«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, «Дәүләт хезмәтләре.Бергәләп хәл итәбез» кире элемтә платформасы аша гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрнең үтәлешен тикшереп тору максатларында «ГЛОНАСС+112» мәгълүмат системасы, шулай ук социаль челтәрләрдәге бәяләмәләр нигезендә Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкилләре белән берлектә республиканың сигез медицина учреждениесенә: «Алексеевск үзәк район хастаханәсе»нә; «Әлмәт үзәк район хастаханәсе»нә; «Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе»нә; «Түбән Кама үзәк район хастаханәсе»нә; «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе»нә; «Арча үзәк район хастаханәсе»нә; Казан шәһәренең «8 нче шәһәр сырхауханәсе»нә; Казан шәһәренең «Россия тимер юллары-Медицина» клиник хастаханәсе»нә баруны оештырды.

Сәфәр барышында Вәкаләтле вәкил гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне оештыруга һәм аларга үз вакытында җавап бирүгә аерым игътибар бирде. Медицина учреждениеләре җитәкчеләренә медицина этикасы һәм деонтология принципларын үтәү мәсьәләләре буенча хезмәткәрләр белән атна саен киңәшмәләр уздырырга тәкъдим ителде.

Аерым билгеләп үтәргә кирәк, Казан шәһәренең «Россия тимер юллары-Медицина» клиник хастаханәсе»нә бару нәтиҗәләре буенча, кискен бөер җитешсезлеге булган пациентларны шәһәрнең профильле учреждениеләренә тәүлек буе озатуны камилләштерү зарурлыгы ачыкланды. Вәкаләтле вәкил әлеге мәсьәләне хәл итү буенча чаралар күрү турында учреждение җитәкчелегенә һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тәкъдимнәр кертте.

Гражданнар мөрәҗәгатьләренә оператив җавап бирү һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерү максатларында Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкилләре, шулай ук медицина оешмалары җитәкчеләре белән эшлекле очрашулар уздырды. Үзара хезмәттәшлек кысаларында медицина ярдәме күрсәтүнең уңайлылыгын һәм сыйфатын күтәрүгә, шулай ук сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклауга юнәлтелгән уртак карарлар эшләнде.

Татарстан Республикасы Премьер – министры урынбасары Л.Р. Фазлыева рәислегендә Җәмәгать сәламәтлеге буенча төбәк советы (алга таба-төбәк советы) эшендә Вәкаләтле вәкилнең катнашуы сәламәтлек саклау системасын камилләштерүнең мөһим эше булды. Төбәк советы утырышларында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен регламентлаштыру һәм дәүләт мәгълүмат системалары аша килә торган хәбәрләрне, мөрәҗәгатьләрне эшкәртүгә бердәм алымнар формалаштыру мәсьәләләре каралды.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы вазыйфаларын башкарганда һәм Татарстан Республикасы төбәк белән идарә итү үзәгенең проект офисын җитәкләгәндә, Вәкаләтле вәкил күп тапкырлар гражданнарга аларның мөрәҗәгатьләрен карау барышы һәм проблемаларны хәл итү сроклары турында вакытында хәбәр итмәү, еш кына социаль киеренкелекнең үсүенә сәбәп булуын ассызыклады.

Утырыш кысаларында җаваплы башкаручыларның гражданнар мөрәҗәгатьләренә җавап бирү вакытын сузу очраклары каралды.

Мәсәлән, 2021 елда «Халык контроле» системасына «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» сырхауханәсендә санитария-гигиена биналарының канәгатьләнерлек булмаган торышы турында хәбәр килде. Хәбәрнамә бирелгәннән соң өч ел ярымнан артык вакыт узса да, эшләрне башкару 2025 елның 16 декабренә генә планлаштырылган иде, шул ук вакытта чараларны гамәлгә ашыруның арадаш этаплары турында тәфсилле мәгълүмат юк иде. Әлеге проблема 2025 елның июлендә төбәк советының икенче утырышында каралды. Кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә инде 2025 елның августында кирәкле ремонт эшләре башкарылды һәм «Лениногорск үзәк район хастаханәсе»ндә санитария-гигиена биналары тиешле хәлгә китерелде, бу пациентларның һәм медицина персоналының уңайлы һәм имин эшен тәэмин итте.

2025 елның октябрендә төбәк советы утырышында Вәкаләтле вәкил шулай ук электрон медицина документациясеннән файдаланудагы катлаулыклар турындагы мәсьәләне күтәрде. Кызганычка каршы, 2025 елда гражданнардан кире элемтә платформасы аша электрон медицина документларын Россия Федерациясенең дәүләт хезмәтләре порталы аша йөкләү мөмкин булмауга кагылышлы мөрәҗәгатьләр килүен дәвам итте.

Шуңа бәйле рәвештә Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлаштыру, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә электрон медицина документларын алу (электрон документларны йөкләү) проблемасын хәл итү чараларын күрергә тәкъдим итә. Шулай ук Сәламәтлек саклау министрлыгына гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда килеп чыга торган кыенлыкларның сәбәпләре турында тулы аңлатмалар урнаштырырга, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләргә тиешле документларны кәгазьдә алу мөмкинлеге турында хәбәр итәргә тәкъдим итәбез.

Ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәменнән файдалану мәсьәләләре

Вәкаләтле вәкил адресына ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәменнән файдалану мәсьәләләренә, шулай ук бригадаларның көтү вакыты һәм аларның саны җитәрлек булмавына бәйле мөрәҗәгатьләр даими рәвештә килә. 2025 ел дәвамында Вәкаләтле вәкил Аппаратына әлеге проблема буенча мөрәҗәгатьләр килүен дәвам итте.

2025 елда «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасы аша 179 мөрәҗәгать (шикаятьләр һәм хәбәрләрнең иң күбесе - Казан, Чаллы шәһәрләреннән һәм Яшел Үзән муниципаль районыннан килгән), «ГЛОНАСС+112» ЕГИС аша-192 хәбәр кергән.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Сәламәтлек саклау өлкәсендә халыкны ресурслар белән тәэмин итү нормативларын һәм нормаларын куллану турында методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2018 елның 20 апрель №18 боерыгы нигезендә ашыгыч медицина ярдәме күрсәткәндә СМП бригадасының пациентка кадәр барып җитү вакыты чакыртканнан соң 20 минуттан артмаска тиеш.

Шул ук вакытта аерым игътибар таләп итә торган очраклар теркәлгән.

Мәсәлән, 2025 елның сентябрендә Биектау муниципаль районыннан гражданка Х.га ашыгыч медицина ярдәме бригадасын чакырырга тырышканда чакыруга чыгу өчен буш ашыгыч медицина ярдәме автомобильләре булмавы турында хәбәр ителгән.

Шикаять «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасында басылып чыкканнан соң, «Биектау үзәк район хастаханәсе» Ашыгыч медицина ярдәме диспетчеры һәм өлкән фельдшерны җәлеп итеп, хезмәт тикшерүе үткәрде. Медицина учреждениесе мөрәҗәгать итүчегә ярдәм иткән, аны табиб-терапевтның планлы каравына чакырган. Мәсьәлә вәзгыять тулысынча хәл ителгәнче Вәкаләтле вәкил контролендә иде.

2025 елның апрелендә Казанда яшәүчедән критик халәте: югары температурасы (40,0°C) һәм сулау авыр булу билгеләре булган пациентка өчен ашыгыч ярдәмне озак көтү (дүрт сәгатьтән артык) турында хәбәр килгән. 16 сәгать 11 минутта килгән чакыру башкару өчен 21 сәгать 30 минутта гына тапшырылган. Казан шәһәренең “Ашыгыч медицина хезмәте станциясе” җитәкчелеге моңа бу чорда хезмәтнең бик тыгыз булуы, чакырулар бик күп булуы белән аңлаткан.

Шундый ук хәл 2025 елның маенда Чаллы шәһәрендә теркәлгән, анда астматик авырулы пациент ашыгыч медицина ярдәме бригадасының килүен биш сәгатьтән артык көткән. Медицина учреждениесе мәгълүматы буенча, чакыру кабул ителгән вакытта буш бригадалар булмаган. Соңыннан мөрәҗәгать итүче «Аллергия» диагнозы белән хастаханәгә озатылган.

«Халык контроле» системасында чагылдырылган мондый очраклар гамәлдәге проблемаларның индикаторы гына түгел, аларны системалы хәл итү өчен дә этәргеч булып тора. Килгән хәбәрнамәләрне анализлау ашыгыч медицина ярдәме хезмәте эшендәге проблемалы мәсьәләләрне ачыкларга, күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеген бәяләргә һәм республика халкы өчен ашыгыч медицина ярдәменең сыйфатын яхшырту буенча алдагы адымнарны планлаштырырга мөмкинлек бирә.

2025 елда яңалыкларның берсе, Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен Лаеш муниципаль районы территориясен Казан шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме станциясе»нә беркетү, хезмәткәрләрнең штат санын оптимальләштерү һәм Лаеш, Комлы Кәвәл һәм Столбище авылларында бригадаларның урнашу зоналарын саклап калу булды. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Казан шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме станциясе» оператив бүлеге базасында бердәм үзәкләштерелгән ашыгыч медицина ярдәме диспетчерлык хезмәтен төзү проектын әзерләде.

2025 елның 1 февраленнән Лаеш районы Ашыгыч медицина ярдәме оешмасын Казан станциясе карамагына тапшыру һәм алга таба Питрәч муниципаль районының Ашыгыч медицина ярдәме бүлеген тапшыру планлаштырылу сәбәпле, Вәкаләтле вәкил «Лаеш үзәк район хастаханәсе» һәм «Питрәч үзәк район хастаханәсе» эшчәнлегенә анализ ясады.

Анализ нәтиҗәләре хезмәт эшен оештыруда уңай тенденцияләрне дә, системалы хәл итүне таләп итә торган кайбер проблемаларны да ачыклады. Аерым алганда, Питрәч муниципаль районында торак пунктларның шактый ерак булуы (үзәктән 55 км га кадәр), районның географик үзенчәлекләре белән бәйле катлаулы юл шартлары, шулай ук фельдшер кадрлары кытлыгы билгеләп үтелде. Лаеш муниципаль районында медицина ярдәме күрсәтүдә тоткарлыклар халыкның интенсив артуы, эре торак пунктларда яшәүчеләрдән мөрәҗәгатьләрнең күп булуы белән бәйле, бу күчмә бригадалар санын арттыру һәм Столбище авылында табиблык амбулаториясе төзү кирәклеге турындагы мәсьәләне актуальләштерде.

Ашыгыч медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлеген һәм сыйфатын тагын да арттыру максатларында, Вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры адресына тәкъдимнәр җибәрелде, алар - кадрлар белән

тәэмин ителешкә комплексы анализ ясауны һәм медицина хезмәткәрләре кытлыгын бетерү буенча чаралар күрүне, яңа табиблык амбулаториясе төзүне һәм аеруча тиз үсә торган торак пунктларда күчмә бригадалар санын арттыруны, шулай ук ашыгыч ярдәм килү вакытын кыскарту һәм маршрутлаштыруны оптимальләштерү өчен бердәм диспетчерлык хезмәте төзүне тизләтү.

Әлеге чараларны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы халкына ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын һәм аннан файдалану мөмкинлеген арттырырга ярдәм итәчәк һәм гражданнарның сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә конституциячел хокукының өстәмә гарантиясе булачак.

Башлангыч медик-санитария ярдәменнән файдалану мәсьәләләре

Гражданнарның сәламәтлек саклауга хокукын тәэмин итүдә башлангыч медицина-санитария ярдәменнән файдалану мөмкинлеге мөһим элемент булып кала.

Вәкаләтле вәкил адресына даими рәвештә табибка язылу мөмкин булмавы яисә кабул итүне озак көтү турында мөрәҗәгатьләр килә. 2025 елда «Табибка язылу мөмкинлеге» категориясе буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына гражданнардан 175 мөрәҗәгать килгән.

Моннан тыш, Аппарат хезмәткәрләре социаль челтәрләрдән килә торган мәгълүматны, шул исәптән Татарстан Республикасы Рәисенә адресланган мөрәҗәгатьләрне дә, даими рәвештә анализлыйлар һәм проблемаларны оператив рәвештә бетерү өчен тиешле мөрәҗәгатьләрне «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыралар.

Кайбер катлаулы хәлләр Вәкаләтле вәкил катнашы белән уңышлы хәл ителде.

Мисал өчен, 2025 елның гыйнварында кергән мөрәҗәгатьләрнең берсендә гражданка Г. «Профессор М.З.Сигал исемендәге республика клиник онкология диспансеры» белгечләренә язылып булмавыннан зарланды. Бу программа яңартылу белән бәйле иде, бу пациентлар өчен шактый уңайсызлыклар тудырды: көтү вакыты артты, ә чиратлар шактый озынайды.

Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатеннән соң Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан комплексы чаралар күрелде: көндезге стационар табиблары саны арттырылды, госпитализацияне рәсмиләштерү өчен өстәмә эш урыны оештырылды, шулай ук персоналның яңа программаны үзләштерүе тизләтелде, бу нормаль эшне торгызырга һәм пациентлар күпләп җыелмаска мөмкинлек бирде. Махсуслаштырылган ярдәмнең территориаль мөмкинлеген арттыру өчен учреждение тарафыннан «20 нче шәһәр сырхауханәсе» һәм «21 нче шәһәр сырхауханәсе» базасында өстәмә химиотерапия кабинетлары ачылды.

Икенче очракта Казанда яшәүче, әнисе мәнфәгатьләрен кайгыртучы гражданка К. күз бәллүрен(хрусталик) алыштыру операциясе алдыннан эндокринологка язылу проблемасы белән очраша. Дәүләт хезмәтләре порталы аша электрон язылу мөмкин түгел иде, ә регистратура бары тик онлайн-язмага гына басым ясады, бу вәзгыятьтә язылу мөмкин түгел булып чыкты. Вәкаләтле вәкил катышканнан соң, мәсьәлә оператив хәл ителде, һәм пациентка кирәкле белгеч консультациясе бирелде.

Шулай ук билгеләп үтәргә кирәк, 2025 елның апрелендә Казан шәһәрендә яшәүче гражданка А. «18 нче шәһәр сырхауханәсе» аскы очлыклар кан тамырларын ультратавыш тикшерүен үткәрүдә шактый тоткарлык булуга шикаять белән мөрәҗәгать иткән. 2024 елның декабрь башында ук билгеләнгән тикшеренү 2025

елның апреленә кадәр үткәрелмәгән. Тикшерү узу мөмкинлеге булмау сәбәпле, мөрәҗәгать итүче кирәкле дәвалау ала алмаган, бу аның сәламәтлеге торышына тискәре йогынты ясаган.

Мөрәҗәгать Вәкаләтле вәкилнең шәхси контроленә алынды, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына вәзгыятьне оператив хәл итүне тәэмин итүне сорап тиешле хат җибәрелде. Күрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә аскы очлык кан тамырларын ультратавыш тикшерүе процедурасы кыска вакыт эчендә башкарылды.

Узган елда проблемаларның системалы булуын раслаучы кабат мөрәҗәгатьләргә дә зур игътибар бирелде.

2025 елның апрелендә кире элемтә платформасы аша гражданнарның «Түбән Кама үзәк район күп профильле хастаханәсе»ндә табиб-эндокринологка язылу мөмкинлеге булмауга шикаятьләр килде. Мөрәҗәгать итүчеләр табиб-эндокринологка язылу белән бәйле җитди кыенлыкларны күрсәттеләр, бу юлламалар булуга карамастан, мәҗбүри медицина тикшерүен вакытында узарга мөмкинлеге булмаган йөкле хатын-кызлар өчен аеруча проблема.

Әлеге факт буенча Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрына мөрәҗәгать юллаган. Алынган җавапта шәхси медицина белгечләрен җәлеп итү һәм участок терапевтлары аша профильле табибларга язылу тәртибен яңадан карау буенча башкарыла торган эшләр турында хәбәр ителде.

Вәзгыятьне хәл итүне контрольдә тоту кысаларында 2025 елның октябрендә Вәкаләтле вәкил «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» баш табибына актуаль мәгълүмат алу өчен запрос җибәрде. Тәкъдим ителгән мәгълүматларга караганда, әгәр 2025 елның апрелендә учреждениедә бары тик өч табиб-эндокринолог (3,25 ставка) эшләгән булса, бу пациентларның махсуслашкан ярдәмгә вакытында керүен тәэмин итмәгән, октябрьгә штат белән тәэмин ителеш 80% ка җиткән (5,25 ставка). Вәзгыятьнең тагын да яхшыруы кадрлар составын «эндокринология» белгечлеге буенча 2 нче ел ординаторлары белән тулыландыру хисабына көтелә.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә медицина хезмәте күрсәтү сыйфатына кагылышлы мәкаләләрне даими күзәтеп торды. Килгән хәбәрләрне анализлау нигезендә гражданнарның махсус медицина ярдәме алуда кыенлыкларга карата шикаятьләре буенча чаралар күрелде.

Аерым алганда, 2025 елның октябрендә «Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе» һәм аның филиалларында балалар неврологына кабул итүгә язылу белән бәйле кыенлыкларга шикаятьләр теркәлгән.

Хәлне җентекләбрәк өйрәнү өчен «Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе» баш табибына мөрәҗәгать җибәрелде. Алынган мәгълүматларга караганда, балалар табибы-невролог Осиново авылындагы күппрофильле сырхауханәдә (төп хезмәткәр) һәм 1 нче балалар сырхауханәсендә (читтән килеп эшләүче хезмәткәр, кабул итү атнага өч тапкыр талоннар буенча алып барыла) кабул итә. Невролог консультациясенә мохтаҗ барлык балаларга «Балалар республика клиник хастаханәсе» белгечләренә консультациягә юлламалар бирелә, әмма бүлеп бирелә торган квоталар саны җитәрлек түгел. 2025 елның 1 октябреннән «Балалар республика клиник хастаханәсе» 2 нче консультатив сырхауханәсендә неврологка консультациягә квоталар саны арттырылды. Яшел Үзән районы администрациясе һәм «Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт оешмасы ярдәмендә аз хәрәкәтләнүче пациентларны карау өчен белгечләрнең атна саен чыгулары оештырылды.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 14 декабрь №1047н боерыгы белән расланган штат нормативлары нигезендә 10 мең балага 1,5 табиб-невролог вазыйфасы каралырга тиеш. Күрсәтелгән нормативлардан чыгып, «Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе»ндә невролог-табибларның 5,0 ставкасын карарга кирәк.

2025 елның 28 октябренә «Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе» штат расписаниесендә балаларга медицина ярдәме күрсәтү өчен 3,5 табиб-невролог ставкасы кертелгән. Хәзерге вакытта «Неврология» белгечлеге буенча ординатурада максатчан укуны 2026 елда эшкә урнаштыру планлаштырыла торган өч белгеч уза. Гомумән алганда, «Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе» дәүләт оешмасында табиблар белән тәэмин ителеш нибары 28% тәшкил итә.

Квалификацияле медицина кадрларына кытлык медицина ярдәмен вакытында күрсәтмәүнең беренче ел гына сәбәбе булып тормый, һәм Вәкаләтле вәкил моны еллык докладларында даими билгеләп үтә. Шул ук вакытта мондый кыенлыклар булу медицина оешмалары җитәкчеләрен кирәкле сандагы кадрлар белән, шул исәптән мәшгульлек хезмәте органнары һәм белгечләрне эзләү һәм җәлеп итүнең башка мөмкин булган механизмнары белән актив хезмәттәшлек итү юлы белән тәэмин итү өчен җаваплылыктан азат итми.

Аеруча зәгыйфь категориядәге гражданнар өчен медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү мәсьәләләре аерым игътибар таләп итә. 2025 елның апрелендә Вәкаләтле вәкилгә медицина хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты мәсьәләләре буенча хокукка сәләтсез балигъ булган гражданнарның законлы вәкилләре мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүчеләр үз карамагындагылар өчен дә, үзләре өчен дә медицина ярдәме алу проблемалары турында борчылуларын белдерделәр. Аерым алганда, табибка язылу, тар белгечләргә консультацияләр оештыру, тиешле тикшерүләр һәм хастаханәгә салу мәсьәләләре күтәрелде.

Әлеге проблематиканың әһәмиятен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил 2025 елның 25 апрелендә кызыксынган министрлыклар һәм ведомстволар, шулай ук иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашында киңәшмә оештырды, аның нәтиҗәләре буенча конкрет карарлар һәм тәкъдимнәр эшләнде.

Аерым алганда, Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенә эшкә сәләтсез гражданнар һәм аларның опекуннары медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать иткәндә килеп туган барлык кыенлыкларны игътибар белән карарга, шулай ук пациентларның индивидуаль үзенчәлекләрен һәм психик халәтен исәпкә алып, эшкә сәләтсезләрне тикшерүне оештырырга киңәш ителә. Моннан тыш, медицина хезмәткәрләре өчен әлеге категория пациентлар белән эшләүдә аларның компетенцияләрен күтәрү өчен укыту семинарлары үткәрергә тәкъдим ителде. Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына авыр психик тайпылышлары булган эшкә сәләтсез гражданнарны диспансерлаштыру һәм медицина тикшерүе тәртибен үтәү мониторингын башкарырга тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2025 елның июнендә биргән мәгълүматларына караганда, тәкъдимнәр үтәлүгә кабул ителгән һәм тиешле чаралар үткәрелгән. Күп кенә тәрбияләнүчеләр өчен тар белгечләр консультацияләре оештырылган, МРТ, УЗИ һәм кан анализлары кебек кирәкле диагностик процедуралар башкарылган, шулай ук тиешле дәвалау билгеләнгән.

Сыйфатлы квалификацияле медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләре

Гражданнарга сыйфатлы квалификацияле медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләре Вәкаләтле вәкилнең игътибарында тора.

Мәсәлән, 2025 елның маенда Вәкаләтле вәкилгә Мамадыш районында яшәүче гражданка М.нан шикаять килгән, ул «Мамадыш үзәк район хастаханәсе»нең «Мамадыш» совхозы бистәсе амбулаториясе участок терапевтының гамәлләреннән канәгать булмавын белдергән. Мөрәҗәгать итүче тиешле квалификацияле медицина ярдәме күрсәтелмәвен әйткән, бу аның сәламәтлеге торышының начараюына китергән.

Вәкаләтле вәкил инициативасы белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тикшерү үткәрде, аның барышында амбулатор ярдәм күрсәтүне оештыруда хокук бозулар, медицина ярдәме күрсәтү тәртибе һәм дәвалау чаралары күләме өлешендә клиник тәкъдимнәрнең үтәлмәве, вазыйфаи затларның тиешле контроле булмавы ачыкланды. Мөрәҗәгать нигезле дип танылды һәм тиешле чара күрү өчен «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» җитәкчелегенә юлланды. Моннан тыш, гражданка М. 2025 елның гыйнварыннан аның гаризасы нигезендә башка участок терапевтына беркетелгән.

Икенче мисал. Вәкаләтле вәкил шулай ук балигъ булмаган улы мәнфәгатьләрендә эш иткән Казан шәһәрендә яшәүче граждан З.мөрәҗәгате буенча чаралар күрде. З. Казан шәһәренең «1 нче шәһәр балалар хастаханәсе» медицина персоналының балага тиешенчә медицина ярдәме күрсәтмәвенә һәм этика һәм деонтология нормаларын үтәмәвенә зарланган.

Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе вәкиле тәкъдимнәре нигезендә хезмәт тикшерүе үткәрелде, аның барышында медицина ярдәме күрсәтүнең аерым этапларында җитешсезлекләр ачыкланды. Тикшерү нәтиҗәләре буенча «1 нче балалар стоматология сырхауханәсе» табиб-стоматологы консультациясен үткәрү турында карар кабул ителде. «1 нче шәһәр балалар хастаханәсе» администрациясе баланы 2 нче сырхауханә бүлегендә алга таба тикшереп тору кирәклегенә басым ясады. Моннан тыш, медицина учреждениесе хезмәткәрләре белән пациентлар һәм аларның законлы вәкилләре белән мөгамәлә иткәндә этика һәм деонтология принципларын төгәл үтәү зарурлыгы буенча чираттан тыш инструктаж үткәрелде.

Гражданнарның хокукларын яклауның нәтиҗәлелеге күбесенчә Вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы буенча Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (Росздравнадзор) территориаль органы (алга таба – ТР буенча Росздравнадзорның территориаль органы) белән тыгыз хезмәттәшлеге белән тәэмин ителә.

2025 елда Росздравнадзорның Татарстан Республикасы буенча территориаль органы белән берлектә гражданнарның 40тан артык мөрәҗәгате каралды. Әлеге хезмәттәшлек сыйфатлы медицина ярдәме алуга хокук бозулар белән бәйле шикаятьләргә оператив һәм комплексы җавап бирергә мөмкинлек бирде. Әйтик, Вәкаләтле вәкилнең ТР буенча Росздравнадзорның территориаль органы белгечләрен җәлеп итеп, уртак күчмә тикшерү чаралары уздыру инициативасы булды, бу тикшерүләрнең объективлыгын һәм компетентлыгын арттырды. Мәсәлән, Казан шәһәренең «2 нче клиник хастаханәсе» һәм психик тайпылышлары булган гражданнар өчен Дәрвишләр бистәсе балалар интернат-йортына бергәләп бару гамәлгә ашырылды.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасы буенча Росздравнадзорның территориаль органы интернет челтәрендә медицина хезмәтләре

күрсәтү турындагы мәгълүматны урнаштыру мәсьәләсенә мониторинг алып бара. Аның нәтиҗәләре буенча 2025 елда әлеге ведомство белгечләре тарафыннан законсыз рәвештә медицина хезмәтләре күрсәтү фактлары ачыкланды. Аерым алганда, күзлек коррекциясен сайлау, пирсинг, перманент татуаж һәм тешләрне протезлау буенча законсыз эшчәнлек билгеләнгән.

Эстетик медицина өлкәсендәге тәртип бозулар җитди борчу тудыра. Махсус рөхсәтсез катлаулы инвазив процедуралар: ботокс кертү, биоревитализация, мезотерапия һәм филлерлар белән коррекция ясалган. Шундый ук хокук бозулар кайбер массаж салоннары эшчәнлегендә дә ачыкланган.

Һәр очрак буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы буенча Росздравнадзорның территориаль органы тарафыннан процессуаль чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына тапшырылган.

Татарстан Республикасында гражданнарның квалификацияле һәм вакытында медицина ярдәменә хокукларын яклау кадрлар сәясәтен камилләштерү, медицина юнәлешләрен маршрутка салуны оптимальләштерү буенча системалы эшне тәэмин итә торган комплексны якын килүне һәм барлык төр медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлеген һәм сыйфатын арттыру өчен оештыру чараларын гамәлгә ашыруны таләп итә.

Гражданнарны дарулар белән тәэмин итү мәсьәләләре

Дарулар белән тәэмин итүнең нәтиҗәле, вакытында һәм тотрыклы системасын оештырмыйча, халыкның сәламәтлеген тиешле дәрәҗәдә саклау мөмкин түгел. Дару препаратлары алу хокукы медицина ярдәме алу хокукыннан аерылгысыз һәм авыруларны лаеклы дәвалау һәм профилактикалау өчен нигез булып тора.

Татарстан Республикасы гражданнарын дарулар белән тәэмин итү мәсьәләләре элеккечә җәмгыятьтә аеруча кискен тикшерелә торган мәсьәләләр исәбендә кала. Тышкы санкцияләр кертү белән бәйле заманча шартларда илнең фармацевтика базары билгеле бер дару препаратлары белән тәэмин итүне сизелерлек чикләүгә юлыкты.

Федераль бюджет акчаларыннан 2025 елда гражданнарның ташламалы категорияләрен тәэмин итүгә 2,558 млрд.сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан төбәк ташламаларыннан файдаланучыларны түләүсез дарулар белән тәэмин итүгә 5,936 млрд. сум бүлеп бирелгән.

Инвалид балаларны ташламалы дарулар белән тәэмин итүне оештыру өчен «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2025 елда төбәк бюджетыннан дару препаратлары сатып алуга 1237,7 млн.сум күләмендә өстәмә акча бүлеп бирелде (шул исәптән Россия Федерациясендә теркәлмәгән яшәү өчен кирәкле һәм иң әһәмиятле дару препаратлары исемлегенә керә торган дарулар), медицина эшләнмәләре (шул исәптән тест-полосалар, глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларына тотыла торган материаллар), дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары.

Татарстан Республикасында дару препаратлары белән тәэмин ителгән гражданнарның ташламалы категорияләре саны 2025 елның 1 декабренә ОНЛС федераль программасы буенча – 91 791 кеше (61,8%), төбәк ташламалары буенча -170 622 кеше (52,3%) тәшкил итте.

Вәкаләтле вәкил «Халык контроле» системасы һәм кире элемтә платформасы аша килгән мөрәҗәгатьләргә аерым игътибар бирә. Мондый һәр хәбәр җентекләп карала, ә проблеманы хәл итүне контрольдә тоту мөрәҗәгать итүченең ихтыяҗлары тулысынча канәгатьләндерелгәнче гамәлгә ашырыла.

Узган елда дарулар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча Вәкаләтле вәкил адресына, шулай ук «Халык контроле» системасы аша 181 мөрәҗәгать кергән.

Әйтик, 2025 елның апрелендә «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына Казан шәһәрендә яшәүче граждан А.дан хәбәр килгән, анда Казан шәһәренең «Таттехмедфарм» ДУПсенең 3 нче даруханәсендә дүрт айдан артык яшәү өчен кирәкле ташламалы дару препаратларын алу мөмкинлеге булмавы турында хәбәр ителгән. Килеп туган вәзгыять граждан А.сәламәтлеге өчен җитди куркыныч тудыра, аңа билгеләнгән медикаментларны даими кабул итү таләп ителә.

Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң һәм тиешле хатны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәргәннән соң, проблема оператив хәл ителде. Алынган мәгълүматларга караганда, пациент барлык кирәкле дару препаратларын алган. Мәсьәләне системалы хәл итүне тәэмин итү өчен мөрәҗәгать итүчене дарулар белән тәэмин итүне Казан шәһәренең «20 нче шәһәр сырхауханәсе» баш табибы урынбасары шәхси контроленә алган.

«Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасы белән берләштән, дарулар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр кире элемтә платформасы аша да килә. Вәкаләтле вәкилнең катнашуы нәтиҗәле мисалы булып 2025 елның августында Әгерҗе муниципаль районында яшәүче граждан Д.ның эпилепсиягә каршы препаратлар алуда кыенлыклар турында хәбәр итүе һәм аларны сатып алуның шактый финанс чыгымнары турында борчылуын белдерүе тора.

Мөрәҗәгатьне беренчел караганда медицина учреждениесе тарафыннан ташламалы дарулар белән тәэмин итүгә өстәмә гариза рәсмиләштерелгән, әмма мөрәҗәгать итүче, препаратларны бирүнең конкрет сроклары һәм гарантияләре булмавын билгеләп, проблеманың тулысынча хәл ителмәвен күрсәткән. Вәкаләтле вәкил катышканнан соң, Сәламәтлек саклау министрлыгы вәзгыятьне тирәнтен тикшерде. Пациент 2025 елның 21 августында «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе»нә кабул итүгә чакырылган, анда аңа кирәкле препаратларга ташламалы дарулар белән тәэмин итү федераль программасы буенча өстәмә гариза бирелгән. Мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә кирәкле препаратлар белән тәэмин итүнең конкрет сроклары турында юллама белән тәэмин итүне тизләтү турында үтенеч хаты җибәрелгән, нәтиҗәдә пациент таләп ителә торган дарулар белән тәэмин ителгән.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән нәтиҗәле хезмәттәшлекнең тагын бер мисалы булып 2025 елның 11 августында килгән хәбәрне карау тора, анда Чаллы шәһәрендә яшәүче мөрәҗәгать итүче Р. операциядән соң «Валганцикловир» яшәү өчен мөһим дару препараты белән тәэмин ителмәвен күрсәтә. Башта медицина оешмасы пациентка дәвалауның альтернатив схемасын тәкъдим иткән, бу граждан ихтыяҗларына туры килмәгән. Вәкаләтле вәкил вәзгыятьне өстәмә өйрәнү инициативасы белән чыкты һәм мөрәҗәгать итүче белән телефоннан сөйләшү барышында пациентның операциядән соң өч ай дәвамында кирәкле препаратны алмавы ачыкланды, ә мөрәҗәгать биргәннән соң бер тапкыр бирелгән бер кап дару проблеманы хәл итмәгән, чөнки алты айлык дәвалау курсы үткәрү таләп ителгән.

Вәкаләтле вәкилнең мөрәҗәгатен карау нәтиҗәләре буенча пациентны дару препараты белән тәэмин итүгә үтенеч хаты Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау

идарәсенә җибәрелде. Кабул ителгән чаралар нәтиҗәсендә пациент 404 нче даруханәдә кирәкле препаратны алган. Вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан вәзгыятьне системалы күзәтеп тору нәтиҗәсендә, 2025 елның 23 сентябренә даруханәгә препаратның икенче партиясе килгән, һәм пациент рецепт алу һәм дәвалануның кирәкле курсын дәвам итү өчен сырхауханәгә вакытында чакырылган.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, хисап елында Татарстан Республикасы буенча Росздравнадзорның территориаль органы тарафыннан гражданнарга кирәкле булган 748 исемдәге дару препаратлары һәм 16 медицина эшләнмәсе үрнәгенең сыйфатына экспертиза оештырылды. Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, сыйфатсыз препаратлар һәм эшләнмәләр әйләнештән алынды. Мәсәлән, дару препаратлары арасында сыйфат стандартларына туры килмәгән: «Каптоприл» (таблеткалар, “ПРАНАФАРМ” ҖЧҖ, Россия), шулай ук «Лоперамид - АЛИУМ» (капсулалар, «АЛИУМ» АҖ, Россия) - «Эреп бетү» сыйфат күрсәткече буенча тест узмады. Кайбер сәламәтлек саклау учреждениеләрендә медицина эшләнмәләрен кулланганда да хокук бозулар теркәлгән. Аерым алганда, әйләнештән алынган: «Луер» шприцлары (5,0 мл) диагностика һәм карау перчаткалары.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2020 елның июленнән барлык дару препаратларына карата мәҗбүри маркировка кертелгән. Маркировканы гамәлгә кертүнең максаты – сыйфатсыз һәм ялган продукция җитештерүгә һәм әйләнешенә каршы тору, шулай ук товар запаслары белән идарә итү. Дару препаратлары әйләнешендә катнашучы барлык оешмалар дару препаратлары әйләнешен мониторинглау системасына дөрес мәгълүматны вакытында кертүне тәэмин итәргә тиеш.

Конкрет төргәкнең геолокациясен билгеләргә мөмкинлек бирә торган дару препаратларын маркировкалауны кертү фармацевтика базарының үтә күренмәлелеген тәэмин итә. Һәр граждан теге яки бу дару препаратын сатуның легитимлыгын тикшерү өчен «Гадел билге» мобиль кушымтасыннан файдалана ала.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, узган елда гражданнарның яшәү өчен кирәкле һәм иң әһәмиятле исемлеккә кертелмәгән дару препаратлары белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләре Вәкаләтле вәкилне аеруча борчуга салды.

Шулай итеп, Вәкаләтле вәкилгә мультисистемалы нейродегенератив авырудан – Хен-Яр шкаласы буенча IV стадиядәге Паркинсон авыруыннан интегүче гражданнардан мөрәҗәгатьләр кергән. Мөрәҗәгать итүчеләр билгеләп үткәнчә, элегрәк комплексны паркинсоник терапия алганнар, әмма ул нәтиҗәле булудан туктаган. Тормыш күрсәткечләре буенча аларга интестиналь кертү өчен гель рәвешендә «Дуодопа» дару препараты белән терапия тәкъдим ителгән, ул тәүлек дәвамында симптомнарның флуктуациясен шактый киметергә мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасы Рәисе ярдәме белән гражданнарны тормыш өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары - ЖНВЛП исемлегенә кертелмәгән дару препаратлары белән тәэмин итү өчен республика бюджетыннан өстәмә финанс бүлеп бирелде.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкилгә Казан шәһәрендә яшәүче граждан К.мөрәҗәгать итеп, аны интестиналь кертү өчен гель рәвешендәге «Дуодопа» дару препараты белән тәэмин итүдә ярдәм итүне сорады. Килеп туган хәлгә тирән борчылу белдереп, Вәкаләтле вәкил әлеге мәсьәләне карау өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрына мөрәҗәгать итте. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, «Дуодопа» дару препараты ЖНВЛП исемлегенә кертелмәгән, һәм граждан К.ны әлеге препарат белән тәэмин

итүне оештыру өчен өстәмә финанслау бүлеп бирү таләп ителгән. Нәтиҗәдә өстәмә акча бүлеп бирү мәсьәләсе уңай хәл ителде. Федераль законнар таләпләре нигезендә әлеге препаратны сатып алуны оештыру өчен конкурс процедурасы үткәрелде, һәм пациентка препарат килгән саен ташламалы дарулар белән тәэмин итү гарантияләнде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрдә шулай ук ЖНВЛП исемлегендә кайбер неврологик авыруларны дәвалаганда кирәкле «Тиаприд» дару препараты булмавы турында хәбәр иттеләр.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматы буенча 2025 елның декабрь ахырына “Дуодоп” (интестиналь кертү өчен гель) дару препараты белән тәэмин итүгә сигез пациент мохтаҗ, еллык ихтыяҗ 29 335,23 мең сум тәшкил итә. “Тиаприд” даруы белән тәэмин итүгә бер инвалид бала мохтаҗ. Еллык ихтыяҗ 46,36 мең сум тәшкил итә.

Күрсәтелгән дару препаратлары белән мохтаҗ пациентлар республика бюджетыннан өстәмә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән тәэмин ителгән.

Әлеге проблеманың әһәмиятен һәм социаль әһәмиятен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрына дару препаратлары исемлеген төзү буенча Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы комиссиясенә дару препаратларын интестиналь кертү өчен гель рәвешендә «Дуодопа» һәм «Тиаприд» ны яшәү өчен кирәкле һәм медицинада кулланыла торган иң мөһим дару препаратлары исемлегенә кертү мөмкинлеген карауны сорап мөрәҗәгать итте. Әлеге докладны тапшырган вакытта Вәкаләтле вәкилнең тәкъдиме карала.

Йомгаклап әйтик, Вәкаләтле вәкил гражданнарны дарулар белән тәэмин итү мәсьәләләрен аерым контрольдә тотуын дәвам итәчәк, кергән мөрәҗәгатьләргә үз вакытында җавап бирәчәк һәм ачыкланган проблемаларны системалы хәл итүгә ярдәм итәчәк, чөнки кирәкле дару препаратларыннан файдалану - сәламәтлек саклау системасының нәтиҗәлелеге күрсәткече генә түгел, ә конституциячел хокукның иң мөһим гарантиясе дә бит.

4.4. ГРАЖДАННАРНЫҢ СОЦИАЛЬ ТӘЭМИН ИТЕЛЕШКӘ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

Теләсә кайсы социаль дәүләтнең төп бурычларыннан берсе - гражданнарга лаеклы тормыш дәрәҗәсен саклап калырга мөмкинлек бирә торган хокукый һәм икътисадый шартлар булдыруга юнәлдерелгән комплексны һәм нигезләнгән сәясәт уздыру. Юридик яктан әһәмиятле шартлар килеп чыкканда — пенсия яшенә җиткәндә, авыру яисә инвалидлык аркасында вакытлыча яисә тотрыклы рәвештә хезмәткә сәләтен югалтканда, туендыручысын югалтканда, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән башка очракларда мондый ярдәм аеруча мөһим.

Гражданнарны социаль тәэмин итү өлкәсендә дәүләтнең социаль юнәлешле сәясәте нәтиҗәсендә уңай үзгәрешләр күзәтелә: ел саен пенсияләр күләме арта, социаль хезмәтләрдән файдаланучылар саны арта. Өлкәннәрне һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын үстерүгә аерым игътибар бирелә, бу аларның тормыш сыйфатын яхшыртуга ярдәм итә.

2025 елда республикада әлеге юнәлеш яңа үсеш алды: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 декабрендәге 1213 номерлы карары белән 2025 – 2030 елларга «Актив озын гомер» республика программасы расланды. Әлеге программа өлкән яшьтәге гражданнарның актив һәм сәламәт яшәү рәвешен озайтуга,

аларның мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга һәм гериатрияне үстерүне дә кертеп, медицина ярдәменең сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән. Программа шулай ук сәламәтлекне саклауга һәм сыйфатлы карауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән социаль хезмәтләрне киңәйтүне, шулай ук өлкән яшьтәге кешеләрнең финанс хәлен яхшырту һәм аларны эш белән тәэмин итү өчен мөмкинлекләр тудыру чараларын күздә тота. Өлкән буынның уңайлы һәм имин тормышын тәэмин итә торган инфраструктураны үстерү мөһим аспект булып тора.

Әлеге программаны гамәлгә ашыру кысаларында «Ак Барс» банкы белән берлектә «Кайгырту» сайтында «Алтын еллар – Золотые годы» бүлеге булдырылды, анда барлык муниципаль районнар буенча интерактив карта урнаштырылган. Аның ярдәмендә өлкән яшьтәге һәр граждан актив форматта физик культура, спорт, мәдәни-ял итү чаралары уздырыла торган, иҗади клублар һәм түгәрәкләр, волонтерлык берләшмәләре эшли торган, әлеге максатчан категория өчен белем бирү программалары гамәлгә ашырыла торган оешмалар турындагы мәгълүмат белән таныша ала, дәресләр уздыру расписаниесе һәм урыны, язылу тәртибе турында бөтен нечкәлекләрне белә ала. Бүген интерактив картада өлкән яшьтәге гражданнар өчен 2 мең дәрес турында мәгълүмат урнаштырылган. Әлеге карта 30 мең пенсионерга кызыксынулары буенча дәресләр сайларга һәм аларда катнашырга язылырга мөмкинлек бирде. Нәтиҗәдә өлкән буын гражданнарының 44,2% ы (479,9 мең кеше) мәдәни-ял итү, иҗат эшчәнлегенә җәлеп ителгән,

Моннан тыш, 2025 елда «Демография» һәм «Гаилә» милли проектлары кысаларында өлкәннәр һәм инвалидлар өчен «Кайгырту йорты» Яшел Үзән интернат-йорты төзелде. Бу заманча учреждение 120 урынга исәпләнгән һәм 8,5 мең кв.метрдан артык мәйданны били. Бинада комплексны тернәкләндерү һәм уңайлы яшәү өчен барлык шартлар да тудырылган. «Акыллы» палаталарны җиһазландыруга аерым игътибар бирелә, анда даими ятак режимында булучылар персонал ярдәменнән башка яктырту, пәрдәләр, ишекләр һәм телевизор белән мөстәкыйль идарә итә алалар. Учреждениедә шулай ук психолог, социаль адаптация һәм хезмәт күнекмәләренә өйрәтү буенча белгечләр, шулай ук физиотерапевт һәм массажист кабинетлары эшли. Дәвалау физкультурасы белән шөгыльләнү өчен аерым зал, иҗади остаханә һәм китапханә бар. Барлык биналарда да заманча җиһазлар урнаштырылган, бу тернәкләндерү бурычларын нәтиҗәле хәл итәргә һәм интернат-йортта яшәүчеләр өчен максималь уңайлы шартлар тудырырга мөмкинлек бирә.

Социаль тәэмин итүгә гражданнарның хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге

2025 елда Вәкаләтле вәкилгә социаль тәэмин итү мәсьәләләре буенча 286 мөрәҗәгать кергән. Гражданнар төрле кире элемтә каналларыннан актив файдаланганнар: “Дәүләт хезмәтләре. Бергә хәл итәбез” бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы платформасы аша 615 хәбәр килде, Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына — 349 хәбәр, «ГЛОНАСС+112» ЕГИС системасына — 403 хәбәр, «Инцидент Менеджмент» системасына 3 756 мөрәҗәгать килде.

Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау республикада яшәүчеләрне борчыган социаль өлкәдәге төп проблемаларны аерып күрсәтергә мөмкинлек бирә: инвалидлык билгеләү, социаль хезмәт күрсәтү системасында хезмәт күрсәтүләрне оештыру,

реабилитацияләүнең техник чараларын алу, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен киртәсез мохит булдыру, пенсия билгеләү һәм яңадан исәпләү, шулай ук вакытыннан алда пенсиягә чыгу мәсьәләләре.

Килгән һәр мөрәҗәгать буенча Вәкаләтле вәкил җентекле эш алып бара: тикшерүләр башлап җибәрә, компетентлы органнарга запрослар җибәрә, гражданнарга хокукый консультацияләр бирә, проблемаларны комплексы хәл итү өчен ведомствоара багланышлар оештыра, кирәк булганда вәзгыятьне объектив бәяләү өчен урынга чыга.

Профильле министрлыклар, ведомстволар, дәүләт органнары һәм муниципаль берәмлекләр белән бергәләп эшләү нәтиҗәсендә 2025 елда кергән мөрәҗәгатьләрнең 70% тан артыгы уңай хәл ителде.

2025 елда Вәкаләтле вәкил эшенең мөһим аспекты булып гражданнарның төрле категорияләре, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр, ветераннар, пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр мәнфәгатьләрен яклаучы иҗтимагый оешмалар белән актив хезмәттәшлек торды. Мондый хезмәттәшлек проблемалы мәсьәләләрне тирәнрәк аңларга һәм килеп туган кыенлыкларга оператив җавап бирергә ярдәм итте.

Профилактика эшләре кысаларында халыкның хокукый грамоталылыгын арттыру буенча системалы эш дәвам итте. Законнардагы үзгәрешләрне аңлатуга, шулай ук социаль ташламалар һәм хезмәтләр алу мөмкинлекләре турында мәгълүмат бирүгә юнәлдерелгән семинарлар, консультация сессияләре үткәрелде.

Хисап елында шулай ук социаль тәэмин итү өлкәсендә норматив-хокукый базаны камилләштерү эше дәвам итте. Вәкаләтле вәкил гражданнарның хокукларын һәм гарантияләрен киңәйтүгә, социаль программаларның үтә күренмәлелеген арттыруга юнәлдерелгән норматив хокукый һәм закон актларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнашты.

Инвалидларның реабилитациянең техник чаралары белән тәэмин итүгә хокукларын яклау

Татарстан Республикасында 2026 елның 1 гыйнварына 311 060 инвалид яши, шулардан 122 551 кеше III төркем инвалидлар, 133 088 кеше II төркем инвалидлар, 36 687 кеше I төркем инвалидлар, 17 173 инвалид балалар.

Хокук яклау практикасы күрсәткәнчә, инвалидларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү мәсьәләләре елдан – ел актуальлеген югалтмый.

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү Фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге мәгълүматларына караганда, 2025 елның 30 декабренә техник реабилитацияләү чаралары һәм протез-протопедия әйберләре белән тәэмин итүгә гаризалар саны 11 182 тәшкил иткән, шуларның 1701е инвалид балалар буенча гаризалар.

Техник тернәкләндерү чаралары һәм протез-ортопедия эшләнмәләре белән тәэмин итү өчен 2025 елда гомуми суммасы 281 914, 0 мең сумлык 130 дәүләт контракты төзелгән.

2025 ел дәвамында Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре инвалидларны протез-протопедия эшләнмәләре һәм шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итүнең проблемалы мәсьәләләре буенча Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан буенча бүлеге оештырган эшлекле очрашуларда катнашты.

Әлеге очрашулар йомгаклары буенча бергәләп әлеге өлкәдә аеруча кискен проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән конкрет тәкъдимнәр эшләнде.

Гражданнарның инвалидларны озак вакыт техник тернәкләндерү чаралары, кирәкле әйберләр белән тәэмин итмәү белән бәйле мөрәҗәгатьләрен объектив һәм һәрьяклап карау өчен Вәкаләтле вәкил фондның Татарстан буенча бүлеге белән тыгыз хезмәттәшлеккә ярдәм итте. Оператив хезмәттәшлек нәтиҗәсендә гражданнарның кайбер мөрәҗәгатьләре уңышлы хәл ителде.

Мәсәлән, гражданка Х.мөрәҗәгате буенча, аның улы, балачактан 1 группа инвалид, дәүләт контракты кысаларында тулы күләмдә җәймәләр (биләүләр) һәм өлкәннәр өчен подгузниклар белән тәэмин ителгән.

Яшел Үзән районы гражданкасы С. дәүләт контракты кысаларында сөт бизенең экзопротезы, бюстгальтерлар (лиф-беркеткечләр) һәм/яисә сөт бизенең экзопротезын теркәү өчен грация (ярымграция), шулай ук сөт бизенең экзопротезы өчен трикотаж чехоллар белән тәэмин ителде.

Лениногорск районы гражданы мөрәҗәгатен карау нәтиҗәсендә аңа уретерокутанеостома өчен сидек катетеры сатып алуга электрон сертификат бирү мәсьәләсе уңай хәл ителде.

Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау күрсәткәнчә, кайбер очракларда инвалидлар өчен техник тернәкләндерү чарасының озак вакыт булмавы төзелгән контрактлар буенча тәэмин итүчеләр тарафыннан китерү срокларын бозу белән бәйле.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил Аппаратына үз әнисе мәнфәгатьләрендә эш иткән һәм аны подгузниклар белән тәэмин итүне сораган гражданка С. мөрәҗәгате кергән. Тикшерү барышында ачыкланганча, тәэмин итүче дәүләт контракты шартларын вакытында тулы күләмдә үтәмәгән, шуның аркасында Россия Пенсия һәм социаль иминияләштерү фондының Татарстан буенча бүлеге аңа дәгъвалар юллаган. Штраф санкцияләренең бер өлеше ирекле рәвештә түләнгән, әмма башка контракт буенча йөкләмәләрне үтәүне тоткарлаган өчен штрафлар һәм пеня күрсәтү белән дәгъва эше дәвам итә.

Инвалидлыгы булган затларның техник тернәкләндерү чаралары белән үз вакытында һәм тулысынча тәэмин итүгә хокукларын һичшиксез үтәү максатларында, Вәкаләтле вәкил, Россия Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан буенча бүлегенә, техник тернәкләндерү чараларына мохтаҗ, инвалидлыгы булган һәр затның сезонлылык факторларын һәм шәхси ихтыяҗларын исәпкә алып, сатып алу процедураларын катгый үз вакытында үткәрүне тәэмин итәргә; техник тернәкләндерү чараларын китерү срокларын мониторинглауның билгеләнгән графиктан теләсә нинди тайпылышларны оператив рәвештә ачыкларга һәм булдырмый калырга мөмкинлек бирә торган комплексны системасын кертергә тәкъдим итә.

Техник тернәкләндерү чараларын сатып алуга электрон сертификатларны җитәрлек финанслау белән тәэмин итү белән бәйле вәзгыять аеруча борчу тудыра. Практика күрсәткәнчә, аерым очракларда электрон сертификатларга акчаларның асылда керүе ике-өч айга кадәр сузыла, бу нык кыенлыклар тудыра, бигрәк тә көндәлек файдалану өчен техник тернәкләндерү чараларын сатып алу кирәк булганда. Мондый тоткарлыклар электрон сертификатның – баштан ук инвалид гражданнарны кирәкле техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү процессын гадиләштерергә һәм тизләтергә тиешле механизм нәтиҗәлелеген юкка чыгара.

2025 елның ноябрендә Вәкаләтле вәкил адресына 1 төркем инвалид, граждан Ш. дан электрон сертификаттан файдалана алмау турында мөрәҗәгать килгән.

Сертификатлар 2025 елның августында дәүләт мәгълүмат системасы аша дөрес резервланган булуга карамастан, 2025 елның ноябренә алар буенча финанслау кермәде.

Килеп туган вәзгыятьтә Вәкаләтле вәкил, Россия Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан буенча бүлеге идарәчесенә эш шартларын һәрьяклап тикшерү, электрон сертификатларны финанслауны тоткарлауның хокукый һәм фактик сәбәпләрен ачыклау, шулай ук акча бирүнең норматив билгеләнгән срокларын үтәүне тикшерү турында мөрәҗәгать итте. Вәкаләтле вәкил ачыкланган хокук бозуларны бетерү һәм мөрәҗәгать итүченең техник тернәкләндерү чараларына тәэмин итүгә хокукларын торгызу буенча тулы чаралар күрергә кирәклеген күрсәтте.

Кабул ителгән чаралар нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүченең электрон сертификатын финанслау мәсьәләсе уңай хәл ителде, бу аның кирәкле техник тернәкләндерү чараларын алу хокукын гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирде.

Россия Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан буенча бүлеге биргән мәгълүматка караганда, 2025 елда электрон сертификатлар рәсмиләштерелгән һәм мөстәкыйль сатып алынган техник тернәкләндерү чарасы өчен (чеклар буенча 01.01.2025) гомуми суммасы 2 577 926,4 мең сумга компенсация түләнгән.

Электрон сертификатларны финанслауның тоткарлану сәбәпләрен анализлаганда без мондый сертификатларга акча күчерү өчен норматив билгеләнгән срокларның булмавына игътибар иттек.

Шунысын билгеләп үтү куанычлы, күрсәтелгән билгесезлекне бетерү һәм инвалидларның кирәкле техник тернәкләндерү чараларына вакытында керүен тәэмин итү өчен 2025 елның ноябрендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенә 2026 елның 1 мартына кадәр инвалидларга техник тернәкләндерү чараларын һәм хезмәтләрен сатып алу (түләү) өчен кулланыла торган электрон сертификатларны финанс белән тәэмин итү тәртибен билгеләү, шул исәптән инвалидларга күрсәтелә торган реабилитацияләүнең, шул исәптән күрсәтелгән сертификатлардан файдалану максатларында ачылган счетларга акча күчерүнең чик срокларын билгеләү йөкләнде.

Инвалидларны электрон сертификатлар ярдәмендә техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү механизмын камилләштерү максатларында Вәкаләтле вәкил, Россия Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан буенча бүлегенә инвалид гражданнар арасында техник тернәкләндерү чараларын сатып алу өчен электрон сертификатларны рәсмиләштерү һәм куллану мөмкинлекләре, тәртибе турында мәгълүмати-аңлату эшен активлаштырырга тәкъдим итә, шул исәптән тиешле мәгълүмати материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында, ведомстволарның рәсми сайтларында, медик-социаль экспертиза учреждениеләрендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, шулай ук инвалидларның иҗтимагый оешмаларында тарату юлы белән.

Инвалидларның күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнең торак урыннарыннан файдалана алуын тәэмин итү

Вәкаләтле вәкилнең эшчәнлек практикасы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен, бигрәк тә коляскадагы инвалидлар өчен, үзләренең күпфатирлы йортларыннан мөстәкыйль рәвештә чыга алмауның элеккечә җитди проблема булып калуын күрсәтә. Тоткарлыксыз чыгу юлы булмау аларның хәрәкәтенә сизелерлек

киртәләр тудыра һәм социаль объектларга һәм җәяүлеләр-транспорт инфраструктурасына керүне чикли. Шул ук вакытта торак йорттан уңайлы һәм һәркем файдалана алырлык чыгу мөмкинлеге булу инвалидларга җәмгыять тормышында тулы канлы катнашырга, аларга социаль интеграция һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү өчен тигез мөмкинлекләр тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган шарт булып тора.

Вәкаләтле вәкил адресына гражданнарның күпфатирлы йортларда торак урыннардан һәм гомуми мөлкәттән файдалана алуны тәэмин итүгә хокукларын гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр җирле үзидарә органнары һәм идарәче оешмалар белән конструктив хезмәттәшлек ярдәмендә нәтиҗәле хәл ителә.

Уңай мисал сыйфатында Казанның К.Габишев урамындагы 1 нче күпфатирлы йорт подъездында инвалид коляскасын төшерү/күтәрү өчен техник ярдәмче җайланманы кыска вакыт эчендә торгызу чараларын башкарган «РФА Сервис» идарәче Компаниясе ҖЧҖ эшен билгеләп үтәргә була. Бу коляскадагы инвалидның яшәү урынына гамәлдәге закон таләпләре нигезендә тоткарлыксыз керүен тәэмин итте.

Икенче мисал булып, тормыш иптәше, коляскада йөрүче 1 группа инвалид мәнфәгатьләрендә эш иткән гражданка Ш.ның Казан шәһәренең Р. Зорге урамындагы 60А күпфатирлы йортның подъезды эченә һәм болдырына пандуслар куеп, торак урынга тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итүдә ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итүе тора.

«УютСервис Групп» ҖЧҖ идарәче компаниясеннән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча техник мөмкинлекләр булмауга сылтап стационар пандуслар урнаштыру мөмкин түгеллеге турында җавап алынган. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче альтернатив вариантны – баскыч буйлап һәм подъезд болдырында җыела торган металл конструкцияләр урнаштыруны карауны сорады.

Инвалидка уңайлы шартлар тудыру һәм хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрү максатларында Вәкаләтле вәкил Казан шәһәре башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгына, шулай ук «УютСервис Групп» җәмгыятенә, пандуслар яисә тоткарлыксыз керүне тәэмин итә торган башка чаралар урнаштыруның техник мөмкинлеген тәэмин итү өчен махсус комиссияне җәлеп итеп, күпфатирлы йортны тикшерүне оештыруны сорап мөрәҗәгать итте.

Соңыннан алынган мәгълүматларга караганда, «УютСервис Групп» ҖЧҖ подъездда җыела торган пандус һәм гариза бирүченең тормыш иптәше яшәгән адрес буенча керү төркемендә пандус урнаштыру буенча эшләр башкарган.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, инвалидларның уңайлы мохиткә хокукларын бозуга бәйле гражданнарның проблемаларын хәл итүдә «Халык контроле» ТР Дәүләт мәгълүмат системасы сизелерлек нәтиҗәлелек күрсәтә. 2025 елда «Уңайлы мохит» категориясендә 197 мөрәҗәгать теркәлгән, шуларның 135е (68%) уңай хәл ителгән. Мөрәҗәгатьләрнең территориаль бүленеше түбәндәге күрсәткечләр белән характерлана: Казан шәһәре – 159, Чаллы шәһәре – 18, Әлмәт районы – 9, Бөгелмә һәм Яшел Үзән районнары – 3әр мөрәҗәгать.

Казан шәһәренең Комиссар Габишев урамындагы 7 нче күпфатирлы йортның 2 нче подъездында пандус урнаштыруга кагылышлы граждан мөрәҗәгате буенча хәл итүне нәтиҗәле эшнең бер мисалы итеп билгеләп үтәргә кирәк. Халыкның аз хәрәкәтчән төркемнәре өчен гомуми мөлкәттән файдалану шартларын тәэмин итү максатларында Вәкаләтле вәкил, Казан шәһәре башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы һәм «РФА Сервис» идарәче

Компаниясе ҖЧҖ җитәкчелегенә күрсәтелгән подъездда пандус монтажлауда һәм тротуарга керү юлындагы плитәдән төшүне җайлаштыруда ярдәм итү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итү инициативасы белән чыкты.

Вәзгыятьне объектив бәяләү һәм чаралар күрү өчен Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре Казан шәһәре башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе һәм «РФА Сервис» идарәче компаниясе ҖЧҖ вәкилләре белән берлектә урынга чыкты. Нәтиҗәдә керү юлларын төзекләндерү эшләре гамәлгә ашырылды, бу аз хәрәкәтләнүче халык төркемнәренә йортка керү мөмкинлеген сизелерлек яхшыртты.

Шул рәвешле, Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң, гражданка Г.ның Казан шәһәре, Ямашев проспекты 69 йорт адресына пандус куюга кагылышлы мөрәҗәгате буенча вәзгыять хәл ителде, анда подъездда яшәүче инвалид-коляскада йөрүченең торак урыннан мөстәкыйль чыгу мөмкинлеге булмаган. Вәкаләтле вәкилнең Казан шәһәренең Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясенә һәм «Уютный Дом «ИК» ҖЧҖ адресына мөрәҗәгате йомгаклары буенча әлеге мәсьәлә уңай хәл ителде, һәм автор, системада уңай шәрехләр калдырып, рәхмәтен белдерде.

Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен күпфатирлы йортлардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ, әлеге проблеманы системалы рәвештә хәл итәргә кирәклеген күрсәтә.

Шуңа бәйле рәвештә Вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органнарына, идарәче компанияләр белән берлектә, уңайлы мохитне тәэмин итү чараларын өстенлекле тәртиптә планлаштыру һәм гамәлгә ашыру максатында, коляскада йөрүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларны ачыклау буенча системалы эш алып барырга тәкъдим итә.

Моннан тыш, инвалидлыгы булган милекчеләрдән тиешле гаризалар булганда, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны планлаштырганда, киртәсез мохит булдыру буенча чаралар, шул исәптән пандуслар, керү юллары, тоткалар һәм башка конструктив элементлар урнаштыруны күздә тотарга, бу халыкның аз хәрәкәтчән төркемнәренең социаль объектларга тоткарлыксыз керү хокукын нәтиҗәле гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

Социаль хезмәт күрсәтү хокукы

Инвалидларның һәм өлкән яшьтәге гражданнарның хокукларын саклауның мөһим аспекты булып аларга стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтү мөмкинлеге тора. Бүгенге көндә халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләтнең социаль сәясәтенең төп өлешләреннән берсе булып тора.

Татарстан Республикасында 2025 елга эшкә яраклы яшьтән өлкәнрәк 955,9 мең кеше яшәгән, бу республика халкының 23,8% ын тәшкил итә.

Өлкән буын өчен, яшькә һәм сәламәтлек торышына карап, актив озак яшәү йә озак вакытлы карау программаларында катнашу беренче планга чыга.

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә өлеш керткән һәм хезмәт ветераны исеменә лаек булган 65 мең өлкән буын гражданы мәнфәгатьләрендә Татарстан Республикасы Рәисе Р. Н.Миңнеханов йөкләмәсен үтәү йөзеннән, быел уртача айлык керемнең социаль ярдәм чараларын алуга хокук бирә торган чик күләме - 20 меңнән 23 мең сумга кадәр арттырылды.

Шулай ук 2025 ел дәвамында:

16,9 мең өлкән һәм инвалид өйләрендә социаль хезмәткәрләр хезмәте алды;

Даими чит ярдәмгә мохтаҗ 6 мең (5 999) өлкән кешегә озак вакытлы карау системасы кертелгән;

528 өлкән кешегә тәрбия буенча ярдәмчеләр хезмәте күрсәтелде;

2,7 мең (2 712) өлкән кеше туганы тәрбияләү нигезләренә өйрәтелгән;

26 өлкән яшьтәге кеше тәрбиягә алган гаиләләрдә яши;

2,2 мең (2 240) кеше инвалидлык рәсмиләштергәнче техник тернәкләндерү чараларын түләүсез прокатлау хезмәтләреннән файдаланган;

Авылда яшәүче 65 яшьтән узган 44,5 мең кеше социаль хезмәткәрләр ярдәмендә медицина тикшерүенә китерелгән. Нәтиҗәдә, һәр алтынчы кеше өстәмә тикшерүгә, операциягә – 100 кешегә җибәрелгән.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматы буенча 2025 елның 19 декабрь көненә психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат-йортларда социаль хезмәтләр алуга чиратта 213 кеше тора. Картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда чират юк. Шул ук вакытта социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең тулылану проценты югары.

Вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән нәтиҗәле хезмәттәшлегенең мисалы булып, 1964 елгы гражданка С.ның аны картлар һәм инвалидлар интернат-йортына билгеләү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгате тора. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры адресына аны социаль учреждениегә урнаштыруда ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итте. Бирелгән җаваптан күренгәнчә, гражданка С. интернат-йортта социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган һәм чиратка куелган (26.09.2025 ел. 1 нче номер). Аны мохтаҗ дип тану вакытына ул хастаханәгә озатылганга күрә, социаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләсе стационар дәваланудан соң каралды. Өстәмә мәгълүматка караганда, 2025 елның 11 ноябреннән гражданка С. «Алабуга өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йорты» оешмасында социаль хезмәтләр алучы булып тора.

Икенче мисал. Питрәч районында яшәүче граждан Р.мәнфәгатьләрендә психик тайпылышлары булган гражданнар өчен социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә соңгысын тизрәк урнаштыруда ярдәм итүне сорап гражданка Г. мөрәҗәгате. Мөрәҗәгатьтән күренгәнчә, граждан Р. ялгыз яши, психик тайпылышлардан интегә һәм үз-үзен мөстәкыйль карау мөмкинлеге юк. Гражданка Г.үзе II группа инвалид булып тора, «кан рагы» авыруыннан интегә һәм өлкән яше аркасында аны тулысынча карый алмый. Мөрәҗәгать итүче сүзләренчә, ул 7 нче номерлы социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә чиратта торган, әмма ике айдан артык инде чират элеккечә калган. Вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры адресына мөрәҗәгатеннән соң, 2025 елның 29 июленнән граждан Р. «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Яңа Чүриле интернат-йорты» учреждениесенең социаль хезмәтләр алучысы булды.

Шул ук вакытта мондый шикаятьләрне караганда социаль ярдәмгә һәм ярдәмгә мохтаҗ гражданнарның еш кына социаль хезмәтләр игътибарыннан читтә калуы җәлеп итә. Социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ гражданның яисә аның законлы вәкиленең гаризасы нигез булып тора. Әмма мондый гражданнарның барысы да бу өлкәдә үз хокуклары турында белми яисә сәламәтлекләре канәгатьләнерлек

булмаганлыктан, тиешле хезмәтләргә гариза белән мөстәкыйль рәвештә мөрәҗәгать итә алмыйлар.

«ГЛОНАСС +112» ЕГИС аша, шулай ук турыдан-туры Вәкаләтле вәкил адресына 2025 елда өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча 286 мөрәҗәгать кергән.

Югарыда бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль социаль яклау бүлекләре белән берлектә ай саен социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ затларны ачыклау буенча эш алып барырга тәкъдим итә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, хисап елында Вәкаләтле вәкил шәхси пансионатлар эшен мониторинглау эшен дәвам итте.

Балык Бистәсе районында эшчәнлек алып баручы өлкән яшьтәге гражданнар өчен хосусый пансионатларның берсе җитәкчесе әлеге учреждениедә яшәүче өлкән яшьтәге кешеләргә социаль һәм медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итте. Мәсьәләнең социаль әһәмиятен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил күчмә киңәшмә оештырды, аның йомгаклары буенча берничә карар кабул ителде, шул исәптән хосусый пансионатта яшәүче гражданнарны урнашкан урынындагы медицина учреждениесенә беркетү, шулай ук һөнәри белем бирү учреждениесенә бердәм минималь таләпләр кертү турында.

Шунысы куанычлы, Вәкаләтле вәкилнең тәкъдимнәре үтәлүгә кабул ителде. Хосусый пансионат хезмәткәрләренә методик ярдәм күрсәтү “Корноухово өлкәннәр һәм инвалидлар интернат-йорты” учреждениесе базасында оештырылган. Дәүләт интернат-йортының эш тәжрибәсен кулланып, эшчәнлекне оештыру мәсьәләләре буенча ике учреждение җитәкчеләре һәм белгечләре очрашулары үткәрелә. Әлеге учрежденинең өлкән яшьтәге гражданнарына медицина хезмәтләрен Түбән Тимерлек авыл җирлеге фельдшеры күрсәтә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2025 елның сентябрендә «ГЛОНАСС+112» ЕГИС ярдәмендә гражданка Р.дан «Сердце гармонии» хосусый пансионатында яшәүче 1941 елгы гражданка белән тиешенчә мөгамәлә итмәү ихтималы турында хәбәр килә. Мөрәҗәгать итүче өлкән яшьтәге хатын-кызның гематомасы булуы һәм аны өченче затлар килүдән изоляцияләү турында хәбәр итә.

Вәкаләтле вәкил Яшел Үзән районы прокуратурасы вәкилләре белән берлектә әлеге учреждениегә планнан тыш күчмә тикшерү уздырды. Тикшерү барышында пансионат биналары каралды, яшәүче гражданнар белән конфиденциаль әңгәмәләр үткәрелде, учрежденинең документациясе тикшерелде. Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданнарны пансионатта тоту шартлары билгеләнгән таләпләргә туры килә, яшәүчеләр белән тиешенчә мөгамәлә итмәү фактлары расланмады, изоляция яки өченче затлар белән аралашу хокукын чикләү очраклары ачыкланмады.

Вәкаләтле вәкилнең 2024 елга еллык докладында Вәкаләтле вәкил өлкән яшьтәге кешеләрне карау буенча хезмәт күрсәтүче оешмалар өчен мәҗбүри лицензияләү кертүнең мөһимлеген ассызыклады. Шуңа бәйле рәвештә гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләнде һәм җибәрелде.

Федерация Советының Регламент һәм парламент эшчәнлеген оештыру комитеты рәисе урынбасары А.М. Терентьевның 2025 елның апрелендә безнең адреска килгән хаты нигезендә социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген лицензияләүгә бәйле мәсьәлә Федерация Советында эштә. Россия

Федерациясе Хөкүмәтенә «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертүне тизләтергә тәкъдим ителде (стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген лицензияләү өлешендә).

Вәкаләтле вәкил әлеге законпроекты якын арада кабул ителер, дип өметләнә.

Билгеле бер яшәү урыны булмаган гражданнарның хокукларын яклауның актуаль мәсьәләләре, «эшче йортларында» яшәүче затларның социаль һәм хезмәт хокукларын тәэмин итү

Йортсызлык проблемасы дәүләтнең һәм җәмгыятьнең иң кискен һәм катлаулы социаль бурычларыннан берсе булып тора.

2024 елның декабрендә Россия Федерациясе Президенты карамагындагы граждан җәмгыятен үстерү һәм Кеше хокуклары советының еллык утырышында ил Президенты В.В. Путин авыр тормыш хәлендә калган кешеләргә ярдәм итүнең мөһимлеген аерым ассызыклады.

«Валидейта» (Validada) социологик маркетинг агентлыгы мәгълүматлары буенча, Россиядә билгеле бер яшәү урыны булмаган 2,13 млн кеше яши. Бу бик зур сан эшләнәсе эш масштабын күрсәтә.

“Кеше приюты” иҗтимагый оешмасының бәяләү мәгълүматлары буенча, Казанда 2024 елда 2,5 тән 2,7 меңгә кадәр йортсыз кеше исәпләнгән. Аларның күпчелеге-ир-атлар (якынча 80%) .

Шәһәр урамнарында йортсызларның булуы Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән төп социаль хокукларны гамәлгә ашыруда гамәлдә булган системалы өзеклекләр турында сөйли һәм дәүләт, муниципаль һәм иҗтимагый ярдәмне камилләштерү кирәклеген күрсәтә.

Соңгы биш елда “ГЛОНАСС+112” ЕГИС аша Вәкаләтле вәкил Аппаратына әлеге тематика буенча 3 000нән артык хәбәр килгән.

2021 ел	2022 ел	2023 ел	2024 ел	2025 ел
288	494	947	786	865

Мөрәҗәгатьләр саны социаль киеренкелек һәм җәмгыятьнең йортсызлык проблемасына борчылуын күрсәтә.

Әлеге мәсьәләнең җитдилеген исәпкә алып, хисап елында «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 ел, 3 март № 95 Татарстан Республикасы Законының 27 нче маддәсе нигезендә Вәкаләтле вәкил тарафыннан «Билгеле бер яшәү урыны булмаган затларның хокукларын яклау: чакырулар һәм карарлар» темасына махсус доклад әзерләнгән (алга таба – махсус доклад). Ул җиде тематик параграфны үз эченә алган ике бүлектән тора.

Әлеге доклад нигезенә Вәкаләтле вәкилнең көндәлек хокук яклау эшчәнлеге нәтиҗәләре, шулай ук Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм иҗтимагый оешмалар белән нәтиҗәле хезмәттәшлек нәтиҗәләре салынды. Нәкъ менә шушы комплексны алым Вәкаләтле вәкилгә билгеле бер яшәү урыны булмаган

затларның хокукларын һәм ирекләрен яклауга кагылышлы мәсьәләләрнең киң спектрын колачларга мөмкинлек бирде.

Махсус докладта йортсызларга ашыгыч ярдәм күрсәтүче махсуслаштырылган дәүләт учреждениеләре һәм коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеге җентекләп яктыртыла. Анда аларның эшчәнлегенең сыйфат һәм сан күрсәткечләре күрсәтелгән: күпме граждан ярдәм алган, башка оешмалар һәм хезмәтләр белән хезмәттәшлек ничек җайга салынган.

Махсус докладта йортсызларга медицина хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә аерым игътибар бирелде. Шулай ук торак йортларның подъездларында йортсыз кешеләр барлыкка килү проблемасы да җентекләп карала.

Махсус докладның икенче бүлеге Татарстан Республикасы территориясендәге "эшче йортлары" эшчәнлегенә багышланган.

Безнең һәрберебез тукталышларда һәм вокзалларда «Эшче йорты», «Эш, торак, атна саен хезмәт хакы», «Авыр хәлдә калганнарга ярдәм», «Эш бирәбез, документларны торгызабыз» дигән белдерүләрне күп тапкырлар күрде. Бу җәлеп итүчән вәгъдәләр артында еш кына хезмәт эксплуатациясенең кырыс чынбарлыгы һәм ирекне чикләү яшеренгән. Белдерүләрдә тәкъдим ителә торган эшнең конкрет тасвирламасы юк диярлек, телефонның контакт номеры гына күрсәтелә, аның буенча шалтырату кешенең билгесез урынга күчүенә китерергә мөмкин.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, 2025 елга Вәкаләтле вәкилнең эш планы нигезендә, Татарстан Республикасы Прокуратурасы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, без «Эшче йортларына» баруны оештырдык. "Эшче йортлары" ның адреслары «Глонасс+112»ЕГИС системасы аша килгән хәбәрләрне анализлау нигезендә билгеләнде.

Махсус докладта күчмә мониторинг барышында ачыкланган төп системалы проблемалар, шулай ук аларны чишү юллары чагылдырылган.

Күпчелек "Эшче йортлары" соры зонада, аларның бернинди юридик статусы яки рөхсәт документлары юк, атап әйткәндә: юридик зат яки шәхси эшмәкәр дәүләт теркәвенә алынмау, биналарны арендалау буенча рәсми рәвештә рәсмиләштерелгән шартнамәләр булмау, салым исәбенә кую бурычларын үтәмәү.

Хәзерге вакытта хезмәтне һәм яшәүне оештыруның әлеге формасын бер үк мәгънәдә идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган билгеләрне билгели торган бердәм норматив хокукый акт юк. Бу хокук куллану практикасында төрлечә укылуга китерә һәм намуссыз эшмәкәрләр тарафыннан манипуляцияләү өчен мөмкинлекләр тудыра.

«Эшче йортлары» эшчәнлегенең формаль булмаган характеры санитария-гигиена нормаларын һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту мөмкинлекләрен сизелерлек чикли. Даими тикшерүләр булмау мондый шартларда яшәүче һәм эшләүче затларның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра.

Махсус доклад проекты Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советы утырышында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары вәкилләре, Татарстан Республикасы муниципаль

районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары вәкилләре, Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчеләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашында каралды.

Махсус докладның йомгаклау өлешендә хакимият органнары, хокук саклау органнары, профильле министрлыклар һәм иҗтимагый оешмалар өчен гамәли киңәшләр бирелгән. Төп тәкъдимнәр арасында - йортсызлыкка каршы көрәш буенча профилактик чараларны көчәйтү, йортсызларга ярдәм күрсәтүче учреждениеләрнең һәркем өчен уңайлы булуын тәэмин итү, шулай ук аларга төбәк һәм муниципаль дәрәҗәдә озак вакытлы ярдәм күрсәтүне һәм социаль яраклашуны оештыру. Аерым игътибар, билгеле бер яшәү урыны булмаган һәм алар белән формаль якын килмичә, тиешле игътибар һәм ярдәм күрсәтеп эшләүче затларны системалы рәвештә ачыклауга бирелә. Шулай ук тәкъдимнәр арасында – мәгълүмат эшен активлаштыру, шул исәптән кешеләр күпләп була торган урыннарда һәм социаль учреждениеләрдә ярдәмгә мохтаҗларга белешмәлек тарату, наркология диспансерларында һәм социаль адаптация үзәкләрендә профилактик әңгәмәләр үткәрү бар.

Йортсыз кешеләрне ачыклау һәм булышу өчен даими рәвештә уртак рейдлар оештыру тәкъдим ителә. Аерым алганда, «Глонасс +112» ЕГИС системасы аша билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар турындагы хәбәрләргә ярты сәгать эчендә килеп җитү белән полиция участок вәкилләренең оператив җавап бирергә тиешлеге ассызыклана.

Күпфатирлы йортларның подъездларында йортсызлар булу проблемасына игътибар итәргә, «Эшче йортлары» сыйфатында файдаланыла торган объектларны ачыклау өчен квартал саен административ участокларны карап чыгарга, шулай ук мондый урыннарда хезмәт хокукларын бозу турында гражданнарның мөрәҗәгатьләре буенча тикшерүләр үткәрергә киңәш ителә.

Әлеге тәкъдимнәр хезмәт эксплуатациясен булдырмауга, гражданнарның хокукларын яклауга, лаеклы хезмәт һәм яшәү шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән системалы үзгәрешләр өчен нигез булып тора.

Әлеге тәкъдимнәрнең үтәлешен контрольдә тоту 2026 елда гамәлгә ашырылачак.

4.5. БЕЛЕМ АЛУ ХОКУКЫ

2025 елда дәүләт тарафыннан икътисадның инновацион үсеше таләпләренә, җәмгыятьнең заманча ихтыяҗларына туры килә торган белем алу мөмкинлеген һәм сыйфатын арттыру буенча эш дәвам итте.

Уку дәресләре расписаниесен формалаштыруга бердәм якын килүне кертү узган елның төп яңалыкларыннан берсе булды. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан 2025/2026 уку елында укуны оештырганда 1-11 сыйныфлар өчен дәресләр расписаниесе вариантлары расланды. Шул ук вакытта һәр мәктәп үзләренең белем бирү процессы үзенчәлегенә җайлаштырылган үз расписаниеләрен төзи ала.

2025 елда шулай ук укучыларның уку йөкләнешен оптимальләштерү чаралары гамәлгә ашырылды. Контроль эшләрнең (язма тикшерүләрнең) дәвамлылыгы бердән ике уку сәгатенә кадәр аралык белән чикләнгән (һәрберсе 45 минуттан артмый). Контроль һәм тикшерү эшләренең гомуми өлеше уку елы дәвамында конкрет сыйныфта һәр фән буенча гомуми уку вакытының 10 процентыннан артмаска тиеш.

2025 елның 1 сентябреннән башлап, «Тарих» предметы буенча аудитор йөкләнеше арттырылды – атнага ике сәгатьтән өч сәгатькә кадәр. 5-7 нче

сыйныфларның уку планнарына яңа модуль – «Безнең төбәк тарихы» кушылган. Әлеге үзгәрешләр патриотик тәрбия бирүнең һәм төбәк тарихын тирәнтен өйрәнүнең мөһимлеген ассызыклый.

Узган елда шулай ук мәктәп формасының яңа милли стандарты – ГОСТ Р 71582-2024 гамәлгә кертелде, ул 1 нче сыйныфтан 11 нче сыйныфка кадәр укучыларның киемнәренә бердәм таләпләр куя, мәктәп киемнәренең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруга юнәлдерелгән.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2025 елның сентябрендә гомуми белем бирү оешмалары һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлегенә кагылышлы санитария кагыйдәләренә һәм нормаларына (СанПиН 1.2.3685-21) мебель урнаштыруны, көн режимын оештыруны, электрон укыту чараларын куллануны һәм азык-төлек блокларын җиһазлауны да кертеп, төрле мәсьәләләрне җайга сала торган үзгәрешләр үз көченә керде.

Тулаем алганда, 2025 елда илебездә күрелгән чаралар комплексы мәгариф системасын камилләштерүгә системалы якын килү турында сөйли һәм балаларны укыту һәм үстерү өчен уңайлырак һәм нәтиҗәлерәк мохит булдыруга юнәлдерелгән.

Гражданнарның белем алуга хокукларын яклау өлкәсендә Вәкаләтле вәкилнең төп эш формалары

Хисап елында Вәкаләтле вәкил институты үз эшчәнлегенең төрле юнәлешләре кысаларында гражданнарның белем алуга хокукларын яклауда катнашты.

Хисап елы дәвамында Вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чараларында яңалыклар тасмасын даими күзәтеп торды, гражданнарның белем алуга хокукын гамәлгә ашыруның аерым проблемаларын өйрәнү һәм тәкъдимнәр кертү максатларында дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан мәгълүмат җыю һәм анализлау гамәлгә ашырылды.

2025 елның май һәм сентябрь айларында Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын – кыз депутатлар берләшмәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәгариф идарәсе вәкилләре катнашында телефон аша «кайнар элемтә» үткәрде, алар барышында мөрәҗәгать итүчеләргә үзләрен кызыксындырган сорауларны бирү, чакырылган белгечләрдән квалификацияле җаваплар һәм консультацияләр алу мөмкинлеге булды. Мондый практика проблемаларны оператив хәл итүгә һәм дәүләт органнары һәм ата-аналар, мәгариф оешмалары арасында диалогны ныгытуга ярдәм итә.

Хисап елында гавами чаралар – форумнар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр барышында дәүләт органнары һәм эксперт җәмәгатьчелеге вәкилләре белән белем алуга хокукны саклау мәсьәләләре каралды.

Аерым алганда, Вәкаләтле вәкил опека һәм попечительлек органнары белгечләре өчен мәгариф хезмәткәрләренең «Балачакны яклауда: стратегияләр, практика, ресурслар» республика август киңәшмәсендә Татарстан Республикасында ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүгә багышланган доклад белән чыгыш ясады (2025 елның 20 июне).

Питрәч районы мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсендә Вәкаләтле вәкил үзенең чыгышында һәр укучыга индивидуаль якын килүне гамәлгә ашыру, ата-аналар белән эшне активлаштыру, тәрбия эшен камилләштерү, балаларны хокуксыз эшчәнлеккә җәлеп итүне булдырмау, шулай ук өстәмә белем бирү системасын үстерүгә кагылышлы актуаль мәсьәләләргә игътибарны юнәлтте. (2025 елның 27 августы).

Вәкаләтле вәкил шулай ук мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең «Хәзерге заман мәгарифенең кыйммәтләр ориентирлары» республика август киңәшмәсенең пленар утырышында катнашты (2025 елның 22 августы).

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе составында актив эшләде, аның утырышларында закон белән конфликтта булган балаларны укыту һәм тәрбияләү, балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау, аларның дәрестән тыш мәшгульлеген оештыру һәм башка темалар каралды.

Моннан тыш, Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының барлык утырышларында катнаштылар, аларда Татарстан Республикасы мәгариф системасын үстерүнең актуаль мәсьәләләре һәм әлеге өлкәдәге закон проектлары тикшерелде.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2025 ел дәвамында Вәкаләтле вәкил институты белем бирү процессында катнашучылар белән тыгыз элемтәдә торды, анда гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары да, югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары студентлары да катнашты.

Халыкара Кеше хокукларын яклау көненә (2025 елның декабре) багышланган чаралар кысаларында Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре «Советлар Союзы Герое А.С. Умеркин исемендәге 116 нчы лицей»ның 9-10 нчы сыйныф укучылары өчен тематик дәрес үткәрде. Әлеге чараның максаты укучыларда хокукый культура, кеше хокукларына һәм ирекләренә, шулай ук дәүләтнең төп законы буларак Россия Федерациясе Конституциясенә хөрмәт тәрбияләүдән гыйбарәт иде.

2025 елның гыйнварында Вәкаләтле вәкил «Ел студенты» премиясе лауреатларын һәм җиңүчеләрен бүләкләү тантанасында катнашты.

Яшьләр инициативаларына ярдәм кысаларында Вәкаләтле вәкил шулай ук “Ярат. Төзе. Илһамлан.”— Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе һәм “Россия-мөмкинлекләр иле” платформасы ярдәмендә оештырылган Татарстан яшьләре өчен белем бирү сессияләре сериясенә кушылды. Программа биш стратегик сессияне үз эченә алды: «Омтылыш», «Сакла», «Ныклык», «Кыйммәт» һәм «Генийлар бергә». 2025 елның 17 сентябрендә инвалид яшьләргә юнәлдерелгән «Омтылыш: карьера турында» сессиясе кысаларында Вәкаләтле вәкил катнашучылар белән очрашу үткәрде, аның барышында гамәлдәге социаль ярдәм чаралары турында җентекләп сөйләде.

Моннан тыш, Вәкаләтле вәкил урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары студентларына юнәлдерелгән “Ел казанышы” IX премиясенең Эксперт советы составына керде, шулай ук җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында катнашты.

Татарстан Республикасында мәгариф оешмаларын төзү һәм капиталь ремонтлау

2025 елда «Яшьләр һәм балалар» илкүләм проектын, «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру һәм республика җитәкчелегенең аерым карарлары кысаларында 4 059 урынга исәпләнгән 5 гомуми белем бирү объекты төзелеше тәмамланды (шул исәптән 1 611 урынга гамәлдәге мәктәпләргә өстәмә өч корпус). Казан шәһәрендә («Лето» торак комплексы), Чаллы шәһәрендә («Мәләкәс аръягы» микрорайоны), шулай ук Кукмара, Лаеш һәм Тукай муниципаль районнарында яңа мәктәпләр файдалануга тапшырылды.

Моннан тыш, 2025 елда Казан шәһәрендә, Питрәч, Лаеш Биектау, Апас муниципаль районнарында 980 урынга исәпләнгән 5 балалар бакчасы төзелде.

Соңгы елларда мәктәпкәчә мәгариф инфраструктурасы объектларын төзү һәм реконструкцияләүнең югары темплары мәгариф системасына барлык яшь категорияләрендәге балалар өчен мәктәпкәчә белем алуның 100 процент мөмкинлегенә ирешергә мөмкинлек бирде.

Хисап елында Вәкаләтле вәкил адресына балаларны мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урыннар белән тәэмин итү мәсьәләләренә кагылышлы аз сандагы мөрәҗәгатьләр керде. Әлеге мөрәҗәгатьләр күбесенчә республиканың эре шәһәрләреннән – Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләреннән килде. Үзләренең мөрәҗәгатьләрендә ата-аналар (законлы вәкилләр) еш кына балаларын яшәү урыны янында урнашкан мәктәпкәчә учреждениеләргә кабул итүдә ярдәм итүләрен сорадылар.

Үз чиратында, һәр мөрәҗәгать буенча Вәкаләтле вәкил мәгариф идарәсе органнарына һәр конкрет балага карата адреслы эш уздыруны һәм мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына кабул итүнең компромисс вариантларын эзләүне сорап мөрәҗәгать итте.

Мәктәпкәчә белем бирүдә уңышларга карамастан, хокук яклау практикасына анализ балаларны гомуми белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэмин итеп, яңа микрорайоннарда территориаль яктан һәркем файдалана алырлык итеп, кыласы эшләр барлыгын күрсәтә. Шул ук вакытта республика җитәкчелеге тарафыннан күрелә торган системалы чаралар әлеге мәсьәләнең кискенлеген акрынлап киметергә ярдәм итә һәм уңай нәтиҗәләр күрсәтә.

Мәсәлән, 2024 елда Лаеш районының Сокурово авыл җирлегендә яшәүчеләр өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Г.Р. Державин исемендәге Сокурово урта гомуми белем бирү мәктәбендә» урыннар кытлыгы проблемасы кискен торды.

Балаларның һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез төп гомуми белем алуга конституциячел хокукын тәэмин итү максатында Вәкаләтле вәкил Лаеш муниципаль районы башлыгына Сокурово авыл җирлегендә гомуми белем бирү мәктәбе төзү буенча тулы чаралар күрүне сорап мөрәҗәгать җибәрде.

Хисап елында әлеге мәсьәлә уңышлы хәл ителде. Сокурово авыл җирлегендә 5000 квадрат метрдан артык мәйданлы заманча дүрт катлы корпус төзелде, ул федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры килә торган заманча техник җиһазлар, мебель һәм кирәкле уку инвентаре белән җиһазландырылган. Яңа бинада мәктәп укучыларын укыту һәм һәрьяклап үстерү өчен уңайлы шартлар тудырылган, моңа иркен уку

сыйныфлары, һөнәри җиһазлар куелган ашханә, дәрестән тыш эшчәнлек өчен бүлмәләр һәм педагоглар өчен уңайлы кабинетлар да керә.

2025 елда Вәкаләтле вәкил адресына, шулай ук «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы аша гражданнардан яңа белем бирү оешмалары төзү кирәклеге турында 20дән артык мөрәҗәгать кергән. Сораулар географиясе Казанны да (Салмачы бистәсе, «Имәнлек экопаркы» торак комплексы) һәм Биектау районының актив үсеп килүче территорияләрен дә үз эченә ала. Торак төзелеше темплары социаль инфраструктура үсешеннән алда баручы Питрәч (Богородкое, Көек, Камышлы бистәләрен) һәм Алабуга районнарының (Поспелово, Луговой Бистәсе, Мальцево авылларын), Биектау районының Шигали, Усад, Озерный бистәсе, Чернышевка, Семиозерка авылларын үз эченә ала.

2025 елда Казанда яшәүчеләрнең иң күп мөрәҗәгатьләре, «Имәнлек экопаркы» торак комплексында яңа мәктәп төзү зарурлыгы белән бәйле. Күрсәтелгән торак массивы актив үсеш белән характерлана, бу күпфатирлы йортларны ел саен файдалануга тапшыруда күренә. Әмма халык санының тотрыклы үсүенә карамастан, күрсәтелгән торак комплексы чикләрендә гомуми белем бирү оешмасы юк. Микрорайонда яшәүче балалар территориаль яктан Казан шәһәре Идел буе районының «6 нчы гимназия», Казан шәһәре Идел буе районының» 16 нчы татар-инглиз гимназиясе», шулай ук Казан шәһәре Идел буе районының 150 нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбенә беркетелгән.

Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүчеләр үз мөрәҗәгатьләрендә югарыда күрсәтелгән мәгариф учреждениеләренең тулылыгына игътибарны юнәлттеләр, бу уку процессын ике сменада оештыруга һәм сыйныфларның тулылануын 40 кешегә кадәр арттыруга китерә.

Килеп туган хәлне җайга салу максатыннан Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Премьер-министры, Мәгариф министры, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе адресына мөрәҗәгать итте.

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты биргән мәгълүматка караганда, «Имәнлек экопаркы» торак комплексы территориясендә элек эшләнгән төзелеш эскизы нигезендә 1100-1501 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү мәктәбе өчен җир кишәрлеге формалаштыруны күздә тоткан межалау проекты расланган. Күрсәтелгән участок 16:00:000000:68438 номеры белән формалаштырылган һәм кадастр исәбенә куелган.

Үз чиратында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хәбәр иткәнчә, 2025 елда Казан шәһәренең «Имәнлек экопаркы» микрорайонында «Яшьләр һәм балалар» илкүләм проекты кысаларында гомуми белем бирү оешмасы төзү каралмаган. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан гомуми белем бирү объектларын төзү буенча федераль проектларда катнашуга гаризаларны өстәмә сайлап алу үткәрелгәндә, республика территориясендә мәктәпләр төзү мәсьәләсе гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә каралачак.

Вәкаләтле вәкил әлеге мәсьәләнең 2026 елда уңай хәл ителүенә өметләнә.

Яңа мәгариф учреждениеләре төзү белән беррәттән, республикада инде булган объектларны капиталь ремонтлауга да зур игътибар бирелә.

Мәгариф министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2025 елда мәгариф оешмаларына капиталь ремонт программасы кысаларында 114 мәгариф оешмасында 2,75 млрд сумлык төзелеш-монтаж эшләре башкарылган. Ремонтланган объектлар арасында -13 муниципаль мәктәп бинасы; 5 дәүләт мәктәбе бинасы; 4 дәүләт оешмасы бинасы; 9

мәктәпкәчә белем бирү оешмасы бинасы; 72 авыл муниципаль һәм 11 дәүләт мәктәбенең функциональ зоналары.

Ирешелгән уңышларга карамастан, мәгариф инфраструктурасының торышы мәсьәләләре актуаль булып кала. 2025 ел дәвамында Вәкаләтле вәкил Аппаратына һәм «Халык контроле» системасына мәгариф учреждениеләре биналарының торышы һәм тузуы белән бәйле 28 мөрәҗәгать кергән. Яр Чаллы шәһәрендә, шулай ук Әлмәт, Алабуга, Зәй, Яшел Үзән, Лениногорск, Түбән Кама һәм Питрәч муниципаль районнарында ремонт эшләрен башкару кирәклеге турында хәбәр иттеләр.

Мәгариф оешмалары территорияләрен төзекләндерү һәм куркынычсызлык аеруча актуаль.

2025 елның ноябрендә Вәкаләтле вәкил адресына С. мөрәҗәгате кергән, анда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Гномик» «5 нче балалар бакчасы» (алга таба - «Гномик» 5 нче балалар бакчасы) коймасының авария хәлендә булуы турында хәбәр ителгән. Вәзгыять территориягә якын ерганак булу белән катлауланды, аның янында автомобиль кую урыннары бар. Мөрәҗәгать итүче уеннар вакытында авария хәлендәге койма җимерелү очрагында балаларның автостоянкага егылуыннан куркуын белдерде.

Кыска вакыт эчендә Вәкаләтле вәкил Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына «Гномик» 5 нче балалар бакчасында булганда балаларның иминлеген тәэмин итү буенча кирәкле чаралар күрү турында тәкъдимнәр белән хат юллады. Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча койманың 27,5 метр озынлыктагы авария хәлендәге өлеше алыштырылган.

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округлары башлыкларына белем бирүнең сыйфатын яхшырту һәм аннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, Мәгариф министрлыгына яңа белем бирү оешмалары төзүгә ихтыяҗ турында, шулай ук гамәлдәге мәгариф объектларына капиталь ремонт ясау кирәклеге турында нигезле тәкъдимнәрне вакытында тапшырырга тәкъдим итә.

Балаларның мәгариф учреждениеләренә кадәр һәм кире кайту куркынычсыз маршрутын тәэмин итү мәсьәләләре

Балаларның иминлеге - җәмгыятьнең иң мөһим өстенлекләренең берсе. Аларның урамнарда йөрү куркынычсызлыгын тәэмин итү, бигрәк тә мәгариф учреждениеләренә барганда һәм кире кайтканда, аеруча мөһим.

2023 ел башыннан 2025 елның ноябренә кадәр республикада балалар катнашында 1305 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән. Әлеге аварияләр нәтиҗәсендә 43 бала вафат булган, ә 1392 бала төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган. Мәгариф учреждениеләре янында булган очраклар аеруча борчый: күрсәтелгән чорда 14 авария теркәлгән, аларда 16 бала зыян күргән.

Балаларның куркынычсыз маршрутын оештыруда заманча юл хәрәкәте куркынычсызлыгы таләпләренә җавап бирә торган тиешле инфраструктура булдыру һәм аны саклап калу принципиаль мөһим элемент булып тора.

Хисап елында «Халык контроле» системасында җәяүлеләр кичүләрен төзекләндерү, светофор объектлары, юл билгеләре, киртәләр урнаштыру, шулай ук мәгариф биналары янында урам-юл челтәренең яктылык дәрәҗәсен арттыру мәсьәләләренә кагылышлы 200дән артык хәбәр теркәлгән. Узган еллардагы

заявкаларны исәпкә алып, әлеге юнәлеш буенча 538 мөрәҗәгать эштә булган, аларның 200се буенча уңай карар кабул ителгән, 179ы буенча эшләр планлаштырылган, ә 81е буенча «Дәлилле кире кагу» статусы бирелгән.

Әйтик, 2025 елның маенда 6874411 номерлы хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре Совет районының «161 номерлы рус-татар урта гомуми белем мәктәбе» янындагы территориядә тротуар чокырларына ремонт ясалган. 2025 елның декабрендә Казан шәһәренең Мәскәү районындагы «Катнаш төрдәге 395 нче балалар бакчасы» янында яктырту баганасы урнаштырылды.

2025 елның октябрендә Яр Чаллы шәһәрендә 7152915 номерлы мөрәҗәгать буенча 28 нче «Снежинка» балалар үсешенең танып белү-сөйләм юнәлеше буенча эшчәнлекне өстенлекле гамәлгә ашырып, гомуми үстерү төрендәге балалар бакчасы территориясендә чокырларга ремонт ясалды.

2025 елның ноябрендә Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлегендә 7035671 номерлы мөрәҗәгать буенча мәктәп автобусы йөри торган юлны ремонтлаганнар. Моннан тыш, 2025 елның августында Тукай муниципаль районында (Жемчужная ур.) 6807830 номерлы мөрәҗәгать буенча балалар иминлеген тәэмин итү өчен ясалма юл тигезсезлеге билгеләнде.

2025 елның сентябрендә 6311535 номерлы мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Лениногорск шәһәренең 8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» территориясенә асфальт салынды.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, балалар иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге кискен проблемаларның берсе – караучысыз калган хайваннарның урамнарда контрольсез булуы.

2025 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Йортсыз хайваннар» категориясе буенча 853 мөрәҗәгать килгән. Әлеге чорда муниципаль берәмлекләрне карасак, иң күп мөрәҗәгатьләр Казан шәһәре буенча бастырылган – 361; Яшел Үзән муниципаль районы буенча – 83; Әлмәт муниципаль районы буенча – 68; Лаеш муниципаль районы буенча - 47; Питрәч муниципаль районы буенча - 37; Түбән Кама муниципаль районы буенча - 35; Биектау муниципаль районы буенча - 32; Алабуга һәм Тукай муниципаль районнары буенча 21әр.

«Инцидент Менеджмент» социаль челтәрләрендә яшәүчеләрнең хәбәрләрен мониторинглау системасы тарафыннан 1537 хәбәр теркәлгән (2024 елда – 1259 хәбәр), аларда караучысыз калган этләрне тоту фактлары турында мәгълүмат бар.

Узган елның ноябрендә Яшел Үзән районының Васильево бистәсендә булган фаҗигале очрактан соң Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак авырулардан халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы һәм «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» гы законнарга үзгәрешләр кертелде.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, әлеге үзгәрешләр хуҗасыз хайваннарга кагылышлы мөгамәләне гамәлдәге хокукый җайга салуның нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк, бу хайваннар белән эш иткәндә гражданнарның хокукларын яклау максатларына ирешергә ярдәм итәчәк.

Урыннарда балаларның куркынычсызлык чараларын гамәлгә ашыру комплексы якын килүне таләп итә һәм ата-аналарның, мәгариф оешмаларының, җәмәгатьчелекнең һәм җирле үзидарә органнарының тырышлыгын берләштермичә хәл итеп булмый торган күп аспектлы бурычны тәшкил итә.

Вәкаләтле вәкил, куркынычсызлыкны арттыру максатларында, җирле үзидарә органнарына ел саен, уку елы башланыр алдыннан, мәгариф оешмалары белән бергәләп, мәктәп янындагы бер километр радиустагы территорияне, якындагы җәмәгать транспорты тукталышларын да кертеп, тикшерергә тәкъдим итә. Әлеге тикшерү юл өслегенең, тротуарларның, яктыртуның торышын комплексы бәяләүне, шулай ук өстәмә юл билгеләре, җәяүлеләр кичүләре һәм киртәләр кую ихтыяҗын ачыклауны үз эченә алырга тиеш.

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау шулай ук балаларны мәгариф учреждениеләренә илтеп җиткерүне оештыруга бәйле мәсьәләләрнең актуальлеген дәлилли. Әлеге тема буенча «Халык контроле» системасына 68 мөрәҗәгать килгән.

Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьләрдә гражданнар балаларны йөртүне оештыру яисә яңа маршрутлар ачу кирәклеген күрсәттеләр. Шулай ук мәктәп автобусларының хәрәкәт расписаниесен бозу яки үзгәртү, юлларның торышы канәгатьләнерлек булмау һәм йөрү кыенлыгы, тукталышлар булмау яки җитәрлек булмау, расписаниенең уңайсыз булуы белән бәйле проблемалар да билгеләп үтелде. Мөрәҗәгатьләрдә куркынычсызлык мәсьәләләренә аерым игътибар бирелде: куркынычсызлык каешы булмау, озата бару һәм башка аспектларга.

Мәгариф оешмалары һәм муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары белән берлектә шактый күп мөрәҗәгатьләр хәл ителде.

Мисал өчен, 2025 елның сентябрендә Вәкаләтле вәкил адресына Биектау районының «Атмосфера» торак комплексында яшәүче балаларны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Х.Гобәши исемендәге 6 нчы Биектау гомуми белем бирү мәктәбе»нә кадәр йөртүне оештыруга бәйле мәсьәләләр буенча гражданка А. мөрәҗәгате кергән. Гариза бирүче хәбәр иткәнчә, балалар мәктәпкә кадәр бара алмый һәм мәктәп автобусын йөртүче булмау сәбәпле кире кайта алмый. Шулай ук торак комплексны мәктәп территориясе белән турыдан-туры тоташтыручы юл төзергә кирәклеген дә әйтте.

Килеп туган хәлдә Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына мөрәҗәгать итте. Хатны карау йомгаклары буенча, кыска вакыт эчендә түбәндәге маршрут расланды: хәзер «Биектауның Х.Гобәши исемендәге 6 нчы урта мәктәбе» - «Атмосфера» торак комплексы - «Биектауның Х.Гобәши исемендәге 6 нчы урта мәктәбе» маршруты буенча укучыларны даими алып килү оештырылган.

Мәгариф оешмаларының автопаркын яңарту эше системалы характерда булуын билгеләп үтәргә кирәк. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 18.07.2024 № 1899-р күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасына 2025 елда 140 мәктәп автобусы (114 — Газ, 26 - ПАЗ маркалы автобус) кайтарылды.

Конфликтлы хәлләрне чишү мәсьәләләре

Белем бирү мохитендә конфликтлар проблемалары әле дә саклана һәм белем бирү процессында катнашучыларның киләчәктә дә игътибарын һәм тырышлыгын таләп итә.

Хисап елында Вәкаләтле вәкил адресына төрле характердагы килеп туган конфликтлы хәлләр турында (укучылар арасында, укучылар һәм педагог арасында, мәктәп җитәкчелеге һәм ата-аналар (законлы вәкилләр) арасында) мөрәҗәгатьләр кергән.

Эшнең барлык шартларын ачыклау максатында мондый мөрәҗәгатьләрне без, мәгариф учреждениеләренә (Казан шәһәре Идел буе районының 73 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең «Советлар Союзы Герое Михаил Егорович Сергеев исемендәге Нурлат гимназиясе», Казан шәһәре Совет районының 47 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Казан шәһәре Киров районының «182 нче политехник лицее» һ. б.) балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре, Мәгариф министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты, мәгариф идарәләренең муниципаль органнары белгечләре белән берлектә барып тикшердек.

Шунысын билгеләп үтү мөһим, конфликтлар булу фактлары барлык очракларда да расланмады. Шуңа да карамастан, һәр мөрәҗәгать буенча мөрәҗәгатьнең шартлары тикшерелде, кирәк булганда бәхәсләрне җайга салу һәм аларны булдырмауны кисәтү буенча чаралар күрелде.

2025 ел дәвамында Вәкаләтле вәкил мәгариф оешмаларында низаглы хәлләрне кисәтү һәм булдырмау буенча республика дәрәҗәсендә эшне оештыруга системалы анализ ясады.

Анализ нәтиҗәләре буенча билгеләп үтәбез, Мәгариф министрлыгы каршындагы балигъ булмаганнар арасында җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалау һәм аларның хокукларын яклау буенча ведомствоара эш төркеме утырышларында квартал саен суицидлар, алкоголь һәм наркотик агуланулар, эзәрлекләүләр (буллинг), балигъ булмаганнар арасында хокук бозулар буенча мәсьәләләр карала.

Имин белем бирү мохитен формалаштыру, балигъ булмаганнарга карата рәхимсез мөгамәләне, көч куллануны профилактикалау буенча комплексны эш «Росток» «психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен үзәк белгечләре һәм психологик-педагогик һәм медик-социаль хезмәтләр һәм укучылар, ата-аналар (законлы вәкилләр) белән бергә ППМС үзәкләре тарафыннан алып барыла.

Уку елы дәвамында Татарстан Республикасы ППМС үзәкләре һәм хезмәтләре түбәндәге эш формаларын кулланып, эзәрлекләүне һәм рәхимсез мөгамәләне кисәтү буенча эш алып бардылар:

укучылар өчен: психологлар катнашында класс сәгатьләре, әңгәмәләр, төркемле дискуссияләр, группорийлар, тренинглар һәм уен дәресләре. Класс/төркем социометриясе эшнең мөһим формасы булып тора. ППМС-хезмәтләр һәм үзәкләр белгечләре 10 308 укучы арасында социометрия үткәрделәр, бу «кире кагылган» укучылар өчен психологик климатны ачыкларга һәм индивидуаль социализация маршрутларын эшләргә мөмкинлек бирде;

педагоглар өчен лекцияләр, семинар-практикумнар, әңгәмәләр, уен һәм тренинг дәресләре (2 334 кешене колачлады), шулай ук аноним анкеталар үткәрелде.

ППМС-хезмәтләр һәм үзәкләр буллингны профилактикалау буенча тәкъдимнәр эшләде;

ата-аналар өчен ата-аналар җыелышы кысаларында әңгәмәләр, психорийлар үткәрелде, эзәрлекләүне (буллингны)профилактикалау буенча психологларның белешмәләре һәм киңәшләре таратылды;

мәгариф оешмаларына «Минем әхлакый ориентирларым», «Уңай «Мин – концепция» формалаштыру», «Конфликтлар, конфликтларны хәл итү», «Үз-үзенә кул салу юнәлешендәге деструктив төркемнәргә җәлеп итү куркынычлары» темалары буенча белгечләр тарафыннан эшләнгән методик тәкъдимнәр җибәрелә, балалар ышаныч телефонының эше турында мәгълүмат бирелә.

Әлеге комплексны чаралар мәгариф оешмаларында ышаныч, үзара хөрмәт һәм психологик иминлек атмосферасы булдыруга юнәлдерелгән. Шунысын да ассызыклап үтәргә кирәк, әлеге эшнең уңышлы булуы күбесенчә ата-аналарның, педагогларның һәм укучыларның үзләренең диалогта һәм бергәләп чишелешләр эзләүдә актив катнашуыннан тора.

Вәкаләтле вәкил, күрелгән адымнарның нәтиҗәлелеген анализлап һәм килеп туган проблемаларны хәл итүгә яңа алымнар тәкъдим итеп, вәзгыятьне мониторинглауны дәвам итәчәк. Сәламәт һәм игелекле мәгариф мохите булдыру - һәркемнән даими камилләшүне һәм җаваплы якын килүне таләп итә торган гомуми бурыч ул.

4.6. ГАИЛӘ ХОКУКЛАРЫ, АТА -АНА ҺӘМ БАЛАЛАР

Гаилә теләсә кайсы җәмгыятьнең нигезе һәм киләчәкне билгеләүче фактор булып тора, анда аралашу, үзара ярдәмләшү һәм шәфкатьлелек, Ватанга мәхәббәт тәҗрибәсе салына. Нәкъ менә гаиләдә кешене мәдәнияткә тарту башкарыла, традицион кыйммәтләр буыннан-буынга тапшырыла. Шул уңайдан гаиләне яклау дәүләтебезнең төп бурычларыннан берсе булып кала.

Дәүләтнең эзлекле гаилә сәясәте нәтиҗәсендә балалы гаиләләрнең хәле яхшыра, гаиләнең җәмгыять мәнфәгатьләрендә эшләве тәэмин ителә.

Узган елда бу юнәлештә мөһим адым, 2036 елга кадәр Россиядә Гаилә һәм демографик сәясәтне гамәлгә ашыру һәм күп балалылыкка ярдәм итү буенча гамәлләр Стратегиясен раслау булды (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 15 мартындагы 615-р номерлы күрсәтмәсе). Стратегия туучылар санын арттыру, ана, ата һәм балалар сәламәтлеген ныгыту исәбенә ил халкын саклап калуга, Россия җәмгыятенең фундаменталь нигезе буларак гаиләләргә ярдәм итүне һәм аларны яклауны тәэмин итүгә, традицион гаилә кыйммәтләрен саклау һәм алга җибәрү нигезендә гаилә һәм никах институтын ныгытуга юнәлдерелгән.

Гаилә институтын ныгыту өчен Стратегиядә аерылышуларны профилактикалауга юнәлдерелгән гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтү программасын киңәйтү, төбәкләрдә күп балалы гаилә көнен билгеләү, оныклары күп булган бабайлар һәм әбиләр өчен иҗтимагый бүләкләр булдыру, «Актив озын гомер» программасын үстерү һ. б. каралган

Республикада гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау балалы гаиләләр өчен актуаль мәсьәләләрнең берсе - социаль ярдәм күрсәтү булуын күрсәтә.

Татарстан Республикасы елдан-ел балалы гаиләләргә ярдәм итүгә комплексы һәм системалы якын килүне күрсәтә.

Тулаем алганда, 2025 елда Татарстан Республикасында балалы гаиләләргә ярдәмгә 38,8 млрд.сум юнәлдерелгән, шулардан: республика бюджеты акчалары – 13,7 млрд. сум, Россия Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан бүлеге акчалары – 25,1 млрд. сум.

Республикада аерым игътибар махсус ярдәмгә мохтаҗ гаиләләргә – яшь, керемнәре түбән булган, инвалид балалар тәрбияләүче, күп балалы гаиләләргә бирелә.

2025 елда:

Аз керемле гаиләләрдән 2,2 мең яңа туган бала беренче кирәкле әйберләр комплектлары алган;

Өч яшькә кадәрге 35 мең бала балалар азыгы белән тәэмин ителгән (медицина күрсәткечләре буенча «Бәләкәч – Малыш» программасы һәм аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар беренче өч елда бушлай махсус азык-төлек -- сөт, кефир, эремчек, сөт катнашмасы белән тәэмин ителәләр).

108,5 мең гаилә балалар бакчасы өчен түләү өлешенә компенсация алган;

өч яшькә кадәрге 5,3 мең сабыйга даруларга 10 мең сум түләү җибәрелгән;

Биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, шуларның берсе инвалид булган 106 гаилә ай саен гаиләнең җан башына уртача керемен яшәү минимумы дәрәҗәсенә күтәрә торган пособие алган (15073).;

Авылдагы 1,5 мең хатын-кыз бала туганда бирелә торган 50-100 мең сум акча алган.

Хисап елында яңа демографик инициативалар кертелде:

Күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен һөнәри белем бирү оешмаларында уку хакының 30% на компенсация бирү (225 мөрәҗәгать итүче);

көндезге бүлектә белем алучы хатын-кызларга йөклелек буенча исәпкә куелганда 100 мең сум күләмендә бер мәртәбә бирелә торган түләү (123 булачак әнигә билгеләнгән);

аз керемле студент гаиләләре өчен "социаль няня" хезмәте күрсәтү (20 кеше файдаланган);

аз керемле гаиләләрдәге яңа туган сабыйлар өчен беренче кирәкле әйберләрне прокатка бирүнең 15 пунктын ачу (20 яшь ата-ана файдаланган).

Күрелгән чаралар нәтиҗәсендә республикабызда күп балалы гаиләләр саны арта. Әйтик, 12 ел эчендә аларның саны 2 тапкырга арткан: 24,4 тән 58,8 мең гаиләгә кадәр.

2025 елдан алып алты яшькә кадәрге күп балалы гаиләләрдәге балалар элек бирелә торган 171 сум субсидия урынына дарулар белән түләүсез тәэмин ителә. Бу 2025 елда әлеге субсидияне алучы 53 799 күп балалы гаилә өчен җитди ярдәм чарасы булды.

Хисап елында фенилкетонурия белән авыручы балаларның сәламәтлеген һәм тормышын тәэмин итү максатыннан айлык акчалата түләү билгеләнде. Әлеге түләүне 68 кеше алды.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, узган елда 10нан артык бала тәрбияләүче алты күп балалы гаилә 15 урынлык «Атлант» маркалы автобуслар белән тәэмин ителгән.

Төрле авыр тормыш хәлләрендә калган гаиләләргә комплексы ярдәм күрсәтү

Гаиләләргә ярдәм итү буенча моңарчы каралмаган чаралар күрелүгә карамастан, төрле авыр тормыш хәлләрендә калган гаиләләргә адреслы ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыруга да, аларга ярдәм күрсәткәндә ведомствоара хезмәттәшлекне көчәйтүгә дә кагылышлы мәсьәләләр әле дә саклана.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Хезмәт министрлыгы) мәгълүматларына караганда, 2025 елның 1 ноябренә социаль яклау органнарында төрле авыр тормыш хәлле балигъ булмаган балалары булган 4607 гаилә исәптә торган.

Социаль яклау органнарында ведомство исәбендә торучы авыр тормыш хәлле һәм социаль яктан куркыныч гаиләләр саны



Кызганычка каршы, Вәкаләтле вәкил үз эшендә кайчак гаиләләргә формаль рәвештә ярдәм күрсәтелә торган хәлләргә юлыга. Чын ярдәм урынына эш балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссиядә ата-аналарны бурычларын тиешенчә үтәмәгән өчен административ җаваплылыкка тарту һәм башка шундый чаралар белән чикләнә.

Мисал өчен, 2025 елның августында Вәкаләтле вәкил адресына сеңлесе Б.һәм аның кызы мәнфәгатьләрендә гражданка С. мөрәҗәгате кергән. Мөрәҗәгать итүченең туганы алкогольгә бәйлелектән интеккән, һәм 2024 елның ноябрендә аның баласы Бөгелмә муниципаль районының «Ялкын» балалар һәм яшүсмерләр социаль приютына урнаштырылган.

Вәкаләтле вәкилнең мөрәҗәгатен карау барышында 2024 елның ноябреннән 2025 елның августына кадәр, килеп туган вәзгыятькә карамастан, җаваплы органнарның Б. гаиләсенә чын ярдәм күрсәтү өчен нәтиҗәле чаралар күрмәве ачыкланды.

Моннан тыш, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 11 нче маддәсен бозып, Бөгелмә районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, дәвалау һәм

реабилитация курсының тәмамлануын контрольдә тотмаган, гражданка Б.медицина учреждениесеннән кайткач, аңа тиешле ярдәм күрсәтмәгән, алкоголь куллануның кабатлануын булдырмауга юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләмәгән, эшкә урнаштыру һәм квалификацияле психологик ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен карамаган, Бөгелмә муниципаль районы муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумы эшчәнлеген координацияләүне һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашырмаган.

Авыр тормыш хәлендәге гаиләгә ярдәм күрсәтү буенча вакытында эшләмәү нәтиҗәсендә балигъ булмаган К.озак вакытлар балалар өчен социаль приютта була.

Гражданка С.мөрәҗәгатен карау йомгаклары буенча, «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 03 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 нче маддәсе 1 өлеше нигезендә Вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына гражданка Б. һәм аның балигъ булмаган кызы К. ның бозылган хокукларын торгызу буенча мөмкин булган һәм кирәкле чараларга карата тәкъдимнәр җибәрелде, алар үтәлде.

Алкоголь һәм наркотиклар куллану проблемасы гаиләләргә җимергеч йогынты ясавын дәвам итә. 2022 елдан 2025 елның 1 ноябренә кадәр 2449 гаилә алкоголь, наркотиклар һәм башка матдәләр куллану аркасында исәпкә куелган, ә 2020 елдан 366 ата-ана ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән.

Алкоголь, наркотик, психоактив матдәләрне чиктән тыш күп куллануга бәйле рәвештә социаль яктан куркыныч гаиләләр исәбенә куелган ата-аналар саны



Хроник алкоголизм яисә наркомания белән авыруга бәйле рәвештә ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән ата-аналар саны



“Республика клиник наркология диспансеры” мәгълүматларына караганда, ел саен 10 меңгә якын хатын-кыз алкогольгә, наркотик матдәләргә яки токсикоманиягә бәйлелек синдромы диагнозы белән исәпкә куела. Бу проблеманың җитдилеген ассызыклый торган борчулы статистика. Әмма елына, хәле яхшырып, 180-200 хатын-кызның гына исәптән төшә алуы сагайта.

Татарстан Республикасы наркология хезмәтендә теркәлгән хатын-кызлар саны турында мәгълүмат

Наименование диагноза	2022 год		2023 год		2024 год		9 мес 2025 год	
	Зарегистрировано женщин	из них снято с улучшением	Зарегистрировано женщин	из них снято с улучшением	Зарегистрировано женщин	из них снято с улучшением	Зарегистрировано женщин	из них снято с улучшением
Синдром зависимости от алкоголя (алкоголизм) и психотические расстройства, связанные с употреблением алкоголя (алкогольные психозы)	8505	160	8527	156	8285	144	7421	119
Синдром зависимости от наркотических веществ (наркомания)	1607	41	1631	32	1659	40	1643	29
Синдром зависимости от ненаркотических психоактивных	10	1	8	0	8	0	8	1

веществ (токсикомания)								

Вәкаләтле вәкил алкоголь һәм наркотикларга бәйлелектән интегүче ата-аналарга психологик ярдәм күрсәтүнең, шулай ук аларны сыйфатлы дәвалауның һәм реабилитацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыруның мөһимлеген ассызыклый. Гаилә алкогольгә бәйле булган очракта балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең 2025 елның 21 мартындагы 11-25 номерлы карары белән расланган субъектларның балигъ булмаганнарның күзәтүчесез булуын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы эшчәнлек алгоритмына җитди иярү мөһим. Алкоголизмның һәр очрагын медицина диагнозы буларак кына түгел, ә эмоциональ һәм физик авыруны, куркуны, шулай ук тернәкләнү өчен потенциаль мөмкинлекне үз эченә алган катлаулы очрак буларак та карарга кирәк.

Көн саен «Глонасс +112» системасы аша, шулай ук турыдан-туры Вәкаләтле вәкил адресына балаларның караусыз булуы, аларның яшәү шартларының тиешенчә булмавы турында мөрәҗәгатьләр килә. Без һәр сигналга төшенергә, барлык хәлләрне ачыкларга тырышабыз. Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчеләре белән бергә муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләренә балаларның яшәү адресына барып, аларның яшәү шартларын бәяләүләрен һәм кирәк булган очракта балалар хокукларын яклау максатларында чаралар күрүләрен сорап мөрәҗәгать итәбез.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкилгә Спас районыннан граждан К. Н. гаиләсе мәнфәгатьләрендә балаларны тартып алулары мөмкин булуы турында хәбәр килгән. Факттагы хәлләрне оператив рәвештә ачыклау максатыннан, Вәкаләтле вәкилнең Спас районындагы җәмәгатьчелек ярдәмчесенә кичекмәстән социаль хезмәт вәкилләре белән бергә гаилә яшәгән урынга чыгу йөкләнде.

Урынга барып тикшерүдән күренгәнчә, гражданка Н. ның ике балигъ булмаган баласы барлыгы ачыкланган. Ул коррекцион мәктәптә белем алган һәм фермада эшли. Ана капиталы акчасына ул өч бүлмәле фатир сатып ала алган, әмма ул үзәкләштерелгән җылыту, су белән тәэмин итү һәм канализация белән җиһазландырылмаган.

2023 елда гаилә ата-ана бурычларын тиешенчә үтәмәү сәбәпле исәпкә куелган, ә 2024 елда уңай динамикага ирешү сәбәпле исәптән төшерелгән. 2025 елда фельдшер сигналы нигезендә ата-ана бурычларын тиешенчә үтәмәү билгеләре кабат теркәлгән: яшәү шартларының санитар шартларга каршы булуы, балаларның пөхтә булмаган тышкы кыяфәте, әниләренең өйдә булмавы күрсәтелгән.

Вәкаләтле вәкил алынган мәгълүматларны анализлап, социаль хезмәтләрнең әлеге гаиләгә ярдәм итү буенча эшенең нәтиҗәле булмавын билгеләп үтте. Анага карата күрелгән төп чаралар аңлату әңгәмәләре һәм профилактик визитлар белән генә чикләнде, ә бу, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, тиешле дәрәҗәдә ярдәм һәм контрольне тәэмин итмәде.

Кызганычка каршы, бу бердәнбер мисал түгел.

Әгерҗе районына сәфәр барышында без бер гаиләдән дүрт баланың өйдә җылылык булмау сәбәпле 2024 елның ноябрендә «Әгерҗе муниципаль районының «Ласка» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приюты» на урнаштырылуын ачыкладык. Без килгәндә (2025 елның августында) алар әле дә учрежденидә иде.

Тапшырылган документлардан күренгәнчә, гражданка Т. 2025 елның 1 сентябрендә генә эшкә урнашкан. Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң, балалар гаиләләренә кайтарылды.

Соңгы дүрт елда даими яшәү урыны һәм яшәү өчен акчалары булмаган аз керемле 101 гаилә исәпкә куелган.

2020 елдан 2710 ата-ана үз балаларын тәрбияләүгә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән, ә зыян күрүче балаларның гомуми саны өч меңнән артып киткән.

Ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү/чикләү



Кызганычка каршы, соңгы биш ел статистикасы шуны күрсәтә: ата-аналарның бик азы гына үз хокукларын кире кайтара алган: барлыгы 104 кеше тәрбиягә хокукларын кире кайтарган. Бу юнәлештә аеруча актив эш Казан шәһәрендә (20 очрак), Әлмәт (9), Яшел Үзән (8), Түбән Кама (6) муниципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә (6) алып барыла. Шулай ук Баулы, Актаныш, Кукмара һәм Минзәлә муниципаль районнарында (5әр очрак), Питрәч, Зәй һәм Арча районнарында (4әр очрак) уңай нәтиҗәләр теркәлгән.

Ата-ана хокукларын торгызу



Вәкаләтле вәкил билгеләп үткәнчә, ата-аналарга ата-ана хокукларын торгызуда ярдәм күрсәтүнең гамәлдәге практикасы куелган бурычларга тулысынча җавап бирми.

Дәүләт сәясәте ата-аналар авырлыкларны җиңеп, балаларын яңадан тәрбияләү хокукына ия булырлык шартлар тудыруга юнәлдерелгән булырга тиеш. Бу бурыч системалы якын килүне һәм гамәлдәге механизмнарны яңадан аңлауны таләп итә. Шуңа бәйле рәвештә Вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органнарына ата-ана хокукларын кире кайтаруның бик сирәк сәбәпләрен анализларга һәм ата-ана хокукларын кире кайтарырга теләгән ата-аналар белән эшләүнең нәтиҗәлелеген арттыру чараларын күрергә тәкъдим итә.

Кайбер төбәкләрдә, мәсәлән, Оренбург, Тамбов һәм Рязань өлкәләрендә, үз ата-ана хокукларын торгызырга омтылган ата-аналар белән ведомствоара профилактика эшен оештыру белән шөгыльләнүче муниципаль комиссияләр (консилиумнар) эшли. Бу комиссияләр төрле хезмәтләр һәм оешмаларның эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә, бу исә кризис хәлендә калган гаиләләр проблемаларын нәтиҗәлерәк хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Төрле хезмәтләрнең һәм оешмаларның гамәлләрен координацияләү максатларында Вәкаләтле вәкил, җирле үзидарә органнарына үзләренең ата-ана хокукларын торгызырга омтылган ата-аналар белән ведомствоара профилактика эшен оештыру өчен комиссия (консилиум) төзү турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итә.

Авыр тормыш хәлендә калган һәм дәүләтнең ашыгыч социаль ярдәменә мохтаҗ балигъ булмаганнарның вакытлыча яшәвен һәм социаль тернәкләнүен тәэмин итә торган балалар өчен социаль приютлар эшчәнлегенә мониторинг нәтиҗәләре

2025 ел дәвамында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе белән берлектә эшләү нәтиҗәсендә Мәгариф министрлыгы, шулай ук Хезмәт министрлыгы тарафыннан социаль куркыныч хәлдә һәм авыр тормыш хәлендә булган гаиләләргә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлекне оештыруга комплекслы анализ ясалды. Профилактика субъектларының балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар белән үзара хезмәттәшлек механизмнарын өйрәнүгә аерым игътибар бирелде.

Хезмәт министрлыгы мәгълүматларына караганда, социаль хезмәт күрсәтү системасында балалар өчен гомуми 443 койка-урын булган 14 социаль приют эшли.

2025 елның 30 сентябренә балалар өчен социаль приютларда 353 бала яшәгән, ә хисап чорында хезмәт күрсәтелгән балаларның гомуми саны 1132 кеше тәшкил иткән.

Социаль приютларда тернәкләнүче балалар саны



Мониторинг кысаларында социаль приютларга чыгулар гамәлгә ашырылды:

- Бөгелмә муниципаль районында «Ялкын» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приюты» (алга таба - «Ялкын» социаль приюты);

- Әгерҗе муниципаль районында «Ласка» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приюты» (алга таба - «Ласка» социаль приюты);

- Питрәч муниципаль районында «Шатлык» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приюты» (алга таба - «Шатлык» социаль приюты);

– Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Кайгырту» социаль приюты» (алга таба - «Кайгырту» социаль приюты);

- Баулы муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Гаилә» социаль приюты» (алга таба – «Гаилә» социаль приюты).

Эш сәфәре йомгаклары буенча социаль приютларда балигъ булмаганнарны тернәкләндерү һәм һәрьяклап үстерү өчен уңай шартлар тудырылуы билгеләп үтелде. Хезмәт министрлыгына, шулай ук әлеге учреждениеләр җитәкчеләренә армый-талмый хезмәт итүләре һәм авыр тормыш хәлендә калган балалар язмышында ихлас катнашулары өчен рәхмәт белдерәбез.

Шул ук вакытта анализ барышында алга таба карау һәм хәл итүне таләп итә торган проблемалы мәсьәләләр ачыкланды.

«Социаль тернәкләнүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр хакында якынча нигезләмәләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 27 ноябрь № 896 карарының 12 пункты нигезендә, балигъ булмаганнар приютта аларга ашыгыч социаль ярдәм күрсәтү һәм киләчәктә урнаштыру мәсьәләләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә хәл итү өчен кирәкле вакыт аралыгында яши.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 31 декабрь № 1100 карарының 6.4.2 пункты нигезендә (алга таба – 1100 номерлы карар) балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениедә социаль хезмәтләр күрсәтү, Россия Федерациясе законнары нигезендә балигъ булмаганнарга ашыгыч социаль ярдәм күрсәтү һәм ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның киләчәк тормышын кайгырту мәсьәләләрен чишү өчен кирәкле вакыт эчендә социаль хезмәтләр күрсәтү шәхси программасы нигезендә тормышка ашырыла.

Социаль хезмәтләр күрсәтү чорының уртача озынлыгы - 3 айдан 6 айга кадәр, максималь озынлыгы - бер ел.

Шуның белән бергә, 2022 елдан 2025 елның сентябренә кадәр 226 баланың 1 елдан артык социаль приютта яшәве ачыкланды. Балаларның социаль приютларда булу вакытын арттыруның төп сәбәпләре булып, гаиләгә кайту буенча ата-аналар белән озак вакыт реабилитацияләү эше, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү /чикләү буенча судка озак вакыт документлар җыю, балалар йортына юлламалар көтүнең озак вакыты, балигъ булмаганнар өчен тәрбиягә алу һәм опекунлык гаиләләрен озак сайлау һ. б. тора.

Үткәрелгән мониторинг кысаларында безнең тарафтан шулай ук билгеләп үтелгәнчә, балалар өчен социаль приютларда социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы килешүләр берьюлы бер елга төзелгән, бу социаль приютлар эшенең баланың нормаль тормыш шартларын вакытлыча хуплауга һәм тизрәк торгызуга юнәлдерелгән төп принципларга каршы килә, шулай ук балалар мәнфәгатьләренә каршы килә, чөнки аларның учреждениедә булуларын озакка суза һәм баланың гаиләгә кайтуына яки аны алга таба урнаштыруга комачаулый.

Югарыда бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил балалар өчен социаль приют директорларының игътибарын ата-аналар (законлы вәкилләр) белән алты айдан да артмаган срокка социаль хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр төзү кирәклегенә юнәлтте. Бу хәлне даими рәвештә яңадан карарга һәм баланың актуаль ихтыяҗларыннан чыгып карар кабул итәргә һәм бары тик аерым очракларда гына килешүне бер елга кадәр озайтырга мөмкинлек бирә.

Тикшерү барышында тәрбиягә алган һәм опекун гаиләләрендәге балаларның социаль приютларда булу мәсьәләләренә аерым игътибар бирелде.

«Ласка» социаль приютында опекуннарның язма гаризасы нигезендә кабул ителгән алты балигъ булмаган бала булган.

Мәсәлән, 2024 елның 22 ноябрендә «Ласка» социаль приютына балигъ булмаган Ш.кабул ителгән, ә 2025 елның 27 гыйнварында аның сеңлесе С. Әлеге приютка кадәр булган хәлләр балаларның аеруча авыр хәлдә калуын күрсәтә: аналары хокукыннан мәхрүм ителгән, һәм 2016 елның июненнән алар М. ның тәрбиягә алган гаиләсендә яшәгәннәр, анда, булган мәгълүматларга караганда, даими рәвештә тәрбиягә алган ана ягыннан физик җәберләүгә дучар булганнар.

Әгерҗе районы башкарма комитетының 2024 ел 27 май №153 карары нигезендә Ш.һәм С. опекуны итеп гражданка К. билгеләнә. Әмма алты айдан соң гражданка К. балаларны «Ласка» приютына урнаштыра, моны «конфликт» һәм «авыр тормыш хәле»дип аңлата.

2025 елның февралендә «Яр Чаллы шәһәренең ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруга ярдәм итү үзәге» белгечләре тарафыннан гражданка К.ның балаларны тәрбияләргә теләге юклыгы билгеләп үтелде. «Ласка» социаль приюты җитәкчелеге шулай ук гражданка К.белән балигъ булмаган балалар арасында психологик контакт булмавын раслады. Бу хакта Әгерҗе районының опека һәм попечительлек органына берничә тапкыр «Ласка» социаль приюты хәбәр итте.

Вәкаләтле вәкил Аппараты Әгерҗе районының опека һәм попечительлек органының 2025 елның февраленнән сентябренә кадәр опека килешүен өзү өчен тиешле чаралар күрмәвен ачыклады.

Эш төркеме әгъзалары шулай ук балалар өчен социаль приютларның балигъ булмаганнар турында мәгълүматларны бердәм банкка һәрвакытта да вакытында кертмәвенә игътибар иттеләр.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасының бердәм белешмәләр банкын төзү турында» 2010 елның 22 апрелендәге 294 номерлы карарының 3 бүлеге нигезендә Бердәм белешмәләр банкына балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләнү үзәкләрендә, социаль приютларда, махсус укыту үзәкләрендә тотылучы социаль ярдәмгә мохтаҗ балигъ булмаганнар кертелә.

Әмма «Ласка» социаль приютында приютта яшәүче 20 балигъ булмаган баланың бары тик 3 гаиләдән 6 баласы турында гына мәгълүмат бердәм мәгълүматлар банкына кертелгән, бу исә әлеге мәгълүматлар банкын формалаштыру һәм алып баруга карата билгеләнгән таләпләрнең тулысынча үтәлмәвен күрсәтә.

Мониторинг кысаларында балалар өчен социаль приютларның балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектлары белән үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләренә дә аерым игътибар бирелде.

Балигъ булмаганнарның күп вакытын мәгариф мохитендә уздыруын исәпкә алсак, мәгариф оешмалары белән үзара хезмәттәшлек беренчел әһәмияткә ия. Социаль приютларга урнаштырганда белем бирү оешмасының алмашынуы мәктәпләрнең педагогик составы ягыннан да, социаль приют тәрбиячеләре ягыннан да ныклы игътибар кирәклегенә китерә, чөнки яңа коллективта адаптация процессы һәм шәхес ара мөнәсәбәтләр формалаштыру катлаулы бурыч булып тора.

Шул ук вакытта эшче төркем тарафыннан «Шатлык» социаль приютының балалар укый торган гомуми белем бирү учреждениеләре белән эшен тиешенчә оештырмавы билгеләнде.Болар -

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының "2 нче Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе" ;

- "Россия Герое Иван Алексеевич Додосов исемендәге аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 1 нче Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе" .

Уртак эш планы төзелмәгәнлеге, күзәтү көндәлекләре алып барылмаганлыгы, балалар очраша торган хәлләргә анализ мәгариф оешмаларында да, «Шатлык» социаль приютында да үткәрелмәгәнлеге ачыкланды. Әлеге фактлар ведомствоара хезмәттәшлекнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавын һәм һәр балага индивидуаль якын килүнең нәтиҗәле гамәлгә ашырылмавын күрсәтә.

Шулай ук «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 13 нче маддәсе 5 өлешенең 2 пункты нигезендә социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр, күрсәтелгән учреждениеләрнең уставлары яисә алар турындагы нигезләмәләр нигезендә балигъ булмаганнарга, аларның ата-аналарына яисә башка законлы вәкилләренә авыр тормыш хәлләрен бетерүдә, балигъ булмаганнарның уку, эшләү, яшәү урынындагы яшьтәшләре коллективларында социаль статусын торгызуда социаль, психологик һәм башка төрле ярдәм күрсәтәләр.

Күрсәтелгән нормаы бозып, 2025 елның маеннан октябренә кадәр «Шатлык» социаль приютында психолог вазыйфасы вакантлы булган, шуңа бәйле рәвештә

социаль приютта тәрбияләнүче балигъ булмаган балаларга психологик ярдәм күрсәтелмәгән.

Мониторинг нәтиҗәләре буенча эшче төркем әгъзалары тарафыннан билгеләп үтелгәнчә, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр тарафыннан социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр белән эшләүне оештыруда, шулай ук балалар өчен социаль приютлардагы балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүдә координацияләү роле тиешенчә гамәлгә ашырылмый.

Опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегенә мониторинг нәтиҗәләре

Районнарга чыгу кысаларында Татарстан Республикасы Питрәч, Әгерҗе, Алексеевск муниципаль районнарының опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген аерым өйрәндек.

Питрәч муниципаль районының опека һәм попечительлек бүлеге эшчәнлегенең уңай нәтиҗәләрен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Шул ук вакытта Әгерҗе һәм Алексеевск муниципаль районнарында опека һәм попечительлек өлкәсендә закон таләпләрен бозу очраклары ачыкланды.

Опекуннарның һәм опекада булганнарның шәхси эшләрен сайлап өйрәнү барышында кайбер очракларда Әгерҗе һәм Алексеевск муниципаль районнарының опека һәм попечительлек органнары тарафыннан опекага алынганнарның яшәү шартларын планлы тикшерүнең билгеләнгән сроклары үтәлмәве ачыкланды.

Шулай ук шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2024 ел өчен опекуннар хисабына сайлап анализ ясау опекуннар биргән белешмәләрнең җитешсезлекләрен һәм аермалыкларын ачыклады, бу опекуннар милкеннән максатчан файдаланмау яисә опекунлык бурычларын тиешенчә үтәмәү мөмкинлеген дәлилләде.

Мәсәлән, З. ның шәхси эшен өйрәнү барышында 2024 елның 25 июнендә балигъ булмаган кызның счетыннан акчалар алынды, дип билгеләнгән. Алексеевск муниципаль районының опека һәм попечительлек органы хезмәткәрләре тарафыннан Алексеевск районы башкарма комитеты җитәкчесенең опекунга, лагерьга юллама алу өчен балигъ булмаган кыз счетыннан акча алырга рөхсәт итә торган карарлары тапшырылган. Шуңа да карамастан, шәхси эштә дә, опекун гаризасына да юлламаны түләүне раслаучы документлар беркетелмәгән.

Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң Алексеевск районының опека һәм попечительлек органы тарафыннан фикер каршылыкларының сәбәпләрен ачыклауга һәм дөрес мәгълүматны һәм раслаучы документларны тапшыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрелде.

Күчмә тикшерү барышында шулай ук Алексеевск муниципаль районының опека һәм попечительлек органының ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар файдасына алиментны вакытында түләтүне тиешле контрольдә тотмавы ачыкланды.

Россия Федерациясе Гаилә кодексының 71 нче маддәсе нигезендә ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү ата-ананы үз баласын матди яктан карау бурычыннан азат итми.

«Балигъ булмаганнарның хокук бозуларының күзәтүчесезлеген профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 9 нчы маддәсе 4 пункты нигезендә балаларның законлы вәкилләре балигъ

булмаганнарның хокукларын бозган өчен, шулай ук аларны тәрбияләү, укыту бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җаваплылык тота.

Шуның белән бергә тәрбиягә бала алучы һәм опекун гаиләләрендә тәрбияләнүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мөлкәти хокукларын яклау һәм балаларның шәхси счетларына алимент керүен тикшереп тору максатыннан, опека һәм попечительлек органы белгечләре суд приставлары хезмәтенең структур бүлекчәләренә алимент түләтү буенча башкарма эш барышы, суд приставлары тарафыннан күрелгән чаралар турында мәгълүмат бирү турында үз вакытында запрослар җибәрмәделәр.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, балалар өчен социаль приютлар мониторингы һәм районнарның опека һәм попечительлек органнары мониторингы нәтиҗәләре Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советы утырышында (2025 елның 26 ноябре) тикшерелде, анда Россия Федерациясе Дәүләт Думасы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, республика прокуратурасы вәкилләре, шулай ук профильле министрлыклар, ведомстволар һәм башкарма комитетлар вәкилләре катнашты.

Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советы эше нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары) башлыкларына, муниципаль берәмлекләрдә (шәһәр округларында) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларына, авыр тормыш хәлендә калган балигъ булмаганнарның вакытлыча яшәвен һәм социаль тернәкләнүен тәэмин итүче балалар өчен социаль приютларга тәкъдимнәр әзерләнде һәм җибәрелде.

Әлеге тәкъдимнәрнең үтәлешен контрольдә тоту Вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан 2026 елда гамәлгә ашырылачак.

4.7. УҢАЙЛЫ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТКӘ ХОКУК

Россия Федерациясе Конституциясе һәр гражданның экологик имин шартларда яшәү һәм әйләнә-тирә мохитнең торышы турында дөрес мәгълүмат алу хокукын гарантияли. Әлеге хокук кешенең төп ирекләре арасында төп урынны алып тора һәм аның иминлек дәрәҗәсен турыдан-туры билгели.

2025 елда Татарстан Республикасында гражданнарның экологик иминлеккә хокуклары гарантияләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән эш дәвам итте. «Экологик иминлек» илкүләм проектын гамәлгә ашырганда узган елда төбәктә 1,2 млрд.сумнан артык акча үзләштерелгән. Әлеге проект кысаларында республикада Яр Чаллы шәһәрендә Мәләкәс елгасы үзәненең бер өлешен чистарту эшләре башланды (проектны 2027 елда тәмамлау планлаштырыла), һәм Казан шәһәренең Отар һәм Победилово бистәләре янындагы ләм кырларын рекультивацияләү эше 93% ка төгәлләнгән.

«Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проекты кысаларында 111 млн.сумнан артык акча урманнарны торгызуга һәм техниканы модернизацияләүгә юнәлдерелгән, 2 мең гектардан артык мәйданда урман торгызу эшләре башкарылган.

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигать ресурсларын торгызу буенча дәүләт программасы кысаларында өстәмә рәвештә 74 максатчан чара уздырылган.

Республикада табигатьне саклау чараларын финанслауның гомуми күләме 16,8 млрд. сум тәшкил итте.

Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы (алга таба – Экология министрлыгы) үткәргән социологик сораштыру нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасында экологик проблемаларга кызыксыну 2022 ел белән чагыштырганда 3,5% ка арткан. Ничек кенә булмасын, экология мәсьәләләре белән республикада яшәүчеләрнең 84,6% ы кызыксына. Сораштыруда катнашучыларның 42,1% ы республикада соңгы 2-3 елда экологик хәл яхшырды дип саный.

2025 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Экология» юнәлеше буенча 1 231 мөрәҗәгать басылып чыкты, шулардан гражданнар мөрәҗәгатьләренең күбесе мондый категорияләрдә:

– “Чүплекләр” – 582 мөрәҗәгать,

– “Һава” – 290 мөрәҗәгать,

– “Су “ – 185 мөрәҗәгать.

Экология һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» дәүләт системасы кире элемтә платформасы аша узган елда 1 573 хәбәр килгән.

Гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын саклау мәсьәләләрендә Вәкаләтле вәкил Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы, Татарстан районара табигатьне саклау прокуратурасы, Экология министрлыгы, Росприроднадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән тыгыз элемтәдә торды.

Әйтик, табигатьне саклау ведомстволары җитәкчеләре белән берлектә гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрләрне анализлау барышында ачыкланган проблемалы мәсьәләләр 2025 елның июнендә Татарстан Республикасында «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисы утырышында каралды.

Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге кысаларында шулай ук, гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне карауны турыдан-туры тикшереп тору гамәлгә ашырыла. Әлеге эш даими нигездә алып барыла һәм гражданнарның экологик хокукларын тәэмин итү системасының мөһим элементы булып тора.

Мисал өчен, безнең адреска «ГЛОНАСС + 112» системасы аша мөрәҗәгать килде. Граждан А. Лениногорск муниципаль районының Подлесный бистәсендә дуңгызчылык фермасының калдыкларны җирлек рельефына (туфракка) агызуы һәм атмосфера һавасын пычратуы турында яза.

Бистәдә яшәүчеләрнең тормыш иминлегенә хокукларын яклау максатыннан Вәкаләтле вәкил экология министры адресына мөрәҗәгать итте. Экология министрлыгы хезмәткәрләре күчмә тикшерү барышында «Агро-Строй» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җир кишәрлегендә урнашкан дуңгызчылык комплексы территориясеннән агып төшүче суларның законсыз агызылу факты ачыкланды, бу туфракның пычрануына китергән.

Ачыкланган хокук бозу нәтиҗәсендә Экология министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Арбитраж судына юридик заттан Татарстан Республикасы бюджетына китерелгән зыянны түләттерү турында дәгъва гаризасы бирелгән. Еллык докладны язу вакытында эш суд каравында иде.

Шулай ук муниципаль районнарга даими бару барышында Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре гражданнар мөрәҗәгатьләрен тиешенчә үтәмәү фактлары буенча «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасында тикшерүләр үткәрде.

Вәкаләтле вәкил адресына Актаныш муниципаль районының Татар Ямалы авылында Сосновский балтырганына каршы көрәш чараларының булмавы турында гражданка Г.мөрәҗәгате килеп ирешкән. Соңгы вакытта бу агулы үләннең үсү мәйданы шактый артты, бу җирле экологик система өчен генә түгел, ә халыкның сәламәтлегенә дә җитди куркыныч тудырды, дип билгеләп үтелде.

Вәкаләтле вәкил Актаныш муниципаль районы башлыгына торак пункт территориясендә куркыныч үсемлекләрне контрольдә тоту һәм юк итү буенча тиешле чаралар күрү турында тәкъдимнәр җибәрде.

Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органы проблеманы хәл итте. Безнең мөрәҗәгатьтән соң әлеге мөрәҗәгатьне кабул итү һәм үтәү буенча тиешле чаралар күрелде.

Хәбәрләрне модерацияләү һәм анализлау йомгаклары буенча Вәкаләтле вәкил, башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм хуҗалык субъектларының җаваплы затларына гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын саклауга һәм яклауга бәйле 25 тән артык тәкъдим җибәргән.

Атмосфера һавасын саклау

Хисап елында без социаль челтәрләргә өзлексез мониторинг үткәрдек, аның нәтиҗәсендә гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларына кагылышлы 1 496 мөрәҗәгать ачыкланды, шуларның күбесе (767, ягъни 50% тан артыгы) атмосфера һавасын пычрату проблемалары белән бәйле иде.

2025 елда социаль челтәрләргә Яшел Үзән муниципаль районының Осиново бистәсендә һәм Казан шәһәренең төньяк өлешендә яшәүчеләрнең һаваның пычрануына карата шикаятьләре килүе дәвам итте. Ә ел дәвамында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына әлеге проблема буенча 90 хәбәрнамә керде, алар системаны кулланучыларның 281 теләктәшлеген алды, бу узган еллар белән чагыштырганда азрак (2023 елда – 300дән артык хәбәрнамә, 1 100 теләктәшлек, 2024 елда – 200дән артык хәбәрнамә, 746 теләктәшлек), бу Экология министрлыгы тарафыннан күрелә торган чаралар нәтиҗәсе. Бу мониторингны көчәйтү, республика башкаласыннан 3 км радиуста яңа предприятиеләр өчен пычрануны исәпләүнең җыелма системасын кертү, нәтиҗәдә, Казан шәһәренең төньягында зарарлы матдәләрнең рөхсәт ителгән чик концентрациясеннән артып китү саны сигез тапкырга кимеде, бу проблема буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләре санын киметүгә китерде, бу хакта шулай ук «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасына кергән хәбәрнамәләрнең югарыда күрсәтелгән статистикасы да раслый.

Шулай ук ел дәвамында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына гражданнардан Биектау муниципаль районында һаваның пычрануы турында 18 хәбәрнамә кергән, аларны системадан 140 кулланучы хуплаган.

Вәкаләтле вәкил әлеге шикаятьләрне тиешле тәкъдимнәр белән башкарма хакимиятнең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органнарына җибәргән иде, шулай ук 2025 елның августында Биектау муниципаль районында узган күчмә киңәшмәдә каралды. Мәгълүмат шулай ук Казан районара табигатьне саклау прокуроры адресына да җибәрелде.

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы үткәргән контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча һаваны пычратучы «Астра Синтез» ҖЧҖ икәнлеге ачыкланды, ул 19 чыганак аша пычраткыч матдәләр чыгара, алар нигездә - мазут һәм дизель ягулыгы яну нәтиҗәсендә барлыкка килә торган төтен газлары.

Прокуратура органы тикшерү нәтиҗәләре буенча предприятие адресына тәкъдимнәр кертте, алар карала, шулай ук административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының 8.1 маддәсе буенча административ хокук бозу турында эш кузгату турында карар чыгарылды һәм административ штраф билгеләнде.

Моннан тыш, 2025 елның сентябрендә Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан әлеге юридик затны тикшерү уздырылган. Санитар-саклау зонасы проектларының санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитар-эпидемиологик нәтиҗәләр булмау, күрсәтелгән предприятиенең йогынты зонасында атмосфера һавасы сыйфатына производство контроле үткәрмәгән өчен Роспотребнадзор тарафыннан гаепле зат РФ КоАП 6.3 маддәсенең 1 өлеше буенча административ җаваплылыкка тартылды.

Су объектларын саклау

Экологик иминлеккә бәйле тагын бер мөһим аспект - су ресурсларын саклау.

Татарстан Республикасы Рәисе ярдәме белән 2018 елдан 2025 елга кадәр республикада 28 су объекты савыктырылды, 44 елга чистартылды, 79 гидротехник корылма ремонтланды, 12 яр ныгыту корылмасы төзелде, шулай ук 23 чакрым эшләми торган нефть үткәргечләре сүтелде.

Татарстан Республикасы 2025 ел йомгаклары буенча «Экологик иминлек» илкүләм проекты кысаларында оештырылган «Россия суы» Бөтенроссия акциясендә беренче урынны алды. Бер ел эчендә республикада 6 794 табигатьне саклау чарасы уздырылды, аларда республиканың 410 меңнән артык кешесе катнашты. Нәтиҗәдә 12 мең километрдан артык яр буе линиясен тәртипкә китерү мөмкин булды.

Социаль челтәрләр мониторингы йомгаклары буенча экология тематикасы буенча фикер алышуларда популярлыгы буенча икенче урында - су объектларын саклау мәсьәләләре тора – 494 хәбәр килгән, бу әлеге юнәлеш буенча килгән хәбәрләрнең гомуми өлешенең 30% тәшкил итә.

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында «Су» категориясе буенча иң күп мөрәҗәгатьләр Казан шәһәре (74), Яшел Үзән (17), Лаеш (16) һәм Питрәч (12) муниципаль районнары, Чаллы шәһәре (11) һәм Биектау муниципаль районы (9) буенча бастырылган.

Мәсәлән, «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне карау барышын мониторинглау кысаларында, без, Казанның Томанлы урамындагы су объектына төзелеш чүп-чарын түгү һәм ташлау мәсьәләсе буенча 2025 ел 4 сентябрь № 7094950 шикаятен ачыкладык, аны 125 кулланучы хуплады һәм 169 тапкыр шәрехләде.

Әлеге проблеманың социаль әһәмиятен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрү максатында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министры адресына мөрәҗәгать юллады.

Экология министрлыгы тарафыннан табигатьне саклау законнарын бозучыларга карата уртак чаралар нәтиҗәсендә РФ КоАП 8.2, 8.42 маддәләренең 3.3 өлеше буенча административ җәза билгеләү турында карар чыгарылды. Административ штрафлар түләнмәү сәбәпле, 2026 елда министрлык тарафыннан хокук бозучыга карата дәгъва характерындагы эш дәвам ителәчәк.

Узган елда гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокуклары бозылу ихтималы турындагы мәгълүматны тикшерү кысаларында, Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре контроль-күзәтчелек органнары, җирле үзидарә органнары һәм юридик затлар вәкилләре белән берлектә күчмә тикшерү чараларында катнашты.

2025 елның октябрендә Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы вәкилләре белән берлектә, «Водоканал-Сервис» ҖЧҖ (Арча шәһәре) карата Арча муниципаль районында Казансу елгасына агызылган суларны агызу барышында табигатьне саклау законнарын бозу факты буенча тикшерүдә катнашты.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча хокук бозулар ачыкланган, атап әйткәндә: юридик зат тарафыннан пычраткыч матдәләрнең рөхсәт ителә торган концентрациясе чикләреннән күп тапкырга артып киткән, агынты сулар билгеләнгән нормативлардан артыграк агызылган, бу су объектына 6 млн. сумнан артык зыян китергән һ. б.

Ачыкланган хокук бозулар нәтиҗәсендә прокуратура органы тарафыннан хокук бозучыга карата закон бозуларны бетерү турында күрсәтмә кертелде, шулай ук административ хокук бозу турында эш кузгату турында карар чыгарылды, алар карала. Шулай ук су объектына китерелгән зыянны каплау өлешендә предприятиегә карата дәгъва характерындагы чаралар күрү мәсьәләсе дә карала.

Бүлектә күрсәтелгән очраклар җәмәгать контроле һәм экологик хокук бозуларга цифрлы платформалар аша оператив җавап бирү системасының нәтиҗәлелеген ачык күрсәтә.

Мондый хокук бозуларга вакытында җавап бирүнең мөһимлеген исәпкә алып, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына әйләнә-тирә мохитне саклау буенча чаралар планын төзегәндә һәм тиешле финанс чараларын бүлгәндә, республика халкының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы һәм «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» кире элемтә платформасы аша кергән мөрәҗәгатьләрен исәпкә алырга киңәш итәбез.

Законсыз чүплекләр мәсьәләләре

2025 елда экология мәсьәләләре буенча Вәкаләтле вәкил адресына 31 мөрәҗәгать теркәлгән. «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында узган елда «Экология» юнәлеше буенча гражданнарның 1 231 мөрәҗәгате басылып чыкты, бу узган ел белән чагыштырганда 5% ка күбрәк.

Законсыз чүплекләр оешу мәсьәләләре буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге Казан (238 мөрәҗәгать), Чаллы (71), Лаеш (47), Тукай (36), Яшел Үзән (27), Алабуга (21) Әлмәт һәм Биектау (20шәр), Түбән Кама (16) муниципаль районнары буенча бастырып чыгарылган.

Республика муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән нәтиҗәле хезмәттәшлек нәтиҗәсендә Казан шәһәре, Әлмәт, Арча, Биектау, Зәй, Яшел Үзән, Лаеш, Питрәч, Спас муниципаль районнары территорияләрендә санкцияләнмәгән чүплекләр бетерелде.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында гражданнарга белдерүләр модерациясе барышында, безнең тарафтан шулай ук җаваплы башкаручылар тарафыннан «Гариза хәл ителде» дигән нигезсез статус бирү очраклары ачыкланды.

Шулай итеп, без Алабуга муниципаль районының «Түбән Кама» милли паркы территориясендәге законсыз чүплекне бетерү мәсьәләсе буенча «Халык контроле» системасында «Гариза хәл ителде» статусын нигезсез бирү фактын ачыкладык. Мониторинг барышында хәбәрнамәләр, аларның карары турында мәгълүмат бирелмәү сәбәпле, эшкә кире кайтарылды. Алга таба системада башкаручылар, раслаучы фотоотчет урнаштырып, хәбәрнамә буенча чаралар күрү турында мәгълүмат бирделәр. Хәзерге вакытта әлеге чүплек бетерелгән.

Башкарылган эшләргә карамастан, мониторинг барышында чүплекләр барлыкка килүнең яңа фактлары теркәлү дәвам итә, бу исә халыкның мөрәҗәгатьләренә оператив җавап бирүне һәм дәүләт һәм муниципаль органнарның даими контролен таләп итә.

Шулай итеп, Вәкаләтле вәкилгә Лениногорск шәһәренең Яр буе урамында янгын куркынычы булган калдыкларны законсыз туплау турында граждан Т. мөрәҗәгате килеп ирешкән. Әлеге мөрәҗәгать безнең тарафтан Экология министрлыгына җибәрелде һәм Лениногорск шәһәре башкарма комитеты адресына табигатьне саклау законнарының мәҗбүри таләпләрен бозуга юл куймау турында кисәтү игълан ителде. Кабул ителгән чаралар нәтиҗәсендә рөхсәтсез чүплек бетерелде.

Шулай ук Вәкаләтле вәкил адресына Тукай муниципаль районының Олы Шилнә авылы территориясендә табигатьне саклау законнарын бозу, шул исәптән табигый чишмәләре булган чокырны күмү һәм агачларны кисү турындагы мөрәҗәгатьне карау йомгаклары буенча Экология министрлыгы җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә табигатьне саклау законнарын бозуны ачыклады, атап әйткәндә, урын ачыкланды.

Хәзерге вакытта Экология министрлыгы тарафыннан Чаллы шәһәр судына хокук бозуны бетерү һәм хокук бозучыны туфракка китерелгән зыянны капларга мәҗбүр итү максатыннан дәгъва гаризасы җибәрелгән. Әлеге мөрәҗәгатьне төгәл үтәү мәсьәләсе Вәкаләтле вәкил контролендә кала.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү

Калдыкларны җыюны, алып китүне һәм утильләштерүне оештыруның нәтиҗәлелеге халыкның тормыш сыйфатына һәм Татарстан Республикасында экологик хәлгә турыдан-туры йогынты ясый. Дәүләт һәм муниципаль органнарның, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторларының һәм гражданнарның үзара хезмәттәшлеге, әлеге өлкәдә барлыкка килә торган мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле шарт булып тора.

Вәкаләтле вәкил Аппараты күп еллар дәвамында каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча төбәк операторлары белән актив хезмәттәшлек алып бара, шул исәптән «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында эшләү юлы белән.

Уртак тырышлык белән күрелгән чаралар нәтиҗәсендә агымдагы елда каты көнкүреш калдыклары белән эш итү мәсьәләләре буенча системага мөрәҗәгатьләр санын 36% ка киметүгә ирешелде (2025 елда «Каты коммуналь калдыклар» юнәлеше буенча 3 173 мөрәҗәгать керде, ә 2024 елда 4 318 мөрәҗәгать басылып чыкты).

Хисап елында каты көнкүреш калдыкларын чыгару мәсьәләләре буенча бастырылган мөрәҗәгатьләрнең 94% ы (719 дан 673е), шулай ук контейнер мәйданчыкларын төзү һәм карап тоту мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрнең 87% ы – 88% ы (2 679 мөрәҗәгатьнең 2 323е) үтәлгән, бу республикада калдыклар әйләнеше белән бәйле хәлнең планлы рәвештә яхшыруын күрсәтә.

Республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча «Каты көнкүреш калдыкларын чыгару» категориясе буенча Казан шәһәре буенча – 311, Чаллы шәһәре буенча – 54, Лаеш шәһәре буенча – 48, Алабуга һәм Яшел Үзән муниципаль районнары буенча – 45;

контейнер мәйданчыкларын төзү һәм карап тоту мәсьәләләре буенча: Казан шәһәре буенча – 1 318, Яшел Үзән шәһәре буенча – 261 һәм Лаеш муниципаль районнары буенча – 202, Чаллы шәһәре буенча - 187 һәм Әлмәт муниципаль районында -105 мөрәҗәгать.

2025 елда «ПЖКХ «ИК» ҖЧҖ һәм «Гринта» ҖЧҖ каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча төбәк операторлары адресына 370 һәм 111 мөрәҗәгать кергән.

Казан шәһәрендә быел 147 яңа контейнер мәйданчыгы төзекләндерелде, биш ел эчендә барлыгы 289 мәйданчык. Агымдагы елда республика буенча каты коммуналь калдыкларны туплау өчен 4 меңнән артык контейнер алыштырылды һәм урнаштырылды.

Кабул ителгән чараларга карамастан, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм карап тоту мәсьәләсе актуаль булып кала бирә. Әлеге проблема буенча мөрәҗәгатьләр Вәкаләтле вәкил адресына да керә.

Әйтик, безнең адреска граждан З. Биектау районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау тимер юл станциясенең Мәктәп урамы буенча көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыгын киртәләп алмавы турында мөрәҗәгать итте, нәтиҗәдә, бункерны көнкүреш калдыклары белән тиз тутыру сәбәпле, калдыкларның контейнер мәйданчыгыннан читкә таралуын кисәтү тәэмин ителмәде. Без бу мөрәҗәгатьне, чаралар күрү өчен, Биектау районы прокуратурасына җибәрдек.

Әлеге факт буенча прокуратура органы тарафыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе адресына, ачыкланган закон бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелде. Шулай ук Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Биектау территориаль бүлеге тарафыннан Красносельский авыл җирлеге башкарма комитетына хокук бозуларны бетерү турында дәгъва гаризасы җибәрелде, ул карау стадиясендә.

Әйтергә кирәк, экологик иминлекне тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлеше булып тора. Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм җәмәгатьчелекнең уртак тырышлыгы, һичшиксез, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметергә һәм республика гражданнарының тормыш сыйфатын күтәрергә мөмкинлек бирәчәк.

5. МӘҖБҮРИ ТОТУ УРЫННАРЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

Мәҗбүри тоту урыннарындагы затларның хокукларын яклау мәсьәләләре социаль-әхлакый әһәмияткә ия һәм аларның гражданлык-хокукый хәлен билгеләү, иректән мәхрүм итү урыннарында санитария нормаларын үтәү, матди-көнкүреш, медицина-санитария тәэмин ителеше, режим таләпләрен һәм сак астында тоту сорокларын үтәү үзенчәлекләре белән бәйле.

Россиядә тоткыннарның һәм сак астында булган затларның хокукларын тәэмин итүгә зур игътибар бирелә, бу закон чыгару инициативаларында һәм гамәли чараларда чагыла.

2025 елда бу юнәлештә мөһим адымнарның берсе, Россия Федерациясе җинаять законнарын гуманизацияләүгә, хөкем ителгәннәрне төзәтү һәм аларның гаилә бәйләнешләрен саклап калу өчен өстәмә шартлар тудыруга юнәлдерелгән «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 82 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2025 ел 24 июнь №174-ФЗ Федераль закон кабул итү булды. Бу максатларда йөкле хатынга, ундүрт яшькә кадәрге баласы булган хатынга, ундүрт яшькә кадәрге баласы булган һәм ялгыз калган ир-атка җәза үтәүне кичектерүне гамәлдән чыгару яки кичектерүне саклап калу турындагы мәсьәләне суд тарафыннан хәл итүгә дифференциацияле якын килү каралган. Күрсәтелгән Федераль законда каралган нигезләмәләр чикләнгән затлар даирәсенә карата җинаять репрессиясе чараларын гомумән, җинаять-хокук яклау чараларын артык җиңеләйтмичә йомшартырга мөмкинлек бирәчәк.

Моннан тыш, узган елда «Россия Федерациясе Җинаять кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 299 маддәсе беренче өлешенең 7.1 пунктының үз көчен югалтуын тану турында» 2025 ел 27 июль №218-ФЗ Федераль закон кабул ителде, аның нигезендә төп эш урыны булмаган хөкем ителгәннәргә төзәтү эшләре рәвешендә җәза билгеләү мөмкинлеге төшереп калдырылды; мәҗбүри эшләр иректән мәхрүм итүне алдан билгеләмичә мөстәкыйль җәза төре буларак билгеләнде; Россия Федерациясе Җинаять кодексының аерым өлешендәге кайбер маддәләрнең санкцияләре мәҗбүри эшләр рәвешендәге җәза белән тулыландырылган (документ - 20.01.2026 гамәлгә керә).

Тагын бер мөһим яңалык, «Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 92 маддәсе һәм «Җинаятьләр кылуда шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне сак астында тоту турында» Федераль законның 18 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 23 мартындагы 60-ФЗ номерлы Федераль закон булды, ул шикләнелүчеләргә һәм гаепләнүчеләргә 14 яшькә кадәрге балалары белән бер ай дәвамында алар белән өстәмә күрешү хокукын бирде. Бу үзгәрешләр гаилә элемтәләрен саклауга һәм сак астында булган затларда психологик киеренкелекне киметүгә ярдәм итә. Алар закон чыгаручының җинаять процессының гуманитар аспектларын исәпкә алу һәм шикләнелүчеләргә һәм гаепләнүчеләргә карата гуманлырак мөнәсәбәт өчен шартлар тудыру омтылышын чагылдыра.

Хисап елында 2025 елның декабрендә Казанда «Җинаять-җәза үтәтү системасын үстерү (2018-2035 еллар)» федераль максатчан программасы кысаларында төзелгән яңа тикшерү изоляторы ачылу республикада җәзаларны үтәтү системасын үстерүдә мөһим этап булды. Әлеге биналар комплексын файдалануга тапшыру Казанда тикшерү изоляторларының тулылыгы проблемасын тулысынча хәл итә, ул 1000 кешегә исәпләнгән, аның составында административ бина, 6 режимлы корпус, шул исәптән шикләнелүче һәм гаепләнүче хатын-кызларны һәм балигъ булмаганнарны

урнаштыру өчен аерым корпус, җыю-тикшерү бүлеге, озак һәм кыска вакытлы очрашулар корпусы, транзит-күчерү пункты корпусы, амбулаторияле медицина часте корпусы, кер юу бүлмәсе, идарә хезмәткәрләре өчен ашханә, склад бүлмәләре бинасы, ремонт зонасы һәм юу урыны булган гараж бар. Медицина часте уңайлы хастаханә палаталары һәм заманча җиһазлар белән җиһазландырылган, шул исәптән инвалидлар һәм башка категориядәге аз хәрәкәтләнүче гражданнар өчен. Тикшерү изоляторында хуҗалык хезмәте күрсәтү отрядының хөкем ителүчеләре белән аларның туганнары белән озак вакытлы күрешүләр уздыру өчен биналар, шикләнелүчеләр, гаепләнүчеләр һәм хөкем ителүчеләрнең кыска вакытлы күрешүләре вакытында телефон сөйләшүләре өчен кабиналар бар.

2025 елда федераль һәм төбәк бюджетларыннан бүленгән акчалар белән

РФ Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсенең Чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәгендә, РФ Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлегенең шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту изоляторында ремонт эшләре башкарылды.

Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлегенең вакытлыча тоту изоляторы булган яңа административ бинасы төзелеше тәмамланды

Шулай ук 2025 елда Казанның “Гагаринский” 7 нче полиция бүлегендә тоткарланган затларны тоту өчен махсус бина файдалануга тапшырылды.

Мәҗбүри тоту урыннарындагы затларның хокукларын тәэмин итү һәм яклау буенча Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге

Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хисап елында җинаять- җәза үтәтү системасы учреждениеләрендә гражданнарның хокукларын тәэмин итү һәм яклау буенча эшне дәвам итте.

Кергән мөрәҗәгатьләрне системалы анализлауга һәм җинаять- җәза үтәтү системасы учреждениеләрендәге вәзгыятьне мониторинглауга төп әһәмият бирелә. Бу тенденцияләрне һәм проблемалы зоналарны вакытында ачыкларга, шулай ук аларны бетерү буенча нәтиҗәле чаралар эшләргә мөмкинлек бирә.

С.А.Салихова җитәкчелегендә «Үзенчәлекле балалар. Татарстан» АКБО һәм «Яңа планета» тернәкләндерү үзәге Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән берлектә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыра. Оешманың эшчәнлеге толерант җәмгыять формалаштыруга, иртә ярдәм системасын үстерүгә һәм балалар өчен инклюзив мохит булдыруга юнәлтелгән.

Оешманың эшчәнлеге нәтиҗәлелеге исбатланган методикаларны, аерым алганда, гамәли тәртип анализын (АВА-терапия) кертүгә һәм инклюзив мохит булдыруга юнәлтелгән.

1. Укыту һәм абилитация буенча проектлар:

- «Гамәли тәртип анализы мәктәбе» һәм «Үсеш»: ата-аналар һәм белгечләр (педагоглар, тьюторлар) өчен интенсив укыту курслары, үзенчәлекле балалар белән эшләүнең гамәли күнекмәләренә өйрәтү.
- «Сөйләмне башлап җибәрү»: сөйләм бозуларын төзәтү буенча махсус программа.

- Иҗади тернәкләндерү: «Татар орнаменты» проекты, анда балалар вак мотриканы үстерә һәм декоратив-гамәли сәнгать аша социализацияләнә.

2. Гаиләләргә һәм белгечләргә ярдәм:

«Перезагрузка»: ата-аналар өчен эмоциональ януны профилактикалау максатыннан психологик ярдәм клубы.

- «Өйдә берүзе»: аерым балаларда мөстәкыйльлек күнекмәләрен үстерү проекты.
- «Чиксез Казан»: нормотипик һәм аерым яшьтәшләр өчен аралашу мөмкинлеге тудыру инициативасы.

Проектларны гамәлгә ашыру барышында Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре тернәкләндерү үзәкләрендә гаиләләр белән даими очрашулар үткәрә, актуаль проблемаларны ачыклый һәм тәҗрибә уртаклаша.

Хисап чорында «Яңа Планета» үзәгендә 512дән артык бала терапевт ярдәме алды. Оешма белгечләре тарафыннан 195 000 сәгатьтән артык индивидуаль һәм төркемле шөгыльләрне үз эченә алган абилитация һәм тернәкләндерү чаралары комплексы гамәлгә ашырылды. Үзәк программалары логопедик коррекция, сенсор интеграциясе һәм төп тормыш күнекмәләрен формалаштыру кебек төп юнәлешләрне колачлый.

Эшнең мөһим юнәлеше булып, Россия Федерациясенең төрле төбәкләреннән килгән гаиләләр өчен баланың үсешендә тиз динамикага ирешүгә юнәлдерелгән 140тан артык кыска вакытлы интенсив курслар үткәрү булды.

Хәйрия эшчәнлегенә аерым игътибар бирелә. Агымдагы елда профильле программалар кысаларында 29 тәрбияләнүче адреслы ярдәм алды. Терапия, супервизион озату һәм гаиләләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән гомуми финанслау күләме 10 миллион сумнан артык тәшкил итте.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе (рәисе – И.А.Сатдинов) белән берлектә, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына буйсынган мәҗбүри тоту учреждениеләрендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен торгызу, бушлай юридик ярдәм күрсәтү һәм хокукый агарту буенча актив эш алып барылды.

Генераль директоры Сатдинов И.А. булган «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» белән берлектә, Татарстан Республикасында авыр тормыш хәлендә калган кешеләр өчен хәйрия проекты гамәлгә ашырыла. Проект, хокук бозучы оешмаларга җәлеп ителергә мөмкин булган яки кабат җинаять кылуга омтылышлы куркыныч төркеменә кергән гражданнар белән эшләүгә юнәлтелгән. Партнер оешма рәсми рәвештә пробация субъектлары исемлегенә кертелгән һәм иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән кешеләрнең социаль адаптациясенә актив ярдәм итә.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле Аппараты һәм «Кеше сыену урыны» социаль тернәкләндерү үзәге» автоном коммерцияле булмаган оешмасы А.А.Суханов җитәкчелегендә авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ярдәм итү буенча уртак проектны гамәлгә ашыра. Эш «ГЛОНАСС+112» системасы нигезендә оештырылган: 2025 елда гына да 408 гариза оператив эшкәртелгән. Оешманың социаль патруле көн саен чакыруларга чыгып, йортсызларга һәм мохтаҗларга комплексы ярдәм күрсәтә - кайнар аштан һәм юридик консультацияләрдән алып төн куну урыны бирүгә кадәр. Шунысын да әйтергә кирәк, 2018 елдан башлап «Кеше сыену урыны» хәйрия эшчәнлегенең киң инфраструктурасын үстерде. Бүгенге көндә оешма көн саен 3000нән артык бушлай

ашамлык өләшә, ә аның базасында социаль чәчтараш, мунча, кер юу һәм кием бирү пункты эшли.

Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау кысаларында, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Казан һәм Татарстан митрополиты Кирилл фатихасы белән О.С.Варганова җитәкчелегендә эшләүче «Мәрхәмәт» ярдәм хезмәте белән актив хезмәттәшлек итә. Бергә эшләү һәм хезмәт тарафыннан оештырылган хәйрия җыемнары нәтиҗәсендә, 2025 елда 30 мөрәҗәгать итүчегә тиз арада ярдәм күрсәтелде. Акчалар социаль әһәмиятле ихтыяҗларга юнәлдерелде: торак-коммуналь хуҗалык бурычларын каплау, көнкүреш техникасы һәм төзелеш материаллары сатып алу, шулай ук балаларны тернәкләндерү өчен түләү.

«Инвалид балаларның ата-аналары өчен хокукый белем мәктәбе» социаль проекты 2020 елдан бирле АРСИ Ассоциациясе (җитәкчесе М.А.Григорьева) ярдәме белән уңышлы үсә. Проектның төп бурычы — бушлай юридик ярдәм күрсәтү генә түгел, ә ата-аналарның республика хакимияте вәкилләре белән диалог мәйданчыгы булдыру. 2025 елда укытуның төп платформасы «Яндекс.Телемост» булды, бу 8 зур дәрес үткәрергә мөмкинлек бирде. Югары ихтыяҗ саннар белән раслана: 40 даими катнашучы белән читтән торып үткәрелгән форматта дәресләрнең видеоязмаларын 3000нән артык кешене караган.

Җитәкчесе Г.Г.Балафендиева булган «Юридик клиника» Татарстан Республикасы мигрантларга һәм социаль якланмаган катламнарга хокукый ярдәм күрсәтү үзәге» төбәк иҗтимагый оешмасы авыр тормыш хәлендә калган гражданнарның хокукларын яклау буенча актив эш алып бара. 2025 елда Вәкаләтле вәкил белән берлектә «Татарстан Республикасы пенитенциар учреждениеләрендә ВИЧ-инфекцияне профилактикалау» һәм «Үсмерләр арасында наркоманияне профилактикалау – Сәламәт булу модада» проектлары эшләтеп җибәрелде. Беренче проектны гамәлгә ашыру кысаларында ВИЧ-инфекциягә аноним экспресс-тестлар, белем бирү һәм агарту чаралары керә. Икенче проект үсмерләр һәм яшьләр арасында тискәре социаль йогынтыларга шәхси тотрыклылыкны арттыруга, шул исәптән ата-аналар һәм укучылар арасында аңлату эшләре алып бару юлы белән наркотик матдәләр куллануга кызыксынуны киметүгә юнәлтелгән. Проектлар кысаларында дәресләр циклы якынча мең кешене колачлады. Вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә эшнең зур өлешен хөкем ителгән, шикләнелүче һәм тикшерелүче гражданнар хокукларын яклау эше алып тора (бу тема докладның «Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын яклау» бүлегендә җентекләп ачыла).

«Татарстан Республикасы Студентлар Лигасы» РЯО - республика студентларын берләштерүче оешма, ул социаль-икътисади мәсьәләләрне хәл итү, студентларның һөнәри сыйфатларын үстерү, студентлар җәмгыятьләрен координацияләү һәм яшьләрнең фәнни һәм иҗади потенциалын гамәлгә ашыруда ярдәм итү белән шөгыльләнә. Студентлар һәм аспирантларны берләштерү өчен булдырылган оешма дәүләт органнары белән хезмәттәшлек итә һәм төбәктә студентлар берләшмәләренең эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру өстендә эшли.

2025 елның 28 гыйнварында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Татарстан Республикасы Студентлар Лигасы Президенты Ш.Н.Якупов арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Студентлар Лигасының уртак эше хокукый аңлату, студентлар һәм яшьләрнең хокукларын яклау, проблемаларны хәл итү өчен

югары уку йортлары һәм яшьләр оешмалары белән хезмәттәшлек итү, шулай ук хокукый мәдәният формалаштыруга юнәлтелгән уртак проектларны үз эченә ала.

2025 елда «Татарстан Республикасы Студентлар Лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы эшчәнлеге социаль ярдәм, яшьләрнең компетенцияләрен үстерү һәм югары уку йортлары һәм урта һөнәри уку йортлары студентларының казанышларын хуплау юнәлешендә тупланган иде.

2012 елдан башлап Студентлар Лигасы кысаларында Чит ил студентлары белән эшләү комитеты эшли. Комитет эшчәнлегенең максаты - республика территориясендә укучы чит ил студентларына адаптация һәм социализациядә ярдәм итү.

2025 елның 11 апрелендә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы бинасында мәгариф оешмаларындагы чит ил студентлары берләшмәләре җитәкчеләре белән очрашу узды, анда Вәкаләтле вәкил дә катнашты. Миграция исәбе, визаларны озайту һәм РФ законнарын үтәү мәсьәләләре каралды. Вәкаләтле вәкил Аппаратның катлаулы хәлләрдә чит ил гражданнарына бушлай юридик ярдәм күрсәтергә әзер булуын ассызыклады. Студентларны деструктив һәм экстремистик эшчәнлеккә җәлеп итүгә юл куймау мәсьәләсенә басым ясалды. Катнашучылар кампусларда иминлекне тәэмин итү чараларын тикшерделәр. Студентлар берләшмәләре җитәкчеләре тулай торакларда яшәү шартлары һәм медицина хезмәте күрсәтү сыйфаты мәсьәләләрен күтәрделәр. Чит ил студентларының ТР яшьләр грантларында һәм «Ярат. Төзе. Илһамландыр» кебек проектларда, «Яшьләр һәм балалар» илкүләм проекты кысаларында чараларда катнашу мөмкинлекләре тикшерелде.

Бу очрашу Татарстанда 20 меңнән артык чит ил студентлары өчен тигез мөмкинлекләр һәм милләтара татулык территориясе формалаштыру буенча Яшьләр министрлыгы һәм Вәкаләте вәкилнең системалы эшенең бер өлеше булды.

2025 елның 22 ноябрендә Вәкаләтле вәкил «ПРОкультуру» республика студентлар балында катнашты - бик матур, атмосфералы чара, ул яхшы традицияләрне кире кайтара һәм яшьләргә мәдәният, этикет һәм иҗат белән танышырга ярдәм итә. Студентлар әлеге тантанага ике ай әзерләнде, бу вакыт эчендә алар репетицияләр үткәрде, сайлап алу этапларында катнашты һәм бию номерларын шомартты. Бал нәтиҗәләре буенча өч номинациядә - «Балның иң яхшы пары», «Бал короле» һәм «Бал королевасы» җиңүчеләр билгеләнде.

2025 елда «Студентлар лигасы»ның төп проектлары һәм ярдәм чаралары:

- Транспорт гранты: 2025 елда ярдәм чарасы 5,7 меңнән артык студентны колачлады. Программа социаль мохтаҗларга һәм «яхшы» һәм «бик яхшы» билгеләре булган активистларга юл чыгымнарын компенсацияли. Киләсе этапка (2025–2026 уку елы) гаризалар кабул итү 2025 елның 1 декабренә кадәр барды.
- Яшьләр торак конкурсы: Лига активистлар һәм яшь галимнәргә ташламалы шартларда (еллык ставка 7%, беренче взнос 10%) торак алу мөмкинлеге бирүче конкурс операторы булды. 2025 елда конкурска якынча 300 гариза бирелде.
- Лига Форум: Татарстанның иң зур белем бирү форумы 2025 елның җәендә узды. Төп юнәлешләр лидерлык сыйфатларын үстерү һәм җәмгыятьләр белән идарә итү булды («Профессионаллар лигасы», «Университетлар лигасы» һәм «Җитәкчеләр лигасы»).

Татарстан Республикасында актив студентларны хуплау өчен зур ярдәм булып «Ел студенты» һәм «Ел казанышы» конкурслары тора. «Ел студенты» юбилей егерменче премиясе 2025 елның гыйнварында узды, анда җиңүчеләр фән, иҗат һәм спорт кебек төрле номинацияләрдә билгеләнде: барлыгы 18 номинация. Төп

номинациядә җиңүче традицион рәвештә «Алгарыш» программасы буенча дөньяның теләсә кайсы югары уку йортында уку хокукын яки Татарстан Республикасы Рәисеннән махсус акчалата бүләк ала. Вәкаләтле вәкил «Ел иреклесе/волонтеры» номинациясендә лауреатларны һәм җиңүчеләрне бүләкләүдә катнашты.

2025 елда «Студентлар лигасы» урта һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен талантларны хуплау максатыннан «Ел казанышы» IX премиясен үткәрде. Премия Татарстанның 56 һөнәри белем бирү оешмасыннан студентларны берләштерде. Вәкаләтле вәкил экспертлар советы эшендә катнашты, анда казанышларны бәяләүдә объективлык принципларын үтәүне тәэмин итте һәм катнашучыларның хокукларын яклады, шулай ук хокукый мәдәниятне һәм актив гражданлык позициясен тәрбияләүнең мөһим элементы буларак «Ел җәмәгатьчесе» номинациясендә җиңүчене бүләкләүдә катнашты.

Вәкаләтле вәкил Аппараты яңа инициативаларга ачык булып кала һәм партнерлык элемтәләрен ныгыту алга таба да республикабыз халкының хокукларын һәм ирекләрен саклауның ышанычлы гаранты булып хезмәт итәчәгенә ышаныч белдерә.

ЙОМГАК

Докладта бәян ителгән проблемалардан чыгып, Вәкаләтле вәкил федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы территориясендә эш итүче территориаль органнарына, дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү, үтәү һәм яклау максатларында кайбер чараларны гамәлгә ашыру мөмкинлеген карарга тәкъдим итә.

1. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының хокукларын яклау максатларында:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

- хәбәрсез югалган дип танылган хәрбиләрнең гаиләләренә ярдәм күрсәтү буенча җирле үзидарә органнарының, хәрби комиссариатларның, «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы филиалының һәм башка ведомстволарның ведомствоара хезмәттәшлеген камилләштерү мәсьәләсен карарга.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

- махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль гарантияләрен гамәлгә ашыруны, шул исәптән хәрби хезмәттән авыр дәрәҗәдәге имгәнүләр (аякларын ампутацияләү) булган, социаль яктан адаптацияләнмәгән, хәрби хезмәт узуга бәйле рәвештә җәзадан азат ителгән махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә урнаштыруны тикшереп торуны тәэмин итәргә;

- «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы һәм «Кадрлар» илкүләм проектының «Эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүнең актив чаралары» федераль проекты кысаларында махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруны дәвам итәргә;

- махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына өйдә социаль хезмәт күрсәтүне һәм социаль-тернәкләндерү хезмәтләрен күрсәтүне дәвам итәргә;

- махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның озак вакытлы тәрбиягә мохтаҗ туганнары арасыннан гражданнарны өйләренә социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүне тәэмин итәргә;

- мәшгульлек хезмәте учреждениеләренә I группа инвалидлар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучыларны өйләренә барып кабул итүне йөкләргә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

- I группа инвалид булган махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен өйдә күчмә кабул итүләр оештыруны тәэмин итәргә;

- хәрби хезмәттән азат ителгән махсус хәрби операциядә катнашучыларга психологик ярдәм күрсәтү эшен көчәйтергә;

- тирәнтен диспансерлаштыруны, чираттан тыш медицина тикшеренүләрен, махсус хәрби операция ветераннарын реабилитацияләүне тулы күләмдә тәэмин итәргә;

- махсус хәрби операция ветераннарына медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлеген координацияләүне дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына, «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалына:

- махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына түләүләрне билгеләү өчен хәрби частьләргә кирәкле документларны җыюда һәм җибәрүдә, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрнең тапшырылган документларын хәрби частьләр тарафыннан карау нәтиҗәләренә мониторинг ясауда һәрьяклап ярдәм күрсәтү эшен көчәйтергә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына, «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалына:

- махсус хәрби операциядән кайткан ветераннар белән эшләү буенча ведомствоара багланышлар оештырырга.

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына:

- адреслы ярдәм күрсәтү максатларында махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының ихтыяҗларын даими нигездә мониторинглауны гамәлгә ашырырга;

- махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын тыныч тормышка җайлаштыру чараларын оештырырга;

- Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның мәшгульлек дәрәҗәсен тикшереп торырга;

- махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә урнаштыру, шулай ук төрле дәрәҗәдәге имгәнүләре булган махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен яңа эш урыннары булдыру мәсьәләсе буенча муниципаль район эш бирүчеләре белән хезмәттәшлек итәргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә урнаштырганда дәүләт ярдәме чаралары турында эш бирүчеләргә хәбәр итәргә;

- Россия Федерациясе Кораллы көчләреннән демобилизацияләнгән һәрбер махсус хәрби операция ветеранына, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре әгъзаларына «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» дәүләт программасы һәм «Кадрлар» илкүләм проекты кысаларында территориаль халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре ярдәмендә эш бирүчеләрдән соралган һөнәрләр һәм белгечлекләр буенча түләүсез әзерләнү һәм яңадан әзерләү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә.

2. Гражданнарның хезмәт хокукларын гамәлгә ашыру максатларында

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

- Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләрнең минималь хезмәт хакы күләмен үтәвенә даими нигездә мониторинг

ясарга; хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча җитештерүдә имгәнүләр дәрәҗәсен киметүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрергә;

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары) тарафыннан эш бирүчеләр һәм хезмәткәрләр арасында хезмәт мөнәсәбәтләрен тиешенчә рәсмиләштерү мәсьәләсе буенча мәгълүмати-аңлату чараларын дәвам итәргә;

- легаль булмаган мәшгульлеккә каршы көрәш буенча Республика ведомствоара комиссиясе эш төркемнәре кысаларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары) тарафыннан эш бирүчеләрнең минималь хезмәт хакы дәрәҗәсен үтәвен тәэмин итү мониторингын үткәрүне дәвам итәргә;

- инвалидларга мәшгульлеккә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

Легаль булмаган мәшгульлеккә каршы көрәш буенча республика ведомствоара комиссиясенә:

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә (шәһәр округларында) легаль булмаган мәшгульлеккә каршы көрәш эшләрен оештыруны; эш бирүчеләрнең минималь хезмәт хакы дәрәҗәсен үтәвен; хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча җитештерүдә имгәнүләр дәрәҗәсен киметүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына:

- хезмәт өчен түләү дәрәҗәсен арттыруны тәэмин итү, хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләүнең минималь күләме өлешендә социаль гарантияләрен үтәү буенча контроль-күзәтчелек органнары һәм Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге белән тыгыз хезмәттәшлектә эш бирүчеләр белән эшне көчәйтергә;

- легаль булмаган мәшгульлеккә һәм хезмәт хакы буенча срогы чыккан бурычларга каршы көрәш буенча республика ведомствоара комиссияләренең эш төркемнәре эшчәнлеге кысаларында, хезмәт хакын түләүне тоткарлауга юл куйган эш бирүчеләрне тыңлау эшен дәвам итәргә; хезмәт мөнәсәбәтләрен яшереп калу очракларын ачыклау эшен оештырырга;

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге (шәһәр округы) мәгариф системасында квалификацияле педагогик кадрлар кытлыгын бетерү буенча программалар, чаралар планнары (юл картасы) эшләргә (булган очракта — камилләштерергә).

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җирле үзидарә органнары белән берлектә:

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең сәламәтлек саклау системасында квалификацияле медицина кадрлары кытлыгын бетерү буенча программалар һәм чаралар планнарын (юл карталары) бергәләп эшләргә (булган очракта — камилләштерергә).

Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- Урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларының уку-укыту программаларын формалаштыруда актив катнашырга;

- предприятиеләрдә профилактик медицина (цех медицинасы) инфраструктурасын, шул исәптән сәламәтлек пунктлары, физиотерапия кабинетлары, сәламәтләндерү комплекслары, санаторий-профилакторийлар һәм цех табиблары институты системаларын торгызырга.

Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә эшләүче оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә:

- предприятиеләрдә тирәнтен диспансеризация үткәрергә, хезмәткәрләргә сыйфатлы һөнәри тикшерү уздырырга, шулай ук производствода савыктыру системасын булдырырга һәм үстерергә тәкъдим итәргә.

3. Торак хокукларын гамәлгә ашыру максатларында:

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына:

- торак урыннарга мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәткәндә гражданнардан артык документлар таләп итү очракларын төшереп калдырырга;

- күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү турында муниципаль норматив хокукый актларны федераль һәм төбәк кануннарына туры китерү чараларын күрергә;

- Әлмәт, Яшел Үзән, Кукмара һәм Түбән Кама муниципаль районнарында өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү эшен җирле үзидарә органнары тарафыннан оештыруны мониторинглау барышында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан ачыкланган хокук бозуларны игътибарга алырга;

- индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт яны җир кишәрлеге) алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен җир кишәрлеге алу хокукына ия затлар исемлекләренә кертелгән гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре бирү чиратларының катгый үтәлешен тәэмин итәргә;

- өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү буенча административ процедураларны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 нче маддәсендә билгеләнгән срокларның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә;

- күп балалы гаиләләргә бирелә торган буш җир кишәрлекләрен ачыклау максатыннан һәр муниципаль берәмлектә җирләргә инвентаризация үткәрергә;

- маневрлы торак фонды формалаштыру өчен бушаган торак биналарга мониторинг ясарга.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитетына һәм Яр Чаллы шәһәре башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсенә:

- индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт яны җир кишәрлеге) алып бару, үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен җир кишәрлеге алу хокукына ия затлар исемлекләренә кертелгән гражданнар

белән җир кишәрлеге урынына акчалата түләү алу мөмкинлеге турында мәгълүмати-аңлату әңгәмәсе үткәрергә.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

- Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 нче маддәсе 13 пунктына җир кишәрлеген сайлау процедурасын үткәрү турында гражданнарга хәбәр итү ысуллары исемлегенә тиешле хәбәрләрне Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрү мөмкинлеген өстәү өлешендә үзгәрешләр кертүнең максатка ярашлылыгын карарга.

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгына:

- әлеге портал аша җир кишәрлеген сайлау процедурасын үткәрү турында гражданнарга хәбәрнамәләрне автоматлаштырылган юллау механизмын интеграцияләү максатыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының функциональ мөмкинлекләрен киңәйтү мөмкинлеген карарга.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгына:

- Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 нче маддәсе 10 пунктында каралган документларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре аша, мөрәҗәгать итүче сайлаган беренчел мөрәҗәгать итү ысулы нигезендә бирү механизмын булдыру мөмкинлеген бергәләп карарга.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына:

- кирәк булган очракта Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 нче маддәсенә җир кишәрлеген сайлау процедурасын үткәрү турында гражданнарга хәбәр итү ысуллары исемлеген тулыландыру, шулай ук Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 нче маддәсе 10 пунктында каралган документларны дәүләт һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре порталы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре аша аша тапшыру мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә үзгәрешләр кертү турында закон проектын әзерләүдә хокукый ярдәм күрсәтергә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

- ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның һәм алар арасыннан булган затларның торак урыннарга мохтаҗлыгы турындагы мәсьәләләрне караганда «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә гарантияләре турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә тайпылышсыз таянырга, шулай ук югары суд актларында формалаштырылган хокукый позицияләрне исәпкә алырга;

- махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү турында законлы көченә кергән суд актларын үтәүнең өстенлекле характерына игътибарны юнәлтергә.

“Халык контроле” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган “Торак-коммуналь хуҗалык” категориясе буенча мөрәҗәгатьләрне башкаручыларга:

- мөрәҗәгатьләрнең вакытында һәм сыйфатлы үтәлешенә контрольне көчәйтергә, мөрәҗәгатьләргә объектив һәм вакытында статус бирергә, фотоотчет һәм башкарылган эшләр турында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт дәгълүмат системасында комментарий урнаштырырга;

- әгәр мәсьәләне башка ведомствога күчерергә кирәк булса, “Дәлилле баш тарту” статусын нигезсез куллануны булдырмаска;

- эш киңәшмәләре барышында каралган “Халык контроле” ТР дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча тулы чаралар күрергә.

4. Гражданнарның сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларын саклау максатларында:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы белән берлектә:

- Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре порталы аша электрон медицина документларын йөкләүгә комачаулый торган техник проблемаларны бетерү буенча комплексы чаралар күрергә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

- медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм куркынычсызлыгына ведомство һәм эчке контроль системасын камилләштерергә;

- медицина эшчәнлеген стандартлаштыруны, процесслы һәм системалы алымнарны кертүне, медицина ярдәме күрсәткәндә сакчыл технологияләр куллануны тәэмин итәргә.

5. Социаль тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау максатларында:

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә:

- тернәкләндерү чарасына мохтаҗ инвалид һәр затның сезонлылык факторларын һәм шәхси ихтыяҗларын исәпкә алып, техник тернәкләндерү чарасын сатып алу процедураларын уздыруның катгый үз вакытында булуын тәэмин итәргә;

- билгеләнгән графиклардан тайпылышларны оператив рәвештә ачыкларга һәм булдырмый калырга мөмкинлек бирә торган техник тернәкләндерү чарасын китерү срокларын мониторинглауның комплексы системасын кертергә;

- инвалид гражданнар арасында техник тернәкләндерү чарасы сатып алу өчен электрон сертификатларны рәсмиләштерү һәм куллану мөмкинлекләре, тәртибе турында мәгълүмати-аңлату эшен активлаштырырга, шул исәптән тиешле мәгълүмати материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында, ведомстволарның рәсми

сайтларында урнаштыру, медик-социаль экспертиза учреждениеләрендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, шулай ук инвалидларның иҗтимагый оешмаларында таратуны активлаштырырга.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

- тәрбияләүнең шәхси программасын формалаштыру өчен өлкән яшьтәге гражданнарның сәламәтлеге торышы турында белешмәләр алу өлешендә медицина оешмалары белән үзара хезмәттәшлекне оештырырга.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

- хезмәт ветераннарына, инвалидларга, өлкәннәргә, балалы гаиләләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына оператив һәм сыйфатлы социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль социаль яклау бүлекләре белән берлектә Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына:

- «Кайгырту» суперсервисы сайтындагы “Алтын еллар-Золотые годы” бүлегендә муниципаль районда (шәһәр округында) актив озак яшәү чараларын гамәлгә ашыручы оешмалар, эш графиклары, хезмәт күрсәтү шартлары турында мәгълүматның актуаль халәтендә булуына булышлык күрсәтүне тәэмин итәргә;

- ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарга, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга йорт саен (фатир саен) йөрүләрне, социаль хезмәтләр алуга ихтыяҗ булу-булмауны оештырырга;

- муниципаль район (шәһәр округы) территориясендә яшәүче өлкән буын гражданнарын өлкән яшьтәге гражданнарның сыйфатын һәм гомер озынлыгын яхшырту өчен өстәмә шартлар тудыруга юнәлдерелгән сәламәтләндерү, социаль һәм иҗади чараларга актив җәлеп итүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына идарәче компанияләр белән берлектә:

- инвалидларның транспорт чаралары өчен йорт яны территорияләрендә парковка урыннары оештыруны да кертеп, уңайлы мохитне тәэмин итү чараларын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру максатларында, кресло-коляскалардан файдаланучы инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларны ачыклау буенча системалы эш алып барырга;

- күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны планлаштырганда инвалидлыгы булган милекчеләрдән тиешле гаризалар булганда, пандуслар, култыксалар һәм башка конструктив элементлар урнаштыруны да кертеп, киртәсез мохит булдыру чараларын күз алдында тотарга, бу халыкның аз хәрәкәтчән төркемнәренең социаль объектларга тоткарлыксыз керү хокукын нәтиҗәле гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортлар, интернат-йортлар директорларына:

Бу чараларны вакытында үткәрүне тәэмин итәргә:

- медик-социаль экспертиза бюросында социаль хезмәтләр алучыларны инвалидлык билгеләү (яңадан карау) предметына тикшерү;

- социаль хезмәтләр алучыларны реабилитацияләү һәм реабилитацияләүнең шәхси программаларын яңадан карау (актуальләштерү);

- реабилитация һәм абилитациянең шәхси программаларында язылган тәкъдимнәр нигезендә социаль хезмәтләр каралган инвалидларга техник тернәкләндерү чараларын алу.

6. Мәгариф өлкәсендә балигъ булмаган балалар хокукларын яклау максатларында:

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына:

- белем алу мөмкинлеген тәэмин итү һәм аның сыйфатын күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына яңа мәгариф оешмалары төзүгә ихтыяҗ турында, шулай ук гамәлдәге мәгариф объектларына капиталь ремонт ясау кирәклеге турында нигезле тәкъдимнәрне үз вакытында тапшырырга;

- уку елы башланыр алдыннан, мәгариф оешмалары белән бергәләп, юл өслегенең, тротуарларның, яктыртуның торышын комплексы бәяләү, шулай ук өстәмә юл билгеләре, җәяүлеләр кичүләре һәм киртәләр кую ихтыяҗын ачыклау максатларында, мәктәп янындагы бер километр радиустагы территорияне, якындагы җәмәгать транспорты тукталышларына кадәрге участокларны да кертеп, тикшерергә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Республика ресурс үзәге» белән берлектә:

- мәгариф оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан ведомствоара исәптә торучы балигъ булмаганнарга диагностика ясауны девиант тәртипкә һәм хокукка каршы гамәлләр кылуга омтылышны ачыклау предметына методик ярдәм күрсәтүне һәм мониторинг үткәрүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына:

- 2026 елда Татарстан Республикасында уздырыла торган Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы кысаларында патриотизм тәрбияләүгә, тарихка һәм мәдәни традицияләргә хөрмәт күрсәтүгә, буыннар арасында элемтәләрне ныгытуга, тарихи мирасны аңлауга, тирән милли үзаңны уятуга юнәлдерелгән чаралар үткәрүне тәэмин итәргә; мәгълүмат диварларында күрсәтмә агитация урнаштыруны, батырлык һәм фидакарьлек күрсәткән, төрле тарихи чорларда Ватан өчен көрәшкән сугышчыларга хөрмәт темасына багышланган видеопродукция күрсәтүне тәэмин итәргә.

7. Балаларның гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү хокукын яклау максатларында:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округлары башлыкларына (балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр рәисләренә):

- «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары таләпләре нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан опекун һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә яшәүче балигъ булмаганнарның тормыш шартларын планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру графигын ай саен расларга һәм тикшереп торырга;

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы, Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, “Опека һәм попечительлек турында” №48-ФЗ Федераль закон таләпләренә ярашлы рәвештә, опека һәм попечительлек органының опекуннар хисапларын тикшерү үткәрүенә контроль алып барырга;

- төрле хезмәтләр һәм оешмаларның гамәлләрен координацияләү максатларында үзләренең ата-ана хокукларын торгызырга омтылучы ата-аналар белән ведомствоара профилактика эшен оештыру өчен комиссия (консилиум) төзү турындагы мәсьәләне карарга;

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләргә мониторинг үткәрергә һәм, кирәк була калса, авыр тормыш вәзгыятен җиңүгә юнәлдерелгән адреслы ярдәм күрсәтергә;

- муниципаль берәмлекләр, шәһәр округлары территорияләрендә “Аеклык ноктасы” проектында катнашучыларны реабилитацияләүнең шәхси программасын гамәлгә ашыруны анализларга, алкогольгә бәйлелектән интегүче ата-аналарга квалификацияле психологик ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә;

- гаилә хәмергә бирелгән очракта балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясенең 2025 елның 21 мартындагы 11-25 номерлы карары белән расланган балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары эшчәнлеге алгоритмын кулланырга;

- Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү мәгариф оешмаларында гаилә сәясәтен гамәлгә ашыру һәм хезмәткәрләргә, студентларга һәм аспирантларга күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары турындагы мәгълүматларга квартал саен мониторинг оештырырга;

- социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләргә, күп балалы гаиләләргә яшәү шартларын өйрәнү, торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен бурычлар артуга юл куймау һәм йорт хуҗалыкларын энергия ресурсларыннан өзмәү максатында квартирларга йөрүне оештырырга.

Татарстан Республикасы Территориаль социаль яклау органнарына, балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларга:

- балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютка җибәрелә торган балигъ булмаганнарга 6 айдан артмаган вакытка социаль хезмәт күрсәтүнең шәхси программасын төзергә.

Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларга:

- бала балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютка кергән көннән алып 2 эш көне эчендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы мәгълүматларының бердәм банкын төзү турында» 2010 ел 22 апрель № 294 карары белән расланган социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы мәгълүматларының бердәм банкын төзү тәртибе нигезендә «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасына сигнал картасын җибәрергә;

- социаль хезмәтләр күрсәтүгә алты айдан да артмаган вакытка шартнамәләр төзергә;

- балаларның социаль приютларда озак вакыт булуына юл куймаска, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә, шулай ук баланы гаиләгә кайтару яисә тәрбиянең башка рәвешенә урнаштыру буенча оператив карар кабул итүне тәэмин итү өчен опека һәм попечительлек органнарына үз вакытында хәбәр итәргә;

- иҗтимагый иминлек өлкәсендә хокук бозулар кылуга катнашы булуга бәйле рәвештә тәрбияләнүчеләр, шул исәптән профилактик исәптә торучылар һәм (яисә) эчке эшләр органнарында административ күзәтү астында торучылар белән, учреждениедә хезмәтләр алучы Россия традицион рухи - әхлакый кыйммәтләрен тәрбияләү буенча индивидуаль (төркемле) әңгәмәләр рәвешендә профилактик чаралар үткәрүне дини, иҗтимагый һәм спорт оешмалары вәкилләрен, психологларны җәлеп итеп башкарырга;

- балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар базасында балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен реабилитацияләү программаларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен халыкка комплексы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре белгечләрен чакырып, квартал саен социаль-тернәкләндерү консилиумнары үткәрүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге (шәһәр округларындагы) мәгариф идарәсе органнарына балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар белән берлектә:

- социаль приютларда реабилитацияләнүче балалар белән белем бирү процессын оештыру һәм тәрбия эшен уздыру мәсьәләләре буенча мәгариф оешмалары белән нәтиҗәле хезмәттәшлекне тәэмин итәргә.

8. Гражданнарның мәҗбүри булу урыннарында кеше хокукларын саклау һәм яклау максатларында:

Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең "16 нчы медицина-санитария часте"нә:

- җинаять-җәза үтәтү системасы учреждениеләрендәге затлар белән, аларның сәламәтлеге торышы, уздырылган медицина тикшеренүләре нәтиҗәләре, ачыкланган

авырулар булу-булмавы, билгеләнгән диагноз, авыруның үсеш фаразы, шулай ук медицина ярдәме күрсәтүнең кулланыла торган яисә фаразлана торган ысуллары, аларга бәйле хәвеф-хәтәрләр һәм медицина катнашының мөмкин булган вариантлары турында тулы мәгълүмат бирүне тәэмин итү максатыннан актив төстә аңлату эшләре үткәрүне тәкъдим итәргә.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең "16 нчы медицина-санитария часте"нә:

- телемедицина технологияләрен кулланып, шул исәптән граждан сәламәтлек саклау учреждениеләрен җәлеп итеп, хөкем ителгәннәргә һәм сак астында тотылучы затларга медицина ярдәме күрсәтү практикасын киңәйтүне тәкъдим итәргә;

- кадрлар кытлыгын тулыландыру өчен профильле медицина югары уку йортлары белән максатчан укыту турында шартнамәләр төзү мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә.

«Казан дәүләт медицина университеты», Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең «16 нчы медицина-санитария часте» белән берлектә:

- төзәтү учреждениеләренең медицина бүлекчәләре (медицина-санитария частьләре) базасында «Казан дәүләт медицина университеты» югары һөнәри белем бирү учреждениесе студентларының производство практикасын оештыру мөмкинлегеген эшләргә тәкъдим итәргә.

Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең "16 нчы медицина-санитария часте"нә һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

- балигъ булмаганнарга, шул исәптән тикшерү изоляторы шартларында туганнарга һәм йөкле хатын-кызларга медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча ведомстволар һәм медицина учреждениеләре арасында үзара хезмәттәшлек өлешендә Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Сәламәтлек саклау министрлыгы арасындагы килешүне яңадан карарга һәм эшләп бетерергә.

Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә:

- төзәтү учреждениеләре җитәкчеләренә пенсия алуга хөкем ителгәннәрнең хокукларын үтәү һәм документларны рәсмиләштерү һәм Россия Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан буенча идарәсенә җибәрүнең билгеләнгән срокларын үтәү өлешендә социаль бүлекләр эшен катгый контрольдә тотуны тәкъдим итәргә.

Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә:

- Россия ҖҮФХ Татарстан Республикасы буенча идарәсе 2 нче төзәтү колониясе һәм Россия ҖҮФХ Татарстан Республикасы буенча идарәсе 19 нчы төзәтү колониясе базасында наркотик чараларга һәм психоактив матдәләргә бәйлелеккә эләккән хөкем

ителүчеләрне реабилитацияләү буенча социаль проектны гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

- реабилитацияләү буенча социаль проектта катнашу мөмкинлеге турында наркотик һәм психоактив матдәләргә бәйлелеккә эләккән хөкем ителүчеләрне мөмкин кадәр күбрәк колачлауны мәгълүмати-аңлату эше белән тәэмин итәргә киңәш итәргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

- наркотик һәм психоактив бәйлелектән интегүче хөкем ителгәннәрне реабилитацияләү буенча социаль проектны Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау мөмкинлеген карарга;

- «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру кысаларында пробация үзәкләре эшчәнлеген оештыру чараларын финанслау мөмкинлеген карарга.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

- иректән мәхрүм итү урыннарыннан чыккан гражданнарның мәшгульлегенә пробация турындагы законнар кысаларында ярдәм итү;

- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тернәкләндерү һәм социаль адаптацияләү эшен, шул исәптән эш эзләү, һөнәри белем алу, гаилә элемтәләрен торгызу чараларын да кертеп дәвам итәргә.

9. Җинаятьләр һәм зыян күрүчеләр турында мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын яклау максатларында:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенә:

- Эчке эшләр органнары тикшерүчеләре, РФ Тикшерү комитетының ТР буенча Тикшерү идарәсе бүлекчәләре тарафыннан җинаятьләр турындагы хәбәрләрне тикшергәндә законлылыкны саклауга юнәлдерелгән өстәмә чаралар эшләүне тәкъдим итәргә;

- мөрәҗәгать итүчеләрнең конституциячел хокукларын тоткарлыксыз гамәлгә ашыру гарантияләрен арттыру максатларында җинаятьләр турындагы хәбәрләрне карау стадиясендә тикшерүчеләр һәм сорау алучылар эшчәнлегенә өзлексез процессуаль һәм ведомство контролен көчәйтергә тәкъдим итәргә;

- тикшерү һәм сорау алу органнары хезмәткәрләрен процессуаль эшчәнлек алып барганда, аларның һөнәри күнекмәләрен камилләштерү максатларында хезмәт әзерлеге системасында даими укытуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

10. Гражданнарның судта яклауга хокукларын яклау максатларында:

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә:

- гражданнар мөрәҗәгатьләренә җавап бирүнең ачыклыгын һәм оперативлыгын арттыру һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау өлешендә Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнары эшчәнлегенә даими ведомство контроле уздыру буенча өстәмә чаралар күрергә.

11. Миграция законнары өлкәсендә кеше хокукларын һәм ирекләрен саклау максатларында:

Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына:

- җинаять-җәза үтәтү системасы учреждениеләренә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә документлары булмаган хөкем ителгәннәр белән эшне көчәйтергә һәм кешенең хокукый статусын һәм гражданлык мөнәсәбәтен билгеләүгә барлык мөмкин булган чараларны кабул итүне йөкләргә.